ИМАНЛЫ ҖЫЕН

Татарстанда бөтен дөнья мөселманнарын көтәләр

> 2

КӨРӘШЛЕ ХАЛЫК

Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш турнирының 60 еллыгы уңаеннан махсус кушымта

> 3–10

ЮБИЛЕЙ КӨТКӘНДӘ...

«ВТ»ның төрле еллардагы баш мөхәррирләре хатирәләре белән уртаклашты

> 11

НЕФТЬЛЕ КИЛӘЧӘК

КФУ доценты Ирек Мөхәммәтдинов нефть чыгаруның яңа ысулын тәкъдим итә

> 12

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 23 (28990) | Чәршәмбе | 15 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

РӘХМӘТЛЕ БУЛЫЙК!

Укытучы һәм Остаз елы

Татарстанда Россия Президенты тарафыннан игълан ителгән Укытучы һәм Остаз елының ачылу тантанасында «Минем яраткан укытучым» фотоархив акциясенә старт бирелде. Анда бездәге барлык буын укытучыларының миллионлаган сурәтләре урын алачак. Республика мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин быел педагогларга кагылышлы күңелле вакыйгалар күп булачагын әйтте. Ә яз көне аларга ярдәм чарасы да көтелә. Тик министр аның ничек буласын әлегә сер итеп калдырды.

Бәйрәмгә укытучы династияләре, халык укытучылары да чакырылган. Үз эшенең осталарына бүләкләр дә тапшырдылар. Мөгаллимнәрне котларга Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов та килгән иде.

– Һәрберебезнең тормышында мөһим урын алып торган укытучысы, остазы бар. Без аларны һәрвакыт җылы хисләр белән искә алабыз. Бу залда үз һөнәрләрендә иң яхшылар – халык укытучылары, Мирза Мәхмүтов исемендәге премия лауреатлары, педагоглар династияләре. Татарстанда укытучы һөнәре яңа дәрәҗәгә күтәрелсен өчен барысы да эшләнә. Яңа белем бирү технологияләре укытучыларның эш шартларын яхшырта, аларны тормышка ашыру мөмкинлекләрен киңәйтә, – диде Рәис.

Рөстәм Миңнеханов быел югары мәктәп, фәнгә игътибар биреләчәгенә басым ясады. Татарстанда яшь галимнәргә нәтиҗәле эшләү өчен уңайлы шартлар тудыру дәвам итәчәк. «Яшь галимнәр – Россиянең техник һәм технологик алгарышына өмет. Безнең төп өстенлегебез – талантларга, иҗади һәм интеллектуаль хезмәткә сакчыл караш. Бу, һичшиксез, нәтиҗә китерер дип ышанам», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Илсур Һадиуллин республиканың мәгариф тарихына багышланган китап бастырыласын, укытучыларга атап, музей, урам, парклар булдырыласын әйтте. «Әлбәттә, болар барысы да берьюлы башкарыла торган эш түгел. Әмма башлаганны башкарып чыгарбыз. Укытучы елы истә калырлык булачак, – дип ышандырды Илсур Һадиуллин. – Безгә укытучыларның барысы да тигез. Аларга кагылышлы проектлар барысы өчен дә булырга тиеш. Укытучыларга ярдәм дә күздә тотыла. Монысын мартта билгеләп үтәчәкбез».

tatarstan.ru

Министр укытучыларга карашны үзгәртергә, алар турында күбрәк сөйләргә өндәде. Быелгы елның максаты да – укытучыга хөрмәтне арттыру, бу һөнәргә яшьләрне җәлеп итү. КФУда бүген педагогик юнәлештә 745 студент укыса, шуларның яртысы ике телле мәктәпләр өчен әзерләнә.

– Алар, мәктәпкә кайтып, үз көчләрен биреп эшли башлый, шунда төпләнә икән, безнең өчен моннан да зур табыш юк. Әти-әниләр, балаларның укытучыга хөрмәтен үстерик. Алар, рәхмәт сиңа, укытучым, дип әйтсә, менә шул мәгариф системасына карашны үзгәртү була инде, – ди министр.

Укытучылардан быелгы елдан нәрсәләр көтүләре турында да сораштык.

– Минем өчен хезмәт хакы да, дәрәҗә дә беренче урында түгел. Мәктәпләргә яңа федераль белем бирү стандартлары кертелде, әмма дәреслекләр һаман юк. Бу бит үзәктә булырга тиеш. Шуны кайтару буенча эшләсеннәр иде. Балаларга яхшы белем бирәсе килә. Яңа дәреслекләр алар өчен кызык, – диде Чистай районының инглиз һәм татар телләре укытучысы Рәмзия Әфләтунова.

Базарлы Матак гимназиясенең рус теле укытучысы Нурия Фаракшинаның иң зур теләге – хисап эшенең кимүе.

– Быелгы уку елында бездә бер педагогик сыйныф ачылды. Мин – аларның сыйныф җитәкчесе. Кызыксынучылар күп түгел. Анда 11 бала белем ала. Булачак педагогларны тәрбиялибез, – диде ул.

Татарстанның Халык укытучылары арасында Казандагы 2 нче гимназиянең элеккеге директоры Камәрия Хәмидуллина да бар иде. Ул сәхнәгә күтәрелгәч, иң элек остазлары – Әлифба авторлары Сәләй Вагыйзов белән Рәмзия Вәлитованың хезмәте турында зурлап сөйләде. Бүген дә дәреслекнең мәктәптә кулланылуына, татар милләтенә телне өйрәтүдә зур ярдәмче булуына басым ясады.

– Укытучы кулында – илнең киләчәге. Бүген аягында нык басып торган, социаль яктан якланган укытучы гына сәламәт җәмгыятькә нигез сала ала. Укытучы һәм Остаз елында бу хакта уйланырга, нәтиҗәле карарлар кабул итәргә насыйп булсын, – дип теләде Камәрия Хәмидуллина.

Рәис җитәкчелегендә

Татарстанда «Алдынгылар хәрәкәте» балалар һәм яшьләр гомумроссия хәрәкәте белән эшләү буенча координация советы оештырылды. Җитәкчесе – Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов.

Республика Рәисе Указы нигезендә, координация советы киңәшмә орган булып тора. Максаты – хәрәкәтнең төбәк бүлеге эшен җайга салу, Татарстанда федераль программаларны гамәлгә ашыруга ярдәм итү максатларына җавап бирердәй республика, муниципалитет программаларын эшләү, балалар һәм яшьләрнең җирле иҗтимагый берләшмәләренә булышу. Ә инде бурычлары – хәрәкәт эшчәнлегенә тиешле хакимият органнарын җәлеп итү, балалар һәм яшьләргә һөнәр сайлауда булышу, иң яхшы балалар һәм яшьләр башлангычларын Татарстан бюджеты хисабына тормышка ашыруга ярдәм итү. Шулай ук республикада остазлыкны үстерү, балалар һәм яшьләр белән тәрбия эше алып баруга күз-колак булу, балалар хәрәкәтен үстерү өчен мәгариф оешмалары, фәнни үзәкләр белән берлектә эшләү күздә тотыла.

Кимү

Узган елда Россиядә пенсионерлар саны, 232 мең кешегә (0,6%) кимеп, 41,78 миллионга калган. Социаль фонд мәгълүматлары буенча, өлкәннәр саны азаю пандемияле 2021 елдагы белән чагыштырганда акрынайган. Ул чагында пенсионерлар сафы 970 мең кешегә кимегән.

Биредә сүз Социаль фондта исәптә торучылар саны турында бара. Оборона, Эчке эшләр министрлыклары, Тикшерү комитеты, башка көч ведомстволары системасында пенсия алучылар аңа керми. Гомумән, пенсионерлар 2019 елдан, пенсия яшен этаплап арттыру башланганнан бирле кими. 2022 елның төп үзенчәлеге – эшләүче пенсионерларның кинәт кимүе (600 мең кешегә, ягъни 7 процентка азаеп, 7,9 миллионга калган).

Пенсиянең уртача күләменә килсәк, узган ел 14 процентка артып, 20,6 мең сум тәшкил иткән. Социаль пенсия, 19 процентка диярлек үсеп, 12,1 мең сумга, ә инвалидлык буенча түләү, 13 процентка артып, 12,5 мең сумга җиткән.

Фәкыйрьлектән котылганнар

Узган ел Татарстанда кереме яшәү минимумыннан кимрәк булган 7 меңнән артык кеше белән социаль контракт төзелгән. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы хәбәренә караганда, барлыгы 4375 кеше эшкә урнашкан, 2227се үз эшен ачкан, 152се шәхси ярдәмче хуҗалык булдырган.

Мәсәлән, Балтач районы Шубан авылында яшәүче өч балалы Алмаз Габделхаков гаиләсенә шулай ярдәм ителгән. Хатыны – декрет ялында. Гаилә хуҗасының да даими эш урыны булмаган. Социаль яклау бүлегендә аңа социаль контракт мөмкинлекләрен аңлатканнар. Үзмәшгуль сыйфатында теркәлеп, үз эшен ачарга ярдәм иткәннәр. Хәзер ул тимердән чүкеп әйберләр ясый. Алмаз дәүләт ярдәме белән үзенә кирәкле барлык эш коралларын сатып алган.

Исегезгә төшерәбез: социаль контракт – социаль яклау органнары белән аз керемле кешеләр арасындагы килешү ул. Әлеге документ нигезендә, социаль яклау органына акчалата түләүләр бирү, кирәкле товарлар сатып алу кебек ярдәм итү бурычы йөкләнә. Ә инде ярдәм алучылар эшкә урнашырга, үз эшен ачарга, яисә шәхси ярдәмче хуҗалыгын җайга салырга тиеш.

Сатудан алганнар

Татарстанда хокук саклау органнары, хезмәткәрләре 1–10 февральдә хәмер һәм тәмәкенең законсыз әйләнешен ачыклау йөзеннән, «Хәмер» операциясе үткәргән. Эчке эшләр министрлыгы хәбәр иткәнчә, продукцияне законсыз сатуга бәйле 128 административ хокук бозу ачыкланган, 12 җинаять эше кузгатылган.

Эчке эшләр министрлыгының Икътисадый иминлек һәм коррупциягә каршы көрәш идарәсе хезмәткәрләре, Дәүләт алкоголь инспекциясе белгечләре белән берлектә, 33 мең литрдан артыграк күләмдә «стеклоомывайка» саклаган складларга тап булган. Экспертиза нәтиҗәсеннән күренгәнчә, сәрхушләр куллана торган бу сыекчада метил спирты өлеше 25% тәшкил итә.

Түбән Камада Икътисадый иминлек һәм коррупциягә каршы көрәш идарәсе белгечләре сәүдә үзәге янында үз машинасына 47 тартма төягән бер ир-атны тоткарлаган. Тартмаларның һәркайсына 40–50шәр савыт спиртлы сыеклык тутырылган булуы ачыкланган. Сыеклыкның гомуми күләме 225 литр тәшкил иткән. Ә күрше республикага керү юлында ялган хәмер ташучылар тотылган: алардан барлыгы 1160 литр күләмендә 292 савыт сыеклык тартып алынган. Моннан тыш шәһәрдә 4260 литр күләмендә ялган хәмер белән шыплап тулган склад табылган.

Шушы чара барышында барлыгы 85 мең литрдан күбрәк спиртлы сыеклык, шулай ук 46 мең кап тәмәке законсыз әйләнештән алынган.

Сәламәтлек

Сакланыр чак

Вирус котыра! Соңгы арада бу сүзләрне еш ишетергә туры килә. Арабызда сезонлы ОРВИ, грипп белән авыручылар күп. Коронавирус йоктыручылар саны да арта бара. Вируслы чирләр котырган чорда ничек сынмаска-сыгылмаска? Авырудан ничек сакланырга?

Балтач районының Бөрбаш авылында бүген гаиләләре белән авыручылар шактый. Авыл мәктәбендә биология фәнен укытучы Мәлик Сибгатуллин сүзләренә караганда, вирус мәктәпкә дә үтеп кергән.

– Баштарак балалар бакчасына йөрүче сабыйлар авырып алган иде. Хәзер укучылар арасында да вирус йоктыручылар шактый. Бигрәк тә башлангыч сыйныф укучылары арасында күп андыйлар. 34 баланың унбише авырый. Чирдән саклану чараларын күрәбез. Күбрәк суган, сарымсак ашарга тырышабыз. Аларны сыйныф бүлмәләренә дә кисеп куеп, яңартып торабыз. Ата-аналарга: «Баланың тамагы авыртса, температурасы күтәрелсә, аны мәктәпкә җибәрмәгез, авыру шуннан башлана», – дип әйтеп куйдык, – ди ул.

Мамадыш районының Көек-Ерыкса авылында исә ул яктан тынычрак икән. Авылда грипп, ОРВИ белән авыручылар берән-сәрән генә күзәтелә.

– Элек кышын грипп, ОРВИ белән авырый идек тә ел буенча җитәрлек иммунитет барлыкка килә иде. Хәзер алай түгел. Коронавирус чире дә гадәти грипп белән тиңләште бугай инде, беренче елдагы кебек үк куркытмый. Ике ел рәттән ярыйсы гына көчле авырдым. Үзем нindидер махсус препаратлар эчәм дип әйтә алмыйм, витаминга бай ризыклар белән яхшы итеп тукланырга тырышам. С витаминына бай әфлисун, мандарин, алма, катырылган карлыган – даими рационда. Әле соңгы вакытта кичләрен чи суган капкаларга гадәтләндем, – ди шушы авылда яшәүче Гөлназ Гәрәева.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Татарстан буенча Роспотребнадзор идарәсе мәгълүматларына караганда, республикада грипп һәм ОРВИ белән авыручылар саны эпидемик чиктән 21 процентка арткан. ОРВИның барлык төрләре арасында иң киң таралганы – грипп. Бүген очраган вируслы авыруларның 92,3 проценты нәкъ менә шуңа туры килә. Хәзерге вакытта Татарстанда барлыгы 1,8 миллион кеше гриппка каршы прививка ясаткан. Шуларның 400 меңе – балалар.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Александр МЯСНИКОВ, медицина фәннәре кандидаты, кардиолог:

Кызганыч, хатын-кызлар гомеренең соңгы 15 елын ялгызлыкта уздыра. Ник дигәндә, ир-атлар кыска гомерле. Аларның организмы озак яшәүгә исәпләнмәгән. Хатын-кыз кебек озын гомерле булу өчен, ир-ат бик нык тырышырга – начар гадәтләрдән арынырга, хроник чирләрен, гәүдә авырлыгын контрольдә тотарга, стресска бирешмәскә тиеш. Эшсез утырырга да ярамый. Ул күңел төшенкелегенә китерә. Максаты булмаган ир-ат яшәү ямен югалта.

(«Аргументы и факты» басмасындагы әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – МАТБУГАТКА ЫШАНЫЧ

Илкүләм җәмагатьчелек фикерен өйрәнү үзәге белгечләре Россиядә яшәүчеләрнең кайсы матбугат чараларына ни дәрәҗәдә ышануларын ачыклаган.





Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АТОМ БОМБАСЫ ҺӘМ ПАЛЬМА МАЕ

Үткән атнада күңелсез яңалыклар Көнчыгыш һәм Көньяк-көнчыгыш Азиядән килде. Япониянең Киодо мәгълүмат агентлыгы 2035 елга Кытай атом-төш очлыкларын 900 данәгә җиткерергә җыена дигән хәбәр таратты. Имештер, Кытай Халык Республикасы лидеры Си Цзиньпин шундый программаны раслаган. АКШта исә үткән ел ук Пекинның 2035 елга атом бомбалары санын 1500гә җиткерергә җыенуы хакында хәбәр иткәннәр иде. Япон агентлыгы, алар 2027 елга ук, Кытай армиясенең йөз еллыгына туры китереп, 550 атом-төш очлыклы ракетаны сафка бастырырга телиләр, ди. Тынычлык проблемаларын өйрәнүче Стокгольм институты мәгълүматлары бүген АКШта – 5428, Россиядә 5977 атом-төш очлыгы барлыгын әйтәләр. Пекинның үз арсеналларын ишәйтүе бу өлкәдә ике полюсның йомшаруына, иминлеккә янаучы өченче үзәк барлыкка килүгә китерәчәк. Америка галимнәре федерациясе 2022 елда дөньяда барысы 12 мең атом-төш бомбасы булганлыгын әйтә. 1986 елда, «салкын» сугыш ахырына якынлашканда, Җир шарында 70 мең атом-төш очлыгы булган. Шуларның 98 проценты – АКШ һәм Россиядә. «Салкын» сугыш тәгәлләнгәч, Вашингтон, Мәскәү, Лондон һәм Париж үз арсеналларын 80 процентка кыскартканнар. Нәтиҗәдә АКШ һәм Россия өлеше 87 процентка калган. Американнар әйткәнчә, үз бомбалары санын 1500гә җиткерсә, Кытай кулында дәһшәтле коралның 14 проценты булачак. Хәзер аларда атом-төш очлыкларының 25 проценты континентара ракеталарда. Булган кадәр бомбалар да кешелек җәмгыятен юк итәргә җитә. Цивилизацияне юк итү максатына ирешергә теләүчеләр, бомбаларның бер өлешен генә стратосферада шартлатып, безне утсыз-сусыз, элемтәсез калдыра алалар. Болай да бүген атом-төш һәлакәте янавы тарихта күрелмәгән дәрәҗәгә җитте.

Көньяк-көнчыгыш Азия гиганты Индонезия исә безнең өчен икътисадый проблемалар тудыру белән яный. Ил яңадан пальма маен экспортлауны 20 процентка киметмәкче. Үткән ел Индонезия 30 миллион тонна пальма мае экспортлаган. Хәзер Джакартада майның дизель ягулыгына кушыла торган өлешен арттырырга дигән фикергә килгәннәр. Февраль аеннан элекке 30 процент урынына 35 процентка җиткерү күз алдында тотыла. Киләчәктә 40 процентка ук арттыру да планлаштырыла икән. Шулай эшләгәч, ил нефть сатып алуны киметү мөмкинлегенә ия булачак, атмосферага парник газлары чыгу да кими, ди. Пальма маеның 90 проценты Индонезия һәм Малайзиядә җитештерелә. Бу илләрнең экспортны киметүе азык-төлек бәяләренә тәэсир ясаячак. Җитмәсә, Малайзиядә, начар һава шартлары һәм ашламалар җитмәү сәбәпле, май җитештерү кимегән. Искә төшерәбез: 2010 елларда башланган «гарәп язы»на этәргечне биоягулык итеп рапс маен куллана башлау биргән иде. Азык-төлеккә бәяләр үсте дә, башта Тунис фетнәсе дөрләде, аңа башка гарәп илләре кушылды. Ул «яз»ның ялкыны әле дә сүнеп бетмәде.

Россиядә

МИЛЛИАРДЕРЛАР ТАГЫН БАЙЫЙ

Тарихта күрелмәгән санкцияләр нәтиҗәсендә авыр хәлдә калган һәм активлары чит илләрдә бикләнгән Россия олигархлары яңадан байлык туплый башлаган. Бу хакта финанс мәгълүматлары белән сату итүче Bloomberg агентлыгы әйтә. Ел башыннан аларның мөлкәте 16,1 миллиард долларга арткан. «Лукойл» хуҗасы Ваһит Алекперов, 2,5 миллиард доллар акча эшләп, байлыгын 17,9 миллиард долларга җиткергән. «Северсталь»ның төп акционеры Алексей Мордашов, байлыгына 1,54 миллиард доллар өстәп, 20,2 миллиард иткән. «Новатэк» җитәкчесе Леонид Михельсон, 1,12 миллиардны кушып, суммасын 12,7 миллиард долларга кадәр үстергән. Федераль хөкүмәтнең олигархлардан бюджетка 250 миллиард сум акча таләп итүе тикмәгә генә түгел, димәк. Инициативаның авторы Белоусов әфәнде олигархларга байлык бик җиңел килә, күктән ява дип саный, бюджет белән бүлешсәләр, берни дә югалтмыйлар дигән фикердә. Чынлап та, хөкүмәт алардан күтәреп булмаслыкны таләп итми, күп булса 3,5 миллиард доллар тирәсе акчаны чыгарып салырга гына куша.

Россиянең урта сыйныфының исә – үз кайгысы. Ел башыннан бирле валюта хисапларындагы акчаны саклау мәшәкатен чиктеләр. Хөкүмәт алай кыерсытмады аларны да. Ай саен 50 мең доллар акчаны «тимер пәрдә»нең теге ягына күчерергә рөхсәт итте. Мөмкинлек йөз процентка файдаланылган. Россиянең Үзәк банкы мәгълүматлары ватандашларның чит илләр банкларындагы акчасының 94,3 миллиард долларга җитүен күрсәтә. 2022 ел дәвамында чит илләрдәге хисапларга 63,7 миллиард доллар акча өстәлгән. Июнь аенда Үзәк банк чит илгә күчерергә рөхсәт ителгән акчаның күләмен миллион долларга ук җиткергән икән. Нәтиҗәдә өченче кварталда статистика тарихындагы иң зур сан – 1,47 триллион сум акча чит ил банкларына аккан. Россия банкларындагы валюта кертемнәре саеккан инде, билгеле. 94 миллиард доллардан 57 миллиардка гына калган.

Грузиягә алдагы ел белән чагыштырганда биш тапкыр күбрәк акча күчкән, гомуми сумма 2,06 миллиард доллар тәшкил иткән. Үткән ел 45439 россияле грузин банкларында хисап ачкан. Кыргызстанга Россиядән 2,6 миллиард доллар күчкән. Грузия һәм Кыргызстан кебек кечкенә илләр өчен бик зур суммалар бу.

Үзәк банк бары тик Россиядән күчкән акчаны гына саный. Бик күп Россия компанияләре чит илләргә күчеп теркәлделәр, кече бизнес вәкилләренең дә байтагы шунда күчте. Аларның башка илләрдә эшләгән акчасын контрольгә алып буладырмы, анысы билгесез. Махсус хәрби операция нәтиҗәсендә илнең финанс югалтулары бик күпкә җыела әле боларны да кушкач. Элекке союздаш республикаларда россиялеләр тырышлыгы белән эчке тулай продукт ике урынлы саннар белән үсте.

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

КӘГАЗЬДӘ ГЕНӘ КАЛМАСЫН!

Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Цифрлы үсешкә ярдәм итү ассоциациясе утырышында әнә шулай диде. Фәнни-техник эшләр кәгазьдә генә «эшләргә» тиеш түгел диюе җитәкченең. Шуңа күрә инновацияләрдән актив файдаланырга чакырды.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, мондый чаралар республиканың фәнни-мәгариф комплексы эшчәнлегенә кагылышлы актуаль мәсьәләләрне анализлауга һәм үсеш өчен мөһим булган башлангычларны тормышка ашыруда ярдәм итә. Рәис бу җәһәттән ил башлыгы Владимир Путинның сүзләрен дә телгә алды.

– Мәгариф һәм фән советында Владимир Путин искәрткәнчә, технологик бәйсезлеккә ирешү өчен ил икътисадына хәзер үзендә җитештерелгән эшләнмәләргә мохтаҗ. Тикшеренүләргә сарыф итәрлек вакытны кире кайтарып булмый инде хәзер, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Саннарга да тукталды. Республика Рәисе әйтүенчә, инновацияләр ягыннан актив булганнар рәтенә ил икътисадының реаль секторына караган компанияләрнең 12 проценты гына керә.

– Бүген Россиянең технологик бәйсезлеген тәэмин итү бурычы илнең киләчәк үсеше өчен тагын да әһәмиятлерәк. Моның өчен бездә дистә еллар дәвамында төзелгән көчле фән һәм инженерия мәктәпләре бар, – ди Рөстәм Миңнеханов. – Әмма фәнни-техник эшчәнлек нәтиҗәләрен коммерциячел итү өчен компетенцияләребез җитеп бетми. Шулай ук аларның икътисад бурычларына йөз тотулары да кирәк.

Сүз уңаеннан, утырышта Татарстандагы студентлар стартаплары турында да сөйләштеләр. 2022 ел нәтиҗәләре буенча республиканың 129 проекты «Студентлар стартапы» илкүләм бәйгесендә җиңгән. Утырышка кадәр Рөстәм Миңнехановка да шуларның берничәсен тәкъдим иттеләр.

– Яшьләр төрле юнәлешләр буенча проектлар әзерли. Бәлки, алар бик үк камил дә түгелдер. Әмма нәрсәнедер үзгәртергә тырышучы кешеләр булуы мөһимрәк. Киләчәк – алар кулында. Алар белән актив хезмәттәшлек итәргә кирәк, – диде республика Рәисе һәм предприятиеләргә игътибарны шул яшьләргә юнәлтергә кушты.

Кайбер стартаплар инде куллану урынын да тапкан. IT парк директоры Руслан Власов сүзләренчә, 129 җиңүченең 24ен IT парк үз канаты астына сыендырган. Аларга эш урыннары тәкъдим ителгән.

МАРТ АЕНА БИЛГЕЛӘНДЕ

Казанның «Санкт-Петербург» волейбол үзәгендә Татарстан Волейбол федерациясе президиумы утырышы узды. Оешманың чираттагы хисап конференциясен 2 мартта уздыру турында карар кабул иттеләр.

Дәүләт Советы Рәисе, федерация президенты Фәрит Мөхәммәтшин утырышны ачып, волейболның халык арасында торган саен күбрәк таралуын билгеләп үтте.

– Осталар командалары сөендерә, яңа проектларны тормышка ашыру башланды, – диде ул. – Мәктәп волейбол лигасы федераль проектка әйләнеп килә. Күп кенә төбәкләр безнең башлангычны хуплый. Быел республикабызда лигага 21 меңнән артыграк мәктәп укучысы кушылды. Профессиональ командаларыбыз – «Ак барс-Динамо» һәм «Зенит-Казан» зур уңышларга ирешә. Республикада спорт тормышы тукталып тормый. Шулай ук агымдагы ел да чараларга бай булачак. Ел азагына кадәр федерация эшчәнлегенең барлык юнәлешләре буенча спорт чаралары календаре булдырылды. Ул конференция делегатлары раславына чыгарылачак.

Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, студентлар арасында волейболны популярлаштыру буенча эшне көчәйтергә кирәк. Ректорлар, студентлар лигалары һәм профессиональ клублар белән тыгызрак элемтәне җайга салу кирәк. Җирле федерацияләр белән эшләүне үстерүдәге мөмкинлекләрдән файдаланасы бар.

Президиум, Татарстан Волейбол федерациясе вице-президентын сайлау буенча кандидатура тәкъдим итү мәсьәләсен карап, бу вазыйфага республикада волейболны үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән Андрей Ляпуновны тәкъдим итте.

Волейбол федерациясе президенты, «2022 елга кадәр Татарстанда волейболны үстерү концепциясе»н үтәү һәм 2027 елга концепция проекты буенча фикер алышуда, яңа документны федерациянең җирле бүлекләре һәм барлык комитетлары тәкъдимнәре белән тулыландыру кирәклеген искәртте.

Президиум әгъзалары шулай ук Волейбол федерациясенең «Уңыш» физкультура-спорт җәмгыяте белән хезмәттәшлеге турында килешү проекты буенча фикер алышты.

Мәңге хәтердә

15 февраль – Ватаныбыздан читтә хезмәт бурычын үтәгәндә һәлак булганнарны искә алу көне. Республикада яшәүчеләргә Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин мөрәҗәгать белән чыкты.

«Бу көнне без төрле елларда хезмәт бурычы буенча Ватаныбыздан читтә хәрби низагларны җайга салуда катнашучыларның барчасына баш иябез, – диелә анда. – Хәрби интернационалистлар үзләренең фидакарьлеге һәм ныклыгы аркасында Бөек Ватан сугышы чорында немец-фашист гаскәрләрен җиңгән бабаларыбызның каһарманлык белән сугарылган үткәненә лаеклы булуларын раслады. Алар, Ватанга хезмәт итүдә үрнәккә әйләнеп, югары дәрәҗәдә хәрби фидакарьлек, профессионализм һәм батырлык күрсәтте.

Кайнар нокталарда хәрби бурычын үтәгәндә 25 мең кеше һәлак булган. Без бу коралды низагларда үзләренең туганнарын, якыннарын һәм тугры дусларын югалтканнарның барысының да кайгысын уртаклашабыз. Ватаныбыз өчен һәлак булганнарның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланачак! Исән-имин кайтучыларның һәркайсына дан!

Хәрби интернационалистларның тиңдәшсез тәҗрибәсе бүген дә – Кораллы Көчләрдә һәм хокук саклау органнарында, дәүләт һәм җәмәгать оешмаларында яшьләрне илебезгә тугры хезмәт итү, шул исәптән ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләү буенча җаваплы хезмәттә дә бик кирәк.

Хезмәт бурычын илебездән читтә үтәгәннәрнең барчасын эчкерсез котлыйм! Сезгә һәм якыннарыгызга озын гомер, тынычлык, бәхет һәм иминлек телим!»

КӨТЕЛГӘН КУНАКЛАР

Рамазан ае тәгәлләнгәч, Татарстанда бөтен дөнья мөселманнарын көтәләр. Башкалада быелдан федераль дәрәҗәдәге «KazanForum» җыены узачак. Аның кысасында 200дән артык чара үткәрергә ниятлиләр. Ә тырышып эшләгәннән соң, кунакларны «Изге Болгар җыены»нда шаккатырмакчылар. Татарстан Министрлар Кабинетында узган брифингта быелгы форумга әзерлек турында сөйләделәр.

«Россия – Ислам дөньясы: KazanForum» халыкара икътисадый җыены Татарстан башкаласында 18–19 май көннәрендә узачак. Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина әйтүенчә, быелгы чара оештыру ягыннан да, кунаклар саны буенча да алдагы еллардан аерылачак.

– Бу – Татарстанда ел саен үткәрелүче иң зур икътисадый вакыйга, – диде ул. – Быел ул ундүртенче тапкыр узачак. Җыенга федераль статус бирелгәннән соң, без гамәлдәге илкүләм чаралар белән бер дәрәҗәгә чыктык.

Билгеле булганча, агымдагы елның 17 гыйнварында Россия Президенты Владимир Путин «KazanSummit»ка яңа статус һәм яңа исем бирде. Аны үткәрү өчен Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин җаваплы.

– Форумның рәсми чаралары 18–19 май көннәренә билгеләнгән. Эш аерым юнәлешләр буенча алып барылачак. Иң зурларыннан берсе – халыкара хезмәттәшлек. Аның кысасында, Ислам илләре һәм Россия депутатлары катнашында «Россия – Фарсы култыгы» парламентара тыңлаулары да узар дип көтелә. Шулай ук, уртак туризм, Якын һәм Ерак Көнчыгыш илләре белән хезмәттәшлекне ныгыту, ислам банкингы өлкәсендә тәҗрибә уртаклашу кебек мәсьәләләр дә мөһим, – диде Талия Миңнуллина.

Кунаклар исемлеге тәгаен билгеле түгел әле. Моңа кадәр кайбер мәгълүмат чыганаклары, әлеге чарага Россия Президенты киләчәк, дип тә язган иде. Тимерне кызуында сугып, брифингта журналистлар Талия Миңнуллинадан:

– Форумга Владимир Путин киләчәкме? – дип тә сорады.

– Бу – федераль дәрәҗәдәге чара, шуңа күрә ил җитәкчелеге катнашуы көтелә, – дип бик әдәпле генә җавап бирде агентлык җитәкчесе.

Серне бераз чишеп, Төркия, Мисыр, Индонезия, Азәрбайҗан, Үзбәкстан һәм Малайзиядән зур кунаклар көтелә, дип тә өстәде. Татарстан Рәисе ярдәмчесе Газинур Бакиров сүзләренә караганда, БДБ илләре, Якын Көнчыгыш һәм Африкадан да катнашучылар күп булачак. Форум рәсми рәвештә биш телдә (!) алып барылачак. Кунакларга чакыру тарата башлаганнар инде. Форумга теркәлү 1 февральдә башланган.

– Форум мөселман булмаган илләр өчен дә ачык, – дип тә искәртте Газинур Бакиров.

tatarstan.ru

Җыенда катнашучыларны, татарларга хас булганча, тәмле тел, якты йөз белән кунак итәргә вәгъдә иттеләр. Озын сүзнең кыскасы, хезмәттәшлекне ныгыту өчен бөтен мөмкинлекләрне дә булдырырга тырышачаклар. Бу җәһәттән, форумны оештыру икътисадый яктан үзен акламый, дигән сорауга да икеләнергә урын калдырмыйча җавап бирде Талия Миңнуллина.

– Хәтерләсәгез, былтыр Петербург халыкара икътисадый форумында катнашу өчен бер миллион сумга якын акча түләргә кирәк иде. Җыен үткәреп, икътисадый яктан отыш алырга телибез икән, мәсьәләдән чыгу юлы бар әнә. Әмма без аңлы рәвештә мондый юлдан барудан баш тарттык, чөнки болай эшләсәк, төп катнашучыларыбызны югалтачакбыз. Болай булгач, аны үткәреп торудан ни файда? Без былтыргы бәяләрне саклап калдык, алар иң түбәне. Мәсәлән, премиум пакет 50 мең сум тора, – диде агентлык җитәкчесе.

Газинур Бакиров әйтүенчә, ислам илләре белән хезмәттәшлек итүнең үз нечкәлекләре бар.

– Россиягә басым ясалган шартларда ислам илләре төп хезмәттәшләребезгә әверелеп бара. Шуңа күрә безгә бик яхшылап әзерләнергә кирәк. Чит илләрдәге хезмәттәшләребез безгә килгәч: «Үзебезне өйдә кебек хис итәбез», – диләр. Димәк, безгә ышаналар. Бу юлы да йөзгә кызыллык китерергә ярамый, – диде ул.

Федераль дәрәҗәдәге чарага әверелгәч, үзәктәгеләргә дини җыенның үзенчәлекләрен аңлатырга кирәклеген дә яшермәделәр. Мәсәлән, төшкә кадәрге чаралар көндезге намазга кадәр бетәргә тиеш. Тышкы кыяфәткә бәйле белешмәлек тә нәшер иткәннәр хәтта.

Җитди сөйләшүләрдән соң, 20 майда форум кунакларын хәләл-маркетта көтәләр. Сүз уңаеннан, быел ул, халыкка барып җитү җиңелрәк булсын өчен, Казан агросәнәгать паркында узачак. Ә менә 21 майда узачак Изге Болгар җыенына ничек тә барырга киңәш иттеләр. Татарстан мөфтие Камил Сәмигуллин Болгарга килүчеләрне шаккатырырга вәгъдә итте.

– Без хаталар өстендә эш үткәрдек. Югыйсә: «Алдагы елларда булдык инде, гел бер үк», – дигән сүзләр ишетергә туры килә. Быел Изге җыенга Мәдинә шәһәреннән, Дагыстан, Гарәп Әмирлекләре һәм башка илләрдән Мөхәммәд пәйгамбәрнең 11 изге әманәтен алып кайтачакбыз. Әлеге күргәзмә бер көн генә эшләячәк, чөнки куркынычсызлык мәсьәләсен тәэмин итү шактый катлаулы. Болгар җыенына килүчеләр аларны үз күзләре белән күрә алачак, – дип җөпләде мөфти.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Сакланыр чак

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Балалар дигәннән, соңгы арада алар арасында да грипп, ОРВИ йоктыру очраклары арткан. Казанның 11 нче шәһәр балалар хастаханәсе педиатры Гөлназ Азизова моны, иң беренче чиратта, көннәр җылы булуга бәйләп аңлата.

– Көннәр җылыту белән вируслар активлашты. Аннары битлек режимы бетерелүнең дә йогынтысы юк түгел. Кешеләр тынычланды, саклык чараларын үтәми башлады. Коронавирус белән авырганнан соң күпләрнең иммунитеты төште. Шул рәвешле башка төр вируслы авыруларга юл ачылды. Соңгы арада балалар арасында да ОРВИ һәм грипп белән авыручылар саны бик нык артты. Коронавирус очраклары да уртача 30 процентка күбәйде. Яңа елга кадәр балалар күбрәк гриппның А штаммы белән авырган булса, хәзер нигездә В штаммы күзәтелә. Сезонлы ОРВИ очраклары да еш очрый. Грипп вакытында температура бик югары була. Ул 5–7 көн дәвам итә. Бала гәүдә авырту, сөякләр сызлаудан зарлана. Косарга, эче китәргә мөмкин. ОРВИ берничә сәгатьтән башлап, ике тәүлек дәвамында кешедән кешегә йогарга мөмкин. Чир билгеләре күренүгә үк кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк, – ди Гөлназ Азизова.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының баш эпидемиологы Дмитрий Лопушов фикеренчә, соңгы арада вируслы чирләр белән авыручылар саны артуга аптырыйсы юк. Ник дигәндә, елныңелында шушы чорда күзәтелә торган хәл бу.

– Узган елның сентябреннән бирле Татарстанда 3 меңнән артык грипп йоктыру очрагы теркәлде. Соңгы арада күбрәк гриппның В штаммы очрый. А штаммыннан аермалы буларак, ул ике дулкында уза. Башта кешенең температурасы 38–39 градуска кадәр күтәрелә дә дару эчкәч төшә. Кеше үзен тулысынча терелгән кебек хис итә. Әмма ике-өч көннән соң температура кабат күтәрелә. Бәхеткә, грипптан үлем-китем очраклары теркәлмәде. Монда гриппка каршы ясалган вакцинаның өлеше зур, – ди белгеч.

Коронавирус та чигенми. Соңгы бер тәүлек эчендә генә дә Татарстанда ковид йоктыруның 104 очрагы теркәлгән. Шул рәвешле республикада коронавирус белән авыручылар саны 196325кә җитте. Бүген республикада 17 инфекция хастаханәсе эшли.

– Хәзер коронавирус элеккечә үк гадәти ОРВИ кебек уза. Кешенең җиңелчә генә температурасы күтәрелә, ютәл борчый. Дөрес, хроник чирләре булган, 65 яшьтән өлкәнрәк кешеләр аны элеккечә үк авыр кичерә. Апрель аена республикада грипп, ОРВИ белән авыручылар саны кимеячәк. Коронавирус буенча вазгыятьне фаразлау кыенрак. Шулай да, өч еллык күзәтүләр буенча карасак, ул елның теләсә кайсы вакытында күзәтелергә мөмкин, – ди Дмитрий Лопушев.

Белгеч, вируслы чирләр йоктырмас өчен, гади генә кагыйдәләрне истә тотарга киңәш итә. Җәмәгать урыннарында битлек киеп йөрү, вируслы авыру йоктырган кеше белән аралашмау, бүлмәләрне даими рәвештә җилләтеп, тузаннарны сөртеп торырга кирәк, ди ул. Температура күтәрелсә, укырга, эшкә бармыйча, вакытында дәвалана башларга кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Без – көрәшле халык, Без – көрәшче халык!

Бер үгет

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне:
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.
Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне.

Кем сокланмас көчкә, тимер сынса
Һәм су чыкса баскан эзеңнән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
Эшең булса чыпчык тезеннән.

Эзе калсын керсез намусыңның,
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма!
Кешелегең белән горурлан!

Һәр адымыңда синең туры акыл,
Көчле йөрәк эзен күрсеннәр,
Кылыч белән түгел, турылык һәм
Чынлык белән көчле кешеләр.

Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында.
Янып калсын гомрең, маяк булып,
Үзеңнән соң килгән буынга.

Утта булган балчык кире купмас,
Эштә булган тимер тутыкмас.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас.

Муса ҖӘЛИЛ.
Декабрь, 1943

МАРАТ ӘХМӘТОВ:

«КӨРӘШЕБЕЗ МАТУР, КӨРӘШЕБЕЗ МӘГЪНӘЛЕ»

Татар көрәшсез яши алмый. Газетабызның юбилей бәйгесе алдыннан Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Көрәш федерациясе президиумы рәисе Марат ӘХМӘТОВ белән көрәш һәм милләт, җиңүче һәм батыр, тарих һәм чынбарлык турында сөйләштек.

:: Марат Готович, көрәшне милләтнең аерылгысыз бер өлеше дигәндә нәрсәне күз алдында тотасыз?

– Татар халкының яшәү рәвеше дә, аның тарихы да көрәшкә бәйле. Сүз бит билгә сөлге салып бил алышу турында гына бармый. Әйтәләр бит әле: көчле булсаң егасың, көчсезрәк булсаң егыласың. Иң авыры – үзең белән үзең көрәшү. Аның өчен бик зур ихтыяр көче кирәк. Бәйгеләрдә бик күп җиңүләр яулап, халык хәтеренә кереп калган, келәмнән киткәч тормышта да үзенә урын таба алган, башка эшләрдә уңышка ирешкән егетләр бар. Кызганыч, сөлге белән башкалардан өстен чыгып, аннары югалып калганнары да юк түгел.

Безнең көрәштә этеп һәм төртеп егып кына җиңә алмыйсың. Анда көч янында хәйлә дә, акыл да кирәк. Кагыйдәләре дә иң гадел, тамашачыга да аңлаешлы. Бездә каерып алып ыргыталар, матур итеп әйләндереп төшерәләр. Минемчә, безнең көрәш бик матур. Мәгънәсе дә бик зур.

:: Федерациягә башкарма директор булып килгән Марсель Таһиров бу вазыйфага алынганнан бирле районнардан кайтып керми диярлек. Нинди хәбәрләр алып кайта?

– Районнардагы очрашулар нәтиҗәсез узмый. Киләчәгебез өметсез түгел. Төп игътибарны район үзәкләренә һәм көрәш традицияләре булган авылларга бирергә кирәк. Казанда һәм башка шәһәрләрдә резервлар җитәрлек. Икенче яктан, аларда спорт төрләре дә бик күп. Һәрберсе белән шөгыльләнергә һәр җирдә зур мөмкинлекләр тудырылган. Яшермим, милли көрәшне үстерү елдан-ел катлаулана бара.

Республикада милли көрәшнең торышы төрле җирдә төрлечә. Көрәшне саклау һәм үстерү традицияләренә тугрылыклы калган дистәдән артык районыбыз бар. Рәхмәт аларга. Сөйләшеп тә, аңлашып та әллә ни кузгата алмаган районнар бар. Бәлки, аларда көрәш традицияләре бөтенләй юктыр? Көрәш булсын өчен урында фанат тренер кирәк. Милли спорт төренә үзе гашыйк һәм аларга булышырга әзер булган җитәкчеләр кирәк. Иганәчеләр дә кирәк. Менә Чаллыда «Профит» җәмгыяте җитәкчесе, Дәүләт Советы депутаты Марсель Мингалимов бар. Ул көрәшчеләр белән дә бик матур эшли, әдәбият һәм сәнгать әһелләрен дә игътибарсыз калдырмый. Чаллыда милли мохиткә бик матур хезмәт итүче тырыш егетебез.

Татар яшәгән бар җирдә милли традицияләребез сакланып, көрәш белән җанлы эш алып барылса, бик әйбәт булыр иде. Әмма без аңа ирешә алмадык. Җаның-тәнең белән эшләсәң, берничә елдан нәтиҗәсе булмый калмый. Әйтик, Лаешта Азат Нурмөхәммәтов исемле егетебез бар, хакимият башлыклары Илдус Зарипов бик игътибарлы. «Алар читтән көрәшчеләр җыя», – дип әйтергә мөмкиннәр. Кемгәдер ошамаска да мөмкин, әмма бу – көрәшне үстерүнең бер алымы. Ул егетләрне кызыксындырып, эш биреп, урын табалар, яшьләрне тәрбиялиләр. Шушы тәртиптә күңелләре сүрелми эшләсәләр, ике-өч елдан Лаешның үзендә туып-үскән көрәшчеләр үсеп чыгачак. Эзсез калмаячак. Күчеп йөрүгә килгәндә, хоккейда һәм футболда гомер буе шулай бит инде. Нишлисең, һәрберсенең тормыш итәсе килә. Хәзер бит көрәш факультатив, ягъни өстәмә рәвештә генә шөгыльләнә торган спорт төре түгел. Һөнәри спорт төренә әверелде. Батыр булып озаграк яшисең килсә, һичшиксез, һәр көнне берничә сәгать шөгыльләнергә туры килә. Шунсыз келәмгә чыгып, батыр калу мөмкин түгел.

:: Батыр калу димәктән, ул нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

– Батыр келәмдә яки Сабан туенда җиңүче генә түгел. Ул – беренчедән, көчле рухлы, кыю, тәвәккәл, хисләре белән идарә итә ала торган кеше. Әлбәттә, җиңеп яши торган кеше. Җиңелсә, шуннан сабак ала белгән. Чөнки гомер буе батыр булу мөмкин түгел. Батыр калып була, ә батыр булып яшәү бик авыр. Татарның батырын рухи яктан милли җанлы, кешелекле, итагатьле шул ук вакытта гадел холыклы кеше буларак күз алдына китерәсе килә. Идеаль батыр ул җыелма образ булырга мөмкин. Бөтен яктан да камил шәхес була ала микән? Булса да, андыйны күргән юк.

:: Әлеге сыйфатларны сеңдерү – тренер эшеме?

– Моның өчен ул үзе дә шул сыйфатларга ия булырга тиеш. Педагог та, психолог та, филолог та, милләтпәрвәр дә. Шушындый тренер кулына эләгеп, яшь егет аңа охшарга тырыша икән, шундый сыйфатлар тәрбияләргә мөмкин булыр иде. Тормыш фән белән, гыйлем белән бергә үрелеп барганда, эчтәлеге дә яхшырак була.

:: Марат Готович, герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган бәйгегә карата фикерләрегезне дә җиткерсәгез иде.

– Иң дәрәҗәле турнир бу. Электән килгән традицияләр белән бәйле микән, көрәшчеләр аны хәтта Татарстан чемпионатыннан да дәрәҗәлерәк дип кабул итә. Быелгысы – 60 нчы юбилей турниры да шулай булыр дип уйлыйм. Әле «мин – юбилей елы батыры» дип горурланырга да мөмкиннәр. Аның Муса Җәлил исемен йөртүе белән дә горурланабыз. Азатлык һәм батырлык символы буларак, бәйгене Җәлил исеме белән бәйләү татар көрәшенә бик тәңгәл килә. Бик күп көрәшчеләр килер, тамашачылар күп җыелыр дип көтәм. Иң мөһиме – гадел көрәш булсын. Тамашачының гайрәтен чигерерлек хәлләр булмасын иде. Әле бит быел Россия Чемпионатында чыгыш ясаячак команда Муса Җәлил турнирындагы җиңүчеләр арасыннан тупланырга мөмкин. Монысы да келәмдә кискенлекне арттырачак.

Әлмәт егетләре узган елгы турнирда сигезенче җиңүләрен яулады.

ТУРНИРДА ҖИҢГӘН КОМАНДАЛАР

Ел	Кубок иясе
1964	Сарман
1965	Буа
1966	Чистай
1967	Актаныш
1968	Актаныш
1969	Тукай
1970	Саба
1971	Тукай
1972	Түбән Кама
1973	Түбән Кама
1974	Түбән Кама
1975	Түбән Кама
1976	Түбән Кама
1977	Балтач
1978	Яшел Үзән
1979	Арча
1980	Балтач
1981	Балтач
1982	Балтач
1983	Балтач
1984	Балтач
1985	Мамадыш
1986	Мамадыш
1987	Чаллы
1988	Балтач
1989	Балтач
1990	Чаллы
1991	Балтач
1992	Чаллы
1993	Теләче
1994	Питрәч
1995	Чаллы
1996	Кукмара
1997	Зәй
1998	Чаллы
1999	Чаллы
2000	Балтач
2001	Әлмәт
2002	Балтач
2003	Балтач
2004	Киров (Казан)
2005	Балтач
2006	Мәскәү (Казан)
2007	Чаллы
2008	Вахитов (Казан)
2009	Чаллы
2010	Чаллы
2011	Әлмәт
2012	Әлмәт
2013	Әлмәт
2014	Әлмәт
2015	Әлмәт
2016	Зәй
2017	Зәй
2018	Зәй
2019	Теләче
2020	Теләче
2021	Әлмәт
2022	Әлмәт

60 ЕЛНЫҢ 60 МИЗГЕЛЕ


1964

1966

1968

1978

1980

БЕЗНЕҢ БАТЫРЛАР

Татарның иң көчле көрәшчеләре келәмгә чыгарга әзерләнә. Герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган бәйгенең 60 нчысы Казанда уза. Турнирның яңа сәхифәсен ачканда аның тарихын барлыйбыз, батырларын искә алабыз.

Иң элек тарихка күз салыйк. Татарның төп газетасы булган «Ватаным Татарстан» (ул елларда – «Соцалистик Татарстан») 1965 елда үзе уздыра торган көрәш ярышын Муса Җәлил исеме белән атый башлый. Гаҗәп түгел. Герой-шагыйрь 1920 нче елларда үзе дә безнең редакциядә эшли. «Бу миңа яшьтән үк әдәбият белән кызыксыну, журналларда, газеталарда әсәрләрем басылуны дәвам итү өчен шартлар тудырды», – дип яза ул соңрак. Димәк, редакцияне булачак шагыйрьнең тәүге эш урыны дип тә атый алабыз. Мәскәүгә күченеп киткәч тә, шигырьләре беренче тапкыр нәкъ менә әлеге газета битләрендә басыла. Бу гына да түгел. Редакциядә турнирга герой-шагыйрь исемен биреп, көрәшчеләрне рухи яктан тәрбияләүне дә максат итеп куялар, келәм батырлары Советлар Союзы Герое белән горурлансын, дип телиләр. Ярты гасырдан артык вакыт узган. Ә без бүген дә геройларыбызны барлыйбыз, бүген дә батырлык бик кирәк.

1964 елда узган тәүге турнирда нибары 11 команда катнашса, икенче елны бу сан 24кә җитә. Шулай итеп, көрәшчеләр дә, җиңүчеләр дә арта. Күп еллардан соң узган ел кабат Казанга әйләнеп кайткан бәйгедә 47 команда һәм 370 көрәшче катнашты. Әлеге турнирның кабатланмас традициясе бар: ярыш тәмамлангач, җиңүчеләрнең рәсемнәре газета битләрендә урын ала. Ә үзең турындагы язманы телефоннан оныкларга күрсәтүне күз алдына китерәсезме? Әле хәзер дә моннан 30–40 ел элек чыккан газетаны кадерләп саклаучылар барлыгын беләбез. Аерым көрәшчеләрнең генә үткәне түгел бу. Муса Җәлил бәйгесендә көрәшнең дә, хәтта татарның да ярты гасырдан артык тарихы чагыла. Көрәш – милләтнең аерылгысыз бер өлеше. Татар халкы булганда, көрәше көчсез була алмый.

Җиңүче исемен яулаган егетләрне барлап утырабыз. Шөкер, бик күп алар. Берничә мәртәбә җиңүчеләр исемлеге кыска түгел, тик батыр исемен кабат яулау җиңел бирелмәгән. 10 егеттән бары берсе генә икенче ел рәттән өстен чыккан еллар да булды. Бер җиңү дә – зур дәрәҗә. Бик күпләрнең келәмнән киткәч тә югалып калмавын, үз эшләрендә уңышка ирешкәнен күрәбез. Һәрберсе кайчандыр Муса Җәлил бәйгесендә җиңүе белән горурлана. Араларында җитәкче урыннарда, фәндә, авыл хуҗалыгында, бизнеста, башка өлкәләрдә дәрәҗә казанган шәхесләр бар. Әгъзам Гобәйдуллин, Фазыл Әхмәтҗанов, Рәшит Сәмигуллин, Марсель Таһиров, Хәлил Шәйхетдинов, Фәрит Шәйхетдинов, Хәйретдиновлар, Әхмәдиевләр һәм тагын бик күпләрнең исемнәре көрәш белән артык кызыксынмаган кешегә дә таныш. Димәк, көрәш ул сөлге тотып көндәшеңне җиңәргә генә түгел, тормышта да батыр булырга өйрәтә. Кайчандыр Муса Җәлил турнирын оештыручыларның тагын бер теләге әнә шул булгандыр дип әйтсәк, дөреслектән ерак китмәбез. Бүген батырларга көч-куәт теләп, бакыйлыкка күчкәннәренә догада булыйк!

Беренче турнирда командалар ярышын Сарман егетләре откан. Чөнки 4 җиңүченең икесе – шушы район егетләре. Аннары күчмә кубокны Буа егетләре, соңрак Чистай көрәшчеләре алып кайтып китә. Команда ярышында җиңүчеләр исемлегендә барлыгы 20 район һәм шәһәрне күрәбез. 59 турнирның 13ен Балтач егетләре откан. Чаллы командасы Кубокны 9 мәртәбә яулады. Әлмәт егетләренең 8 җиңүе бар. Алар бүген дә көрәштә алдынгылар сафында. Димәк, традицияләр дәвам итә.

Турнирның озын гомерле булуы «Ватаным Татарстан» газетасының гына тырышлыгы түгел, әлбәттә. Бүгенге заманда алай була да алмый. Татарстанның Көрәш федерациясенә, Спорт министрлыгына тагын бер кат рәхмәтебезне җиткерәбез. Ә быелгысы тәмамланып, берничә көн узуга, бәйгенең 61 нчесенә әзерлек башланачак. Муса, Җәлил турнирының гына түгел, көрәш тарихының да яңа сәхифәләре язылачак. Безгә көрәш кирәк, безгә батырлар кирәк!

Ихтирам белән,
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

«СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» БҮЛӘГЕ – ЧИСТАЙ БАТЫРЛАРЫНДА!

Әле беркайчан да татарча көрәш буенча республикабызда шундый зур ярышларның булганы юк иде. Казанда ике көн буена барган авыл спортчылары чемпионатында 32 командадан 121 кеше катнашты. Бу ярышлар быел «Социалистик Татарстан» газетасы тарафыннан билгеләнгән Муса Җәлил исемендәге приз өчен үткәрелде.

Иң элек җиңелчә (60 килограмм) үлчәү категориясенә күз салыйк. Бу үлчәүдә 28 батыр катнашты. Беренче әйләнештән үк лидерлар сафына Р. Бариев (Минзәлә), Хәмидуллин (Саба), М. Сәетшин (Сарман) чыкты. Дөрес, Бариевка өченче әйләнештә оттыру ачысын татырга туры килде. Ул 2 минут 30 секундта Хәмидуллинга җиңелде. Шулай да Минзәлә егете калган очрашуларда зур ихтыяр көче күрсәтте һәм беренче урынга чыкты.

Татарстанның җиңелчә үлчәүдәге чемпионы В. Сөләйманов (Аксубай) быел зуррак үлчәү категориясенә күчте. Ул җиңел (70 килограмм) үлчәүдә келәм тотты. Вазыйх 35 көрәшче арасында яңадан чемпион дип танылды. Ул бер-бер артлы К. Зариповны (Арча), Н. Васильевны (Октябрь районы), Р. Нуруллинны (Зеленодольск), Р. Фәсәховны (Әлмәт), З. Сәхаповны (Минзәлә), Р. Хисаметдиновны (Чистай) җиңде. Икенче урынга бу категориядә Р. Фәсәхов чыкты. Өченче призлы урын Р. Яруллинга (Аксубай) бирелде.

Сарман районы укытучысы Зөфәр Ханов – танылган батыр, көрәш ветераны. Ул да быел югарырак үлчәү категориясендә ярышты: урта үлчәүдә (80 килограмм) келәм тотты. Һәм яңадан спорт сөючеләрне үзенең осталыгы, тәҗрибәсе белән шаккатырды. Зөфәр биш очрашуда зур өстенлек белән җиңүләр яулады. Бары тик финалда Татарстан батыры Г. Хафизовка (Чаллы) гына оттырып, ул икенче призлы урынга иреште. Өченче урынга Н. Музагиров (Чаллы) чыкты. Республикабызның җыелма командасы члены, мастерлыкка кандидат И. Минһаҗов бу юлы дүртенче урын белән генә канәгатьләнде.

Авыр үлчәүдә 23 кеше катнашты. Беренче урынны дәгъвалаучылар арасында район Сабан туйлары батырлары бик күп иде. Күбесенең үлчәүләре 1000 килограммнан да артык иде. Арча районының Тукай-Кырлай колхозы члены Татарстанның абсолют батыры Рәдис Сәйфуллин (94 килограмм) аеруча уңышлы чыгыш ясады. Ул бер-бер артлы спорт мастеры Р. Гумеровны (Чистай), Г. Фәттаховны (Минзәлә), Мөхәммәтҗановны (Баулы), С. Шакировны (Саба), М. Фәхретдиновны (Лениногорск), Р. Хуҗинны (Чаллы), М. Гыйлаевны (Актаныш), Гайфуллинны (Чистай) җиңде. Рәдискә бу юлы да беренче бүләк бирелде. Икенче һәм өченче урыннарга чистайлылар Гайфуллин белән Гомәров чыкты. Буа районының «Цильна» колхозы члены М. Айзатуллов – дүртенче, Гыйлаев бишенче булдылар.

Командалар арасында Чистай районы көрәшчеләре иң аз штраф очколар алдылар һәм беренче урынга чыктылар. Аларга «Социалистик Татарстан» газетасының кыйммәтле күчмә кубогы тапшырылды. Икенче урында – Буа, өченче – Саба, дүртенче – Сарман, бишенче – Минзәлә, алтынчы – Актаныш командалары.

Чемпионат тәмамланган, авыл спортчыларының IV җәйге спартакиадасына йомгак ясалды. Җиңүче дип Баулы районы танылды, икенче урынга – Чаллы, өченчегә Октябрь районы спортчылары чыкты. Ярышларда иң зур массовыйлык өчен ВЛКСМ өлкә комитеты билгеләгән приз Питрәч районына бирелде. Республика спорт советы иң күп разрядлы спортчылар хәзерләгән Октябрь районына махсус приз тапшырды.

Дамир ШӘРӘФЕТДИНОВ,
ярышларның баш судьясы.
«Социалистик Татарстан». 7 декабрь, 1966 ел

«СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» БҮЛӘГЕ– ЧИСТАЙ БАТЫРЛАРЫНДА!

ФУТБОЛ БУЕНЧА СССР БЕРЕНЧЕЛЕГЕ
УЕННАРНЫҢ ЙОМГАКЛАУ ТАБЛИЦАСЫ
«А» КЛАССЫ (БЕРЕНЧЕ ГРУППА)

ХОККЕЙ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

«А» КЛАССЫ, ИКЕНЧЕ ГРУППА

Батырлык турында

Беләм, егет, синең җырыңда
Күп иленә сөю, якынлык.
Тик әйт: авыр сугыш юлында
Син күрсәттең нинди батырлык?

Син бастыңмы сафка, кыенлык,
Кайгы йөген илең тартканда?
Кыенлыкта күренә кыюлык,
Ил батырны сыный батканда,



Коткарырмы ялыну, елаулар,
Тоткын итсә дошман йөрәкне?
Буа алмас ләкин богаулар
Кылыч йөртә белгән беләкне!

Ни мәгънә бар эзсез яшәүдә,
Түбәнлектә, тарлык, кимлектә?
Яшәү хозурлыгы хөрлектә,
Гомер озынлыгы ирлектә.

Муса ҖӘЛИЛ.
Декабрь, 1943

...Авыл һәм район, шәһәр Сабан туйлары, Татарстан чемпионаты, РСФСР беренчелеге – әлеге ярышларның кайсы гына «Муса Җәлил призына көч сынашлары» белән тиңләшә ала? Быелтыр, мәсәлән, безнең ярышларда 42 командага керүче 300дән артык ир-егет бил алышты. Ә егерме биш ел дәвамында анда бил алышкан пәһлеваннарны санасаң...
«Социалистик Татарстан». 17 ноябрь, 1988

1985

1985

1986

1988

1989

60 ЕЛНЫҢ 60 МИЗГЕЛЕ

1989

1990

1990

1991

1991

КЕЛӘМДӘ – КАЛӘМ

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛИСТЛАРЫ ЯРТЫ ГАСЫРДАН АРТЫК КӨРӘШ СӘХИФӘЛӘРЕН БАРЛЫЙ

Хәтер-хатирә

...Дамир белән без педагогия институтындагы тарих-филология факультетында укыганда таныштык. Ул миннән берничә курска югарырак, татар мәктәпләрендә рус теле укытучылары әзерли торган бүлектә укыды, буш вакытларында баштарак «Динамо» спорт җәмгыятендә СССРның атказанган тренеры Николай Иванович Моряшичев төркемендә классик көрәш белән шөгыльләнде.

Республикада Милли спорт төрләре федерациясе оешкач (1960 ел), Дамир аны җитәкләргә алынды һәм бу җәмәгать эшен бик тә нәтиҗәле алып барды. Институттан соң «Татарстан яшьләре» газетасына чакырылып, андагы оборона-масса һәм спорт бүлегендә эшләгәндә, бу эзләнүчән егеткә бик тиз игътибар итеп, аны зуррак басмаларга чакыра башладылар. Һәм ул, яшьләр басмасындагы урынында үзе белән бергә укыган, бергә көрәшкә йөргән сабакташы Илгиз Минһаҗевны калдырып, партия газетасы «Социалистик Татарстан»га күчте, андагы спорт бүлеген җитәкләргә алынды. 1964 елдан бу газетаның герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә татарча көрәш бәйгесе үткәрелә башлау да аның тырышлыгына бәйле булды.

1971 елда безнең икебезгә дә Казан белән ике елга хушлашып торырга туры килде: Дамирны – Ленинградтагы партия мәктәбенә, мине Мәскәүдәге югары комсомол мәктәбенә укырга җибәрделәр. Укуыбызны тәмамлагач, икебез дә яңа урынга билгеләнүне көтеп, элек эшләгән урыннарыбызга әйләнеп кайттык.

1974 елда Дамир Рәүф улын КПССның Татарстан өлкә комитетына эшкә күчерүләре билгеле булды. Шул чакта газетаның редакторы Шәмси Хәбибулла улы Хамматов аннан: «Үз урыныңа кемне калдырырга телисең?» – дип сорагач, остазым мине тәкъдим иткән. Ул вакытта мин комсомол өлкә комитетының үзе укытып кайтарган яшь кадрны «Татарстан яшьләре»н җитәкләргә билгеләвен көтеп яшәвемә дә карамастан, бу тәкъдимне кабул иттем.

Баштарак мине тәрҗемә бүлегенә беркеттеләр. Ә 1975 елда редакциядә «Хәбәрләр һәм спорт бүлеге» оештырып, аны җитәкләргә куйдылар. Республикада, бигрәк тә аның башкаласында үтә торган вакыйгалар турында хәбәрләр әзерләп бирү белән бер үк вакытта газета призына электән үткәрелеп килгән атучылар, ишкәкчеләр һәм көрәш ярышларын оештыру, аларны югары дәрәҗәдә уздыру һәм, иң мөһиме, матбугатта матур итеп яктырту кебек бик тә җаваплы һәм саваплы мәшәкатьләр өстәлде.

Көрәшкә килгәндә, бу ярыш башлыча Казандагы Үзәк ял паркының бер читенә сыенган Югары спорт осталыгы мәктәбендәге залга җәелгән келәмдә уза торган иде. Бер карасаң, урыны да тыныч, келәм дә җәелгән, ә менә тамашачыларны күпләп чакыру мөмкинлеге юк: балконына, сыйса, 50–60 кеше сыяр.

Көрәш турында беренче «Батырлар – Түбән Камадан» дигән язмам, аерым үлчәү авырлыкларында мәйдан тоткан Наил Хәмидуллин (Саба), Наил Зәйнуллин, Данил Галиев (Түбән Кама), Михаил Чернов (Питрәч), Фидаил Шакиров (Балтач) һәм җиңүче команда (Түбән Кама) фоторәсемнәре белән бизәлеп, 1975 елның 15 октябрендә чыкты.

Спорт биографиямне йөгерү һәм чаңгыда узышу төрләре белән шөгыльләнеп башлаган булсам да, шушындый егетләр, көрәшчеләр, мәйдан батырларына килеп кушылгач, тәнемдә бабамнан килгән көрәшче каны уйный башлавын тойдым. Алар белән аралашу чорында туган уйларым, фикерләрем газета битләренә генә сыймыйча, тора-бара радио һәм телевидение тапшыруларына да кереп китте.

Бу бәйгенең баш судьясы булуны без гадәттә редакторыбыз – герой-шагыйребезнең иҗаты белән яхшы таныш булган, «Муса Җәлил – партия солдаты» дигән китап та чыгарган Шәмси ага Хамматовтан үтенә торган идек. Ул ризалык бирсә дә, аның көрәштәге вазыйфаларын күп очракта Казан ветеринария институтының физик тәрбия кафедрасы мөдире, көрәш буенча СССРның спорт остасы, РСФСРның атказанган тренеры, 1980 елда республиканың Татарча көрәш федерациясе рәисе итеп сайланган Мәгаз Мөбарәкша улы Сәхәбетдинов башкарды. Кайбер елларда аны Дамир Рәүф улының энесе – яшьтән үк классик көрәш белән шөгыльләнеп, үсмерләрнең ил беренчелегендә алгы урынга чыккан, СССРның спорт остасы, университетның биология факультетын тәмамлагач тренер булып эшләгән Рафаэль Шәрәфетдинов алыштырды. Ә ярышларны ачу һәм ябу тантаналарына герой-шагыйрьнең туганнары, язучылар, Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге бүләге ияләре булган артистлар белән бергә һәрвакыт редакторыбызның беренче урынбасары Рафак Шәех улы Тимергалин килеп йөрде.

Бу җаваплы да, мактаулы да, саваплы да бурычны, җиренә җиткереп, миңа унбиш ел дәвамында башкарырга насыйп булды. Үземә карата булган ышанычның, хөрмәтнең, ихтирамның артуын аеруча 1988 елда, көрәшчеләр мине Республика көрәш федерациясенең җитәкчесе итеп сайлап куйганда көчле тойдым.

Тырыша-тырыша тәҗрибә туплап, халыкта көрәшебез белән кызыксынуны тагын да арттыруга, тамашачыларыбызның саны елдан-ел күбәя баруга да ирешелде кебек. 1980 нче еллар уртасында «Органик синтез» заводының Химиклар мәдәният сарае белән янәшәдә, Г.Ибраһимов исемен йөрткән урамда көрәш корылмасы үсеп чыккач, ярышыбыз еш кына шунда узды.

Яши-яши, уйлаша торгач, бу бәйгене Казаннан чыгарып, районнарда үткәрү милли көрәшебезнең чикләрен киңәйтергә булышыр дип, без аны Чаллыда, Зәйдә, Балтачта, Чистайда, Кукмарада да оештыргаладык. Көрәшебезне яратучылар бәйгеләрнең берсендә финал өлешенең ике меңләп тамашачы катнашында циркта келәмдә узганын да хәтерли торгандыр. «Социалистик Татарстан» күрсәткән шундый үрнәк белән РСФСРның 1989 елгы көрәш чемпионатын Г.Камал театры сәхнәсендә уздыру да спорт тарихына кереп калырлык вакыйга дип билгеләп үтелде.

1990 елда Казандагы үзәк стадионга 25 мең тамашачы (бу инде парктагы залга килә торган 100 кеше генә түгел!) җыеп, «Илһам сезне кичке Сабантуйга чакыра» дигән көрәш һәм сәнгать бәйрәме оештыручыларның берсе дә безнең «Социалистик Татарстан» газетасы булды. Көрәш белгечләре бик тә хаклы рәвештә мәйдан тоткан батырларны машиналар белән бүләкләү шуннан кереп китте дип саный.

Газета призына ярышларның тарихына әйләнеп кайтсак, шул еллардан истә калган аерым хәлләр, вакыйгалар хәтеремдә әле дә яхшы саклана. Шуларның кайберләрен язып үтим әле.

...Сабаның гап-гади бер көтүче-терлекчесе – 1967, 1968, 1971, 1975 елларның җиңел үлчәүдәге батыры Наил Хәмидуллин, кызын үсеп килүче көрәшче егет Сәгыйть Гыйниятуллинга кияүгә биреп, үзе бу киявенең тренерына әйләнеп, аны ярышның җиңүчеләре арасына керерлек дәрәҗәгә күтәреп, аннары оныклары Илдар белән Фирзәрне дә бөтен Татарстанга танылган көрәшчеләр итеп тәрбияләүгә күп көч куйды.

...1977 елда 70 килога кадәрге көрәшчеләр арасында мәйдан тоткан Фәрит Әхмәдиев аннан соңгы елларда да яшьлек шөгыленнән аерылмыйча, Карадуган мебель фабрикасына җитәкчелек иткән елларда да үзләренең Балтач районы командасын 1980–1984, 1988–1989 елларда беренчелеккә чыгаруга булышып яшәде.

...1978, 1979 еллар бәйгеләрендә үз үлчәүләрендә җиңү яулаган абыйлы-энеле Вагыйз һәм Таһир Минһаҗевлар, ветеринария институтын тәмамлагач, үзләренең Арча районына кайтып эшли башладылар. Бертуганнарның кечесе үзен сәүдә эшендә танытса, олысы хуҗалык җитәкчесеннән район башлыгы дәрәҗәсенә кадәр күтәрелде, икътисадый үзгәреш чорында «ВаМин» компаниясен оештырып, соңрак Федерация Советында Татарстаннан сенатор булып торды.

...1978 ел ярышында җиңеп чыккан Яшел Үзән районы командасында Карагуҗа дигән авылдан килгән егетләр – физкультура укытучысы Фәрит Шәйхетдинов, шофер егет Госман Хөсәенов, педагогия институтында укып йөрүче Илгиз Гайнуллин, Ансар Галләмов белән бергә «Искра» күмәк хуҗалыгы җитәкчесе, соңрак министр урынбасары, район хакимияте башлыгы, Татарстан Президенты Аппараты җитәкчесе булачак Әгъзам Гобәйдуллин да көрәште.

...1980 нче елларда өч тапкыр республиканың баш батыры булып танылган Алабуга егете Фазыйл Әхмәтҗанов, көрәшеп туктагач, шәһәрдәге бөтен уңайлыклары булган куышын калдырып, туган авылы Мортыга әйләнеп кайтты, анда авыл хуҗалыгы кооперативы оештырып, матур гына идарә итә.

...1991 ел бәйгесенең 70 килодагы батыры – яңа оешкан Теләче районында физкультура-спорт оешмасын республикадагы алгы урыннарның берсенә чыгарган Олы Шыңар егете Хәлил Шәйхетдинов инде унбиш елдан артык спорт министрының беренче урынбасары буларак Казанны Россиянең спорт башкаласы итеп танытуга зур өлешен кертә.

Бу гасырга чыгып, башка редакцияләрдә дә эшләп, лаеклы ялга киткәч, республиканың һәм Россиянең Көрәш федерацияләре ярдәмендә язылган «Без – көрәшле халык» (2003), «Без – көрәшче халык. Родом из борьбы, Tatars – nation of wretslerst» (2009), «Саба егы көрәше» (2014), «Көрәш дөньясын шаулаткан батыр» (2020) дигән китапларыма мәгълүматлар туплап, республика, ил буенча йөргәндә дә миңа аларның байтагы белән очрашырга һәм бик күбесенең матур тормыш корып, үзләренең яшьлек шөгыле булган көрәшкә зур рәхмәтле булып яшәүләрен күрергә туры килде.

Илдус ИЛДАРХАНОВ,
Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре

Дамир Рәүф улы ШӘРӘФЕТДИНОВ
(12.09.1940 – 7.02.2014)

- Милли төр буенча РСФСРның спорт остасы.
- Татарча көрәштән Республика категориясендәге хөкемдар.
- «Татарстан яшьләре» һәм «Социалистик Татарстан» газеталары редакцияләренең бүлек мөдире.
- Татарстан Журналистлар һәм Язучылар берлекләре әгъзасы.
- Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре.
- «Татарстан» һәм «Гасырлар авазы – Эхо веков» журналларының баш мөхәррире.
- Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләге лауреаты.
- Россия Федерациясенең почетлы архивчысы.
- Тарих фәннәре докторы, профессор.

Бу исемнәрнең барысы да бер кешенеке. Ул газетабызның герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә узучы бәйгенең башында торган.

...Залда – тамашачылар арасында мин кайчандыр Сабантуй мәйданнарын шаулаткан, келәмдә җиңелү белмәгән өлкән яшьләрдәге башка көрәшчеләрне дә күрдем. Бүген аларга келәмгә чыгарга бераз кыюлык җитеп бетмәгәндер. Әмма ветераннар арасында бил алышуларның киләсе елларда да үткәреләчәген исәпкә алганда, без аларның күбесен келәмдә тагын күрербез әле...
«Социалистик Татарстан». 21 ноябрь, 1988

БЕРЕНЧЕЛӘРНЕҢ БЕРСЕ

Муса Җәлил бәйгесендә җиңгәндә, Зөфәр Ханов 40 яшен тутырган була инде. Ул – тәүге ярышта уңышка ирешкән дүрт батырның берсе. Бөек Ватан сугышын кичкән, Ленинград блокадасын өзүдә катнашкан, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән көрәшче безнең турнирда 1966 елда тагын бер мәртәбә уңышка ирешә әле.

Дүрт мәртәбә Татарстан чемпионы, күп Сабан туйларында батыр булып танылачак көрәшче егет Минзәлә районының Иске Мунча авылында туып үсә. Хәзерге вакытта Казанда яшәүче кызы Кифая ханым Нотфуллина сөйли: «Безнең бабайлар олы гәүдәле булган. Әти исә бизгәк белән авырып, бераз кечерәк калган. Әмма үзеннән күпкә зуррак кешеләрне җиңел генә селкеп ата иде. Хәзерге кебек, зур бүләкләр юк инде. Батыр исеме, дан өчен бил алышкан алар. Бабайлар да көрәшкән. Хәтерлим әле: Минзәлә районындагы бер авылның Сабан туенда туганыбыз Даут абый көрәшә. Көндәшен ега алмый азаплана. Бабай чыгып сөлгесен тартып та алды, «менә болай көрәшәләр аны» дип, тегенең көндәшен егып та салды».

Зөфәр Ханов гомерен балаларга белем бирүгә багышлый. Рус теленә дә өйрәтә, физик культура да укыта. Балаларны спортка тартырга тырыша. Шул арада келәм һәм чирәмдә дә җиңүләр яуларга өлгерә. «Якын-тирәдәге Ворошилов, Сарман, Мөслим, Минзәлә районнары Сабан туйлары батыры булды. Аннары Казанга барып көрәшә башлады. Җиңүләр яулап кайтуы белән тагын да илһамланды. Аннан күреп, энесе Рәшит тә яшьли көрәшкә кереп китте, 9 нчыда укыганда ук район батыры булды. Бертуган Хановларның даны 1960 нчы, 1970 нче елларда бөтен Татарстанга таралды. Олыгаеп, яшьләр белән тартышу авырая башлагач, Зөфәр ага улы Русланны ияртеп, Сабан туйларына килеп чыгар иде дә, көрәшеп, гер күтәреп, бүләкләр җыеп, дәртен басып кайтып китәр иде. Хәтта 70кә җиткәндә дә ул Минзәләдәге Күзкәй авылында көрәшкә чыгып, баш батырга билен бирмәде», – дип яза журналист Илдус Илдарханов «Без – көрәшле халык» китабында.

Инде ярышларда катнашмый башлагач та, келәмнән ерак китми ул. Үзе язган шигырьләрне укый-укый, бәйгеләрне алып бара. 60 яшендә «Татарстанның атказанган физик культура хезмәткәре», соңрак «Татарстанның атказанган спорт остасы» исемнәренә лаек була. Кызганыч, гомеренең соңгы еллары авыр була. «Йөгереп йөргәндә үләм, дип сөйли иде ул. Тик башканы язган икән шул. Урман кискәндә, өстенә агач төшеп, урын өстенә ятты. Бик интексә дә, анда да бирешмәскә тырышты», – дип искә ала кызы Кифая исеме тарихка кереп калган әтисен.

Беренче батырлар (1964 ел):
Зөфәр Ханов (Сарман), Габдулла Ямалов (Сарман), Талип Яруллин (Әлки), Габдулла Хафизов (Чаллы)



Зөфәр Ханов 1980 нче еллар батырларын келәмгә алып чыга.

1994

1995

1996

1998

1999

60 ЕЛНЫҢ 60 МИЗГЕЛЕ

2000

2000

2000

2000

2001

Муса Җәлил турниры ул – ...

Рәкыйп ФӘЙЗУЛЛИН,
Россиянең атказанган тренеры (Чаллы):
– Әлеге турнир – минем бөтен тормышым ул. Без егет чакта көрәшкә күбесенчә татар районнарында игътибар бирелә иде. Безнең якларда (Рәкыйп Фәйзуллин тумышы белән Минзәлә районыннан. – **Авт.**) менә шул җитеп бетми иде. Чаллыга күченгәч, көрәшне үзебез күтәрә башладык. Гомумән алганда, Чаллы командасы Муса Җәлил турнирына соңрак килеп кушылды. Шулай булуга карамастан, күчмә кубокны күп тапкыр яуларга насыйп булды безгә. Турнирның 12сен Чаллыда уздырдык. Кыскасы, турнир тарихында эзебез шактый тирән. Җәлил турниры – безнең көрәшнең тарихы ул. Татарның асыл егетләре, чын ир-атлар нәкъ менә шушы ярышта тәрбияләнә.

Габбас ӘХМӘДИЕВ,
бәйгенең 2 мәртәбә җиңүчесе (Түбән Кама):
– Татар көрәше дөньясында иң зур турнир ул. Муса Җәлил истәлегенә уздырылучы ярышларга ел саен ким дигәндә 45 команда җыела. Аны откан кешегә кызыгып, хәтта көнләшеп карыйлар. Минемчә, Татарстан беренчелегеннән дә зуррак җиңү бары Җәлил турнирында гына була ала. Аның бу кадәр дәрәҗәле булуы, беренче чиратта, каһарманыбыз Муса Җәлил исемен йөртүенә бәйле. Ике ел элек без бу ярышларны Минзәләдә уздырдык. Сугышка китәр алдыннан Муса Җәлилнең Минзәләдә хәрби әзерлек үткәне билгеле. Шуңа да без көрәш ярышлары алдыннан аның һәйкәленә чәчәкләр салып, бу чараны бик зурлап уздырдык. Башка бер ярышны да бу кадәр зурлап уздырмыйлар. Бик истәлекле, хәтта гыйбрәтле турнир да әле ул. Бу турнирны мин Муса Җәлил генә түгел, көрәш мәйданында һәлак булган бабаларыбыз һәм башка милләттәшләребезнең батырлыгын һәм хәтерен мәңгеләштерү чарасы буларак та кабул итәм.

Ренас КӘЛИМУЛЛИН, көрәшче,
бәйгенең 7 мәртәбә җиңүчесе (Теләче):
– Муса Җәлил истәлегенә уза торган көрәш турниры – иң зур һәм мәртәбәле ярышларның берсе. Анда катнашу – һәр көрәшче өчен зур дәрәҗә. Мин аны Татарстан беренчелеге белән чагыштырам, чөнки бу турнирны оту бер дә җиңел түгел. Әмма рейтинг буенча Муса Җәлил турниры Татарстан чемпионатыннан да популяррак. Аны күбрәк карыйлар, аның белән күбрәк кызыксыналар. Бу турнирга иң көчле көрәшчеләр җыела. Көндәшлек тә зур: барысы да җиңәр өчен килә бит. Минем тәүге тапкыр батыр калган зур ярышым да Муса Җәлил турниры булды. Шуның белән кадерле ул миңа. Анда җиңгәч, тора-бара Татарстан беренчелеген, башка ярышларны да ота башладым. Әле дә исемдә: мәктәптә укыган чакта махсус әлеге турнирны карарга дип Чаллыга бара идем. Көрәшчеләргә бик сокланып кайтканымны хәтерлим. Анда җиңүчеләр чын геройлар кебек тоелды. Мин дә кайчан да булса алар урынында булырмын дип хыяллана идем. Һәм шулай насыйп булды да. Быел, Алла боерса, сигезенче тапкыр батыр калырга дип киләм. Бу ярышны барыбыз да көтеп алып, сагынып киләбез. Башка мондый турнир юк.

Алсу ГАЛИМОВА, турнирда 9 мәртәбә җиңгән мәрхүм көрәшче Ильяс Галимовның тормыш иптәше:
– Әлеге турнир Ильяс өчен бик кадерле, мәртәбәле һәм җитди ярыш иде. Дөнья чемпионатына әзерләнгән кебек әзерләнде ул аңа. Гомумән, бу турнир гаиләбез өчен дә әһәмиятле иде. Беренче елларда Ильясның ярышларын калдырмадым диярлек, шактый турнирларны күрергә насыйп булды. Ул чактан ук Муса Җәлил турниры шундый матур һәм зурлап уздырыла торган чара булып истә калган.

Радик СӘЛАХОВ, көрәшче,
бәйгенең 3 мәртәбә җиңүчесе (Лаеш):
– Минем өчен бу турнир – ел саен көтеп ала торган зур вакыйга, иң данлыклы һәм көчле ярышларның берсе. Бәләкәй чакта әти белән махсус, Муса Җәлил турнирын карарга дип, Чаллыга бара идек. Шулкадәр матур итеп көрәшкәннәре истә калган. Тәүге тапкыр бу турнирда 2011 елда, нәкъ менә Чаллыда узганында катнаштым. Миңа ул вакытта 17 яшь иде. Беренче әйләнештә үк җиңелдем. Алай да минем өчен зур тәҗрибә булды ул, хәтта җиңелүем дә алга таба яхшы этәргеч бирде. Муса Җәлил турниры – җаваплы һәм җитди ярыш. Беренче җиңүемне ничек көтеп алганымны белсәгез! Шундый зур дәрәҗәдәге турнирда откач, горурлык хисе биләп алды. Дөнья чемпионатында откан кебек бу, ышанырлык әйбер түгел. Быел да, һәрвакыттагыча, ныклап әзерләнәбез һәм җиңәргә дип киләбез.

Рузил ГАНИЕВ, Әлмәт командасы тренеры,
бәйгенең 3 мәртәбә җиңүчесе:
– Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш турнирында еллык нәтиҗә ясала, якын-тирәдәге төбәкләрдән дә катнашучылар килә. Шуңа да без аңа ел саен ныклап әзерләнәбез. Нинди генә чорда яшәсәк тә, зур, дәрәҗәле турнир булып кала бирде ул. Миңа калса, көрәш ярышларының иң көчлесе, иң матуры! Көрәшкән вакытта Муса Җәлил турнирына Татарстан беренчелегенә әзерләнгән кебек әзерләнә идек. Аны оту – чын мәгънәсендә, зур титул чөнки. Бу ярышларда беренче тапкыр 2002 елда катнаштым. Ир-атлар арасында көрәшә башлаган вакыт. Азарт көчле! Минем белән бер үлчәү авырлыгында спорт осталары да бар иде, аларны җиңеп карыйсы килде инде. Ул елны дүртенче урында калдым. Ләкин бу да үзенә күрә зур нәтиҗә иде. Шул ярыштан соң әкренләп җиңә башладым.

КӨРӘШ БӘЙРӘМЕ

Батыр, ярышларны оештыручы һәм тамашачы. Татарстан спорт министрының беренче урынбасары, атказанган спорт остасы Хәлил ШӘЙХЕТДИНОВ Муса Җәлил бәйгесенә өч яктан мөнәсәбәте турында сөйли.

Җиңү тәме турында

Әлеге бәйге башкаларыннан аерылып тора. Мин – 1984 еллардан бирле көрәшеп йөргән егет. Турнир, аның тарихы шул вакыттан бирле күңелгә кереп калган. Аеруча безнең кебек авыл малайларының күңеленә. Ул вакытта «Социалистик Татарстан» газетасы һәр йортка килә. Һәр бәйгедән соң анда җиңгән батырларның рәсемнәре басылып чыга. Шул батырлар кебек буласы килде. Бу бәйгедә 1991 елда 70 килолы егетләр арасында җиңүче булдым. Рәсемем басылып чыккан газетаны әле дә кадерләп саклыйм. Шөкер, ул елны студентлар бәйгесеннән алып, Казан беренчелеге, Татарстан һәм Россия чемпионатларына кадәр – катнашкан ярышларның барысында да җиңеп чыгу бәхете елмайды. Ул вакытта Муса Җәлил бәйгесе, һичшиксез, иң титуллы бәйге саналды. Бәлки, яшь көрәшчеләр хәзер Татарстан чемпионатын өстенрәк күрәдер. Анысы бит Россия чемпионатына чыгу мөмкинлеге бирә. Ә бәлки, герой-шагыйрь исемен йөрткән бәйгенең дәрәҗәсе тагын да күтәрелгәндер. Бүген ватанпәрвәрлек төшенчәсенең әһәмияте тагын да артты.

Тарих һәм бүгенгебез турында

Кызганыч, яшь буын тарихны белеп бетерми. Шул исәптән, Муса Җәлилне һәм аның батырлыгын да. Яшь көрәшчеләрдән сораштырам – кистереп әйтә алмыйлар. Федерациябез җитәкчесе Марат Әхмәтов бәйгене ачу тантанасының мәгънәсе, эчтәлеге булсын дип шарт куя. Шагыйрьнең шигырьләрен укыйлар, образын күрсәтәләр. Тамашачы да, көрәшче дә үзенә күпмедер мәгълүмат ала, аз булса да уйлана башлый. Татар халкы Җәлил кебек геройлары булу белән дә бәхетле. Үзебезнең көрәш аркылы аның исемен зурлый һәм таныта алабыз. Бу – бик зур эш.

Батыр булу турында

Мәгънәсен аңлыйлардыр, дип уйлыйм. Кеше элек буш вакытында кулына сөлге алган да көче һәм таланты белән җиңүгә ирешкән. Хәзер бу гына җитми. Һәрдаим шөгыльләнергә, физик яктан әзер булырга кирәк. Хәтерлим әле: Теләче районында беренче булып ярышлар алдыннан махсус әзерлек җыеннары уздыра башладык. Хәзер андый тәҗрибә башкаларда да бар. Батыр булу элек тә дәрәҗә саналган, хәзер дә шулай. Бәлки, матди хәлен яхшырту өчен, җиңүче исемен акчага алмаштыручылар да бардыр. Әмма гомерләр узгач, моның өчен үкенергә туры киләчәк.

Быелгы фаворитлар турында

Командалар ярышында лидерларның берсе – Лаеш командасы. Һәр авырлык категориясендә көчле көрәшчеләрне тупладылар. Казанның Яңа Савин районында, Теләче, Әлмәт, Чаллыда көчле командалар бар. Кукмара, Арча, Балтач та калышмаска тырыша. Күп нәрсә беренче әйләнештә лидерларның ничек чыгыш ясавына бәйле булачак. Батыр алмашына. Чөнки хәзер һәр категориядә батыр калырлык бишәр егет бар. Тамашачының исә – үз фәлсәфәсе. Аларның Раил Нургалиев, Радик Сәлахов, Ренас Кәлимуллин кебек чемпионнарның җиңелгәнен күрәсе килә. Көрәшченең, әлбәттә, җиңәсе килә. Элек дип сөйләшәбез дә, ул вакытта җиңүчеләр физик яктан башкалардан аерылып торган. Чыккан да салган көндәшен, чыккан да еккан. Хәзер алай гына булмый. Тактик яки техник осталыкларын чарлап җибәрәләр дә теләсә кемгә көндәш була алалар. Көче тигез булган егетләр бил алышканда, хөкемдарларга да авырга туры килә. Шуңа күрә судьялык итү буенча фикерем мондый: җиңгән егет – отканын, җиңелгәне үзенең оттырганын аңларлык булырга тиеш. Берсенең күңеле булсын, икенчесе өчен үкенечкә калмасын.

Өмет турында

Егетләр башка ярышлардагы кебек үзләре генә түгел, командаларын өскәрәк күтәрү өчен дә бил алыша. Монда бердәмлек бик мөһим. Егетләр чын, гадел көрәш күрсәтерләр, алыш-биреш ише әйберләр булмас, дип көтәм. Алар шуны аңларга тиеш: көрәшче гомере озын түгел. Әле җитмәсә, пандемия кебек авырлыклар аша кичтек. Аллаһы Тәгалә дә аларга сынаулар биреп тора. Үкенмәслек итеп бил алышырга кирәк. Тамашачы буларак кызыклы көрәш көтәм. Ә оештыручы буларак безнең бурыч – күбрәк тамашачыны җәлеп итү. Бу – бик зур бәйрәм. Муса Җәлилне дә искә алабыз, яраткан көрәшебезне һәм көчебезне дә күрсәтәбез. «Ватаным Татарстан» редакциясенә рәхмәт: бу бәйгене авыр елларда да саклап кала алды. Гомерләр узар, ә күпләребезнең сандыкларында бу газеталар сакланыр.

ТРЕНЕРЛАР:
«БАЛАГА ИКЕНЧЕ ӘТИ БУЛЫРГА КИРӘК»

Орчык кадәр сабыйны да, 150 килога җиткән дәүләрне дә кулыннан тотып алар алып чыга келәмгә. Бүгенге көрәштә Аллаһы Тәгалә биргән көч вә талант янына аларның ярдәме һәм киңәше дә кирәк. Тренер – спортчы өчен әти дә, дус та, сердәш тә, кумир да. Кечкенәдән тәрбия, дисциплина, зурларга һәм бер-береңә хөрмәт дигән төшенчәләрнең кыйммәтен дә спорт залларында өйрәтәләр.

Көрәшчене чемпион итү җиңелрәкме, әллә инде кеше буларак тәрбияләүме? Ничек бу заманда балаларга чын батырлыкның нәрсә икәнен аңлатырга? Әлеге сорауны тренерларның үзләренә бирдек.

Казанның Авиатөзелеш районында көрәш буенча тренер Илһам Волков:

– Икесе бергә барырга тиеш. Көрәшче булгач, кеше тәртиплерәк була, чөнки көрәшчеләрдә дисциплина бар. Дисциплина юк икән, чын көрәшче булу мөмкин түгел. Чөнки алар безнең күз алдында, подъездда тәмәке тартып басып тормый. Без 1990 нчы елларда урамнан саклап калган балаларның хәзер үзләренең балалары үскәндер инде. Залга килгәч, бөтенесен дә өйрәтәсең.

Балалар да төрле. Кайбер бала көрәшергә дип йөрми, аңа аралашырга кирәк. Әти-әнигә бөтенесен дә сөйләп бетереп булмый. Тренер алдында ачыла кайберләре. Авыр тормышта яшәүче балалар да күп. Кайберсе әнисе, әбисе белән генә тора, күпбалалы гаиләләрдә тәрбияләнүчеләр бар. Кайвакыт кәефләрен дә күтәреп җибәрергә кирәк, бер төрле генә булмый бит алар. «Ташлыйм» диючеләр дә бар. Алар белән аерым сөйләшәбез.

Хөрмәт итү исә кешенең характерыннан да киләдер. Аннары үзеңне ничек тотасың, балалар да үзләрен синең кебек тотарга, синең кебек булырга тырыша.

Түбән Каманың «Шинник» спорт комплексында көрәш тренеры Илнар Гәрәев:

– Һәрбер балага аерым якын киләсең. Аларны мактарга, аларга икенче әти булырга кирәк. Зурларны бер яктан башларыннан сыйпыйсың, икенче яктан әзрәк сүгеп тә аласың. Кеше тәрбияләүме, чемпион ясаумы – авыр сорау. Ул кешенең үзеннән тора. Үзеннән булмаса, син ни генә эшләсәң дә, нәтиҗәсе булмый. Кеше итеп бәләкәйдән тәрбияләргә кирәк. Өйдәге тәрбия дә бик мөһим. Өйдә балаларны «бала» дип, без аларны «спортчы» дип тәрбиялибез. Шушы ике тәрбия булмыйча гына җиңүче булганнар бик сирәк. Без аларны «безбашенный» дип атыйбыз.

Чемпионнар булып җиткәч, хөрмәт итә башлыйлар. Хәер, исәнләшә белмәүчеләре дә очрый. Өйдә тренерларга хөрмәт дигән тәрбия юк икән, Россия чемпионнары да исәнләшмәскә мөмкин. Кайбер чемпион булмаганнары әллә каян йөгереп килеп: «Абый, исәнмесез», – дип кул суза.

Әлмәт районында көрәш тренеры Рузил Ганиев:

– Безнең үзебезгә тренерлар авторитет иде. Аларның спорт осталары булып, зур җиңүләргә ирешүләре үрнәк булды. Хәзер үзебезне – Фәнил Минһаҗевны да, Руслан Нургалиевны да, мине дә балалар авторитет итеп күрә. Кайбер вакытта әти-әниләр шалтыратып: «Безне тыңламыйлар, сезне беренчерәк күрәләр. Шуны яки тегене эшләргә кирәген аңлатыгыз әле», – диләр. Кайберләре башта безнең белән киңәшләшә.

Балаларның төрлесе бар. Бик тыңламаганнары булмаса да, шуклары бар. Тыңламаучыларның нәтиҗәләре яхшырак та булгалый әле кайчак. Көрәшкә авыр гаиләләрдән булган, ятим калган балалар күп йөри. Аллаһы Тәгалә бирә үзләренә.

Кеше булсыннар, тәрбияле булсыннар, дип тырышабыз. Тәрбия дигәндә хөрмәт төшенчәсе дә бар. Балалар безне хөрмәт итә. Үзебезнең дә, аларның дәрәҗәләрен төшереп, түбәнсетеп сөйләшкән юк. Яшьтәшләре кебек сөйләшәбез, хәлләренә керергә тырышабыз. Шаяртасы җирендә шаяртасың, кирәк чакта ачуланасың.

Безнең нәкъ менә чемпион ясау дигән максат юк, иң мөһиме, кеше булсын. Без 50 процент өлешне кертәбез, калган 50се – алар кулында. Кемдер без кушканнардан соң да өстәмә шөгыльләнә, шулай итеп уңышка ирешә. Кемдер ялгыша: тәмәке, хәмер кабып караучылар да, бик сирәк булса да, булгалый. Без аңлатып, төзәтеп карыйбыз. Әлбәттә, анысы балалар арасында, зурларга күчкәч, аларны контрольдә тотып бетереп булмый. Шулай да юнәлешне күрсәтәбез.

Батырлык дигәндә, соңгы ярышларның берсендә атказанган көрәшчеләрнең гадел көрәшмәве, бер-берсенә билен бирүе канымны кыздырды. Миңа: «Абый, нигә шулай итәләр?» – дип балалар үзләре яза. «Бу – оят, дөрес эшләмиләр. Без беркайчан да алай сөйләшмәдек, көрәштек, сез дә алай эшләмәгез», – дип аңлатабыз. Балалар башларын селкеп торалар. Безнең балалар «договорняк»ларны өнәми, аларның чынлап җиңәселәре килә.

Энҗе ГАБДУЛЛИНА

РСФСРның милли төрләр буенча спорт остасы, Татарстанның атказанган тренеры Гайнетдин Мөхәммәдиев. Көрәш дөньясында танылу алган бу шәхеснең кулы астында шөгыльләнеп, 68 егет РСФСРның милли төрләр буенча спорт остасы исеменә лаек була. 32се Татарстан һәм Россия чемпионнары була. Бик күпләре «Гайни абый» киңәшләре ярдәмендә Муса Җәлил бәйгесендә җиңү яулый.
Гайнетдин Мөхәммәдиевкә һәм әле бүген дә көрәш серләренә өйрәтүче остазларга сәламәтлек насыйп булсын! Бик күп батырлар тәрбияләгән Мәгаз Сәхәбетдинов, Әсгать Шәйхетдинов, Илгизәр Димиев, Миннәхмәт Мөхәммәтҗанов һәм башкаларның урыны җәннәттә булсын!

...Кичә Казанның «Динамо» спорт залында татарча көрәш буенча «Социалистик Татарстан» газетасы билгеләгән Муса Җәлил исемендәге призга авыл спортчыларының республика ярышы башланды. Анда Татарстанның 30 җыелма командасы катнаша. Моңарчы безнең республикада көрәш буенча мондый массовый ярышларның үткәрелгәне юк иде әле...
«Социалистик Татарстан», 2 декабрь, 1966

2001

2002

2002

2003

2003


2004

2005

2006

2007

2008

ӘҮХӘТ МӨХӘММӘДИЕВ:

«ҺӘР КӨРӘШЧЕДӘН ХӨКЕМДАР ЧЫКМЫЙ»

«Егетләр, тынычлык! Әүхәт абый микрофонны алды». Бу сүзләрне көрәш ярышында еш ишетергә була. Келәмдәге көрәшчеләр, хөкемдарларга төрле сүзләр юллаган тамашачыларны Әүхәт абый бер карашы белән тынычландыра ала. Аңа көрәшчеләр хөрмәт белән карый.

Әүхәт Мөхәммәдиев 1981 һәм 1984 елда герой-шагыйрь Муса Җәлил исемендәге турнирда авыр үлчәүдәге көрәшчеләр арасында җиңүче була. Ул Татарстанның ике тапкыр баш батыры булып таныла, 1982 елда авыр үлчәүдә Россия чемпионы булып кала. Кама Тамагы, Тәтеш районы авыллары, Казанның Идел буе һәм Киров районы Сабан туйларының баш батыры.

– 1980 нче елларда ике зур турнир бар иде – Муса Җәлил турниры һәм Татарстан беренчелеге. Муса Җәлил турнирын отсак, Олимпиаданы откан кебек була идек. Ул җиңү – безнең чор көрәшчеләре өчен бик зур дәрәҗә саналды. Шушы ике турнирда җиңү өчен бик күп тир түгәргә кирәк иде, – дип искә ала көрәшеп йөргән яшьлек елларын Әүхәт абый Мөхәммәдиев. – Ул чактагы батырлар хәзер көрәш мәйданына чыкса, бүгенгеләргә берсе дә сер бирмәс иде. Безнең буын акча өчен дә, кыйммәтле бүләк өчен дә түгел, исем өчен көрәште. Матур лента, значок, диплом бирәләр иде. Шул бүләкләргә бик зур канәгатьләнү кичереп, шатланышып кайтып китә идек.

Кама Тамагы районында балаларга көрәш серләрен төшендерә ул. Балаларга белем бирү аерым хөрмәткә лаек. Фикерене нык: «Татар бетмәсә, көрәш бетми, ә татар беркайчан да бетәчәк түгел».

Хәзерге көндә Әүхәт абый – күп кенә республикакүләм көрәш ярышларының баш хөкемдары яки баш хөкемдар урынбасары. Хөкемдарлык эшенә аны яшьлек дусты, «Ак барс» көрәш сарае директоры урынбасары Фәрит Шәйхетдинов алып керә. Баштагы елларны келәмдә ян-як хөкемдар булып эшли Әүхәт абый.

– Фәрит – минем көрәш буенча коллегам, якын дустым, бик тыныч, бик төгәл, мәрхәмәтле кеше. Без аның белән матди яктан түгел, фикер ягыннан дуслар. «Әйдә әле, Әүхәт, эшләп кара әле», – дип, мине хөкемдарлыкка да ул тартты. Хөкемдар булып эшләүдә зур этәргечне Көрәш федерациясенең элекке башкарма директоры, мәрхүм Равил Хәйруллин бирде. Ул миңа хөкемдарлыкны һәрвакыт ышанып тапшыра иде, – дип сөйли ул. – Яхшы хөкемдар булыр өчен нишләргә кирәкме? Сеңлем, һәр көрәшчедән хөкемдар чыга алмый. Хәтта танылган батыр булсаң да. Икесе дә туры килгән очраклар бик сирәк. Хөкемдарлык – авыр эш.

Хөкемдарны үстерү өчен, аны иң беренче ян-як хөкемдар итеп утыртырга кирәк. Аннары келәм хөкемдары итәргә, берничә елдан соң өстәл янына келәм җитәкчесе итеп утыртырга кирәк. Шулай иткәндә генә хөкемдар үсә ала. «Бу – безнең бик яхшы көрәшче», – дип, аны шунда ук йә келәм хуҗасы, йә баш хөкемдар ярдәмчесе, йә бөтенләй баш хөкемдар итеп кую дөрес түгел. Ул барысына да этаплап барырга тиеш. Шул очракта гына безнең көрәштә югары квалификацияле хөкемдарлар үсеп чыгачак.

:: Сезне усал хөкемдар, диләр. Хөкемдар нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?

– Хөкемдар усал булырга тиеш түгел. Аңа тәвәккәл булырга кирәк. Кагыйдәләрне белергә, ишарәләрне дә дөрес итеп күрсәтергә, келәмдә йокламаска кирәк. Аның өчен «синеке – минеке»ләр булырга тиеш түгел. Көрәшчеләргә һәммәсенә дә гадел итеп карасаң, сине һәрвакыт

хөрмәт итәчәкләр. Көрәшче белән хөкемдар арасында ара булырга тиеш. Матур итеп киенүе, үз-үзен дөрес тотышы, тәртипле, чиста булуы да мөһим.

:: Татар көрәшендә хөкемдарлык итүнең нинди кыенлыклары бар?

– Булды шундый еллар: район җитәкчеләре, хөкемдар янына килеп, күкрәк кагалар, ду киләләр иде. Беләләрме алар, юкмы, анысы алар өчен мөһим түгел. Ул вакытларда бик авыр булды. Соңгы елларда андый хәлләр күзәтелми. Район җитәкчесенең районда – үз эше, хөкемдарларның келәмдә – үз эше. Без бит аларның эшенә тыгылмыйбыз, алар да безнең эшкә тыгылмасын иде. Хөкемдарларның берсенең дә үз вөҗданнарына тап төшерәселәре килми.

Хөкемдарларны укыталар, семинарлар да узып тора. Безнең бөтен ялгышлыкларны безгә күрсәтәләр. Үзең җибәргән ялгышлыкны тану да – батырлык. Дүрт аяклы ат та абына, дибез бит. Тик хөкемдар ялгышты, дип, аны сөбереп түгәргә, әшәке сүзләр кычкырырга ярамый. Хөкемдарлар да, көрәшчеләр дә – һәммәбез дә шул татар көрәшеннән чыккан кешеләр. Берәүләр килә, икенчеләр китә.

:: Иң зур батырлык нәрсә ул?

– Кечкенә чакта иң зур батырлык – авыл Сабан туен отып, тәкә алу. Батырлык безнең гадәти тормышта да күп бит ул. Кайбер кеше үзенә авыр булса да, иптәшләренә булыша, ятим балаларга, картларга ярдәм итә. Бер белмәгән кешеләргә дә булышасың бит кайвакыт. Эшеңне яхшы итеп башкару, туган илеңне яклау – һәммәсе минем өчен батырлык. Кешелекле булу, кешегә ярдәм итү – дөньядагы иң зур батырлык.

Энҗе ГАБДУЛЛИНА

КЕЛӘМНЕҢ ТЕГЕ ЯГЫ

Көрәшче – кем ул һәм ни өчен көч түгә, тир агыза? Көрәш җанатары, үзе дә сөлге тотуның җаен һәм тәмен белгән Рөстәм ЗАРИПОВ фикерләре.

Көрәш ул – спорт төре генә түгел. Мин аны милли сәнгатебез, җыр-биюләр, милли кием, милли ашларыбыз, традицияләребез белән янәшә күрәм. Алар барысы да татарның миллилеген, гореф-гадәтен саклап кала. Көрәшебез көчле, үзенчәлекле, кешене кызыксындырырлык булса, милләтебез яши дигән сүз. Хәзерге вакытта милли спортыбызга игътибар җитәме? Юк! Барыбызның да игътибары кирәк.

Спортыбызның миллилеге телгә күбрәк бәйле, үзебезне тәрбияләүче бер корал булсын иде. Әйтик, шигарь тәкъдим итәм: татар малае бер тапкыр булса да кулына сөлге тотып, көрәшеп карарга тиеш. Әлбәттә, бу бөтен кешегә дә спорт залларына йөрергә дигән сүз түгел. Сабан туйларында кечкенә генә келәм куелса, бөтен килгән кеше, олымы ул, кечеме, бер-берсе белән тотынышып, көрәшеп карап, ничек икәнен белеп, кечкенә генә бүләген алып кайтып китсә, әти-әниләр дә, балалар үзләре дә моңа сөенер иде.

Батыр ул – халык ихтирамын яулаган милли көрәшче. Ничә ел рәттән чемпион булган, рекордлар куйган, бөтенесен җиңеп чыккан кеше батыр булды дигән сүз түгел әле. Бәлки, кайсыдыр көрәшче чемпион да булмагандыр, әмма аның көрәше халыкның күңеленә кереп кала. Җиңүне бит төрлечә яуларга була. Хәрәмләшүчеләр дә очрый, очраклы рәвештә көндәшләрнең имгәнүе дә. Ә минә иң авыры – халык ихтирамын яулау.

Кайсы гына өлкәне алсак та, кешеләрнең якынча 20 проценты – хейтерлар, ягъни барына канәгать булмаган кешеләр. Алар барыбер гаебен, ошамаган ягын табачак. Тагын 20 процент чамасы, киресенчә, һәрвакыт канәгать, кимчелекләр булса да, гаеп итми. Болары – фанатлар, аерым көрәшчеләрнең җанатарлары була инде. Калган 60 проценты – нейтраль як. Ул көрәшне карарга да, карамаска да мөмкин. Ничек тә менә шуларны җәлеп итәргә иде бәйгеләргә.

Бу исә – батырларның да эше. Көрәшү генә түгел, ә халыкның хөрмәтен яулау, халыкны мәйданнарга җәлеп итү. Моның өчен егетләребезгә үз фикерен әйтә белергә, кирәк булганда аңлатып бирергә дә өйрәнәсе бар әле. Хөрмәтне дә, ышанычны да арттырачак анысы.

Халыкка безнең көрәшнең фәлсәфәсен аңлатырга кирәк. Ул бит ике кеше сөлге тотып көрәште дә, берсе җиңде, ә икенчесе җиңелде дигән сүз түгел. Тирәндәрәк аның мәгънәсе. Әтиең, абыең, энең, дустың белән бил алышып, үзеңне чыныктырасың, көчеңне арттырасың. Ул гына да түгел. Кочаклашып, билен тотып көрәшкәнсең икән, ул синең ышанычлы кешеңә әверелә. Көрәш ул – көч түгеп имгәнү өчен түгел, киресенчә, көчеңне арттыру өчен уйлап табылган спорт төре. Һәм ул безнең милләтнеке. Башка төрләрдән аермалы буларак, безнең көрәштә көндәшне екканчы, башта күтәреп алырга кирәк. Кагыйдәләрне үзгәртеп, берара әнә шул асылын бетерә дә яздылар. Безнең көрәш авыр һәм шул алышта җиңү һәм халыкның хөрмәтен яулау чын батырлык була инде. Чын көрәш – батырларны, ә чын батырлар көрәшне үстерә.

Җанатар буларак, мин кискен көрәш, көтелмәгән нәтиҗә, яңалык һәм көрәшчеләрнең тамашачыга ихтирамын көтәм. Яңалык халыкны һәрвакыт җәлеп итә. Шуңа күрә чемпионнар көрәшкәндә, күп очракта нейтраль тамашачылар аның көндәше өчен җан ата, сенсация көтә. Тамашачыларга шулай ук кискен көрәш бик ошый. Көчләре тигез, соңгы секундларга кадәр кем җиңәчәге билгеле булмаганда. Андый көрәштә алымнары да күп булмаска мөмкин, ләкин кискенлек, интрига бар. Киресенчә дә булгалый. Менә икәү бил алышалар. Матур алымнар җитәрлек. Башта – берсе, аннары икенчесе алып сала, тырышкан булалар, ләкин кискенлек юк. Килешкәннәр икән, ничек сөйләшкәннәр, шулай булачак, барысы да алдан билгеле. Кулына сөлге тотып караган кеше андыйны бик тиз чамалый. Мәйдан тулы тамашачылар алдында көрәшик дисәк, батыр булыйк дисәк, алдашмыйк, егетләр!

Муса Җәлил турниры – саннарда

➤Турнир тарихында авырлык категорияләре үзгәреп торган. 1964–1970 елларда аларның саны – дүрт, 1971–1981 елларда – биш, 1982–1994 елларда – тугыз, 1995–2005 елларда – ун, 2006–2007 елларда – янәдән тугыз, 2006–2022 елларда ун булган. Быел исә көрәшчеләр 11 авырлык категориясендә бил алышачак.

➤Турнир тарихында барлыгы 70тән артык команда катнашкан.

➤Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш турнирында каһарман-шагыйрьнең адашы Муса Галләмов биш мәртәбә җиңүче булган.

Муса Җәлил турнирында биш мәртәбә җиңү яулаган, РСФСРның милли төрләр буенча спорт остасы, Татарстанның атказанган спорт остасы, грек-рим көрәше буенча СССРның спорт остасы Данил Галиевка 2014 елда туган ягы Биектауда бюст ачтылар. Якты дөньяда нибары 45 ел яшәп калган батыр Түбән Кама командасы өчен бил алышты.

Муса Җәлил турниры ул – ...

Марсель ТАҺИРОВ,
Муса Җәлил турнирының 4 мәртәбә җиңүчесе, Татарстан Көрәш федерациясенең башкарма директоры:

– Тарихка күз салсак, 1965 елда бу турнирга Муса Җәлил исеме бирелә. Бу исем бирелү турнирның дәрәҗәсен күтәрә. Бүген дә эчтәлеге, мәгънәсе, тамашачы мәхәббәте ягыннан иң көчле турнир ул. Үзебез көрәшә башлаганчы, без аның турында газетадан укып кына белә идек. Батырларның исемнәрен, фотосурәтләрен күреп, ничек кенә чемпион булырга икән, дип хыялланып йөрдек. Җәлил турнирында беренче тапкыр 1988 елда батыр калдым. Ул елны Казанда көрәштек. Аңа кадәр катнашкан бөтен ярышларда җиңсәм дә, бу турнирда җиңә алмадым. Җәмгысы дүрт тапкыр батыр калырга насыйп булды. Бу турнирга көрәшчеләр генә түгел, электән халык та, матбугат та башкача әзерләнә, бик көтеп ала. Шул ягы белән дә көчле һәм кадерле ул.

Руслан ГӘРӘЕВ,
бәйгенең 2 мәртәбә җиңүчесе (Азнакай):

– Җәлил турниры җитә башлауга, көненә өчәр тапкыр тренировкаларга йөри идек. Татарстан гына түгел, якын-тирәдәге төбәкләрдән дә иң көчле көрәшчеләр җыела бит! Гомумән, көрәшнең нәрсә икәнен аңлый башлаганнан бирле таныш мин бу турнир белән. Ул чакта чын баһадирлар келәм тота иде. Муса Җәлил турнирында 6 тапкыр җиңгән Рафаэль абый Сафиуллинның батыр калганнан соң келәмне үпкәне әле дә күз алдымда. Менә нинди зур җиңү иде ул көрәшчеләр өчен! Әүвәлге көрәшчеләрнең күбесен хәтерлим. Без – малайлар өчен чын батыр иде алар! Алар кебек, күкрәк киереп, мин Муса Җәлил турнирында оттым, дип әйтү хыялы гаҗәеп көчле иде. Шуңа да үз алдыма бер мәртәбә булса да бу ярышта беренче урынны алу максаты куйдым. Шөкер, ике тапкыр җиңдем дә. Элек тә турнир җиңүчеләренең фотосурәтләрен сезнең газетада бастыралар иде. Үзем чыккан газеталарны, саргаеп бетсәләр дә, күз карасы кебек саклыйм. Без бит елый-елый көрәшә идек. Хәзерге яшьләр алай түгел шул…

Атлас ГАФИЯТОВ,
«Татарстан яшьләре» газетасының баш мөхәррире,
республика категорияле хөкемдар:

– Газеталар арасында көрәш буенча турнирны иң беренче булып «Социалистик Татарстан», аннары «Татарстан яшьләре» белән «Яшь ленинчы» оештыра башлады. Алар бөтенесе дә республикада спортны үстерүгә бик зур өлеш кертте. Муса Җәлил турнирының дәрәҗәсе Татарстан беренчелегенә караганда да зуррак. Ул элек тә шулай, хәзер дә. Чөнки монда һәрбер командадан теләгән һәр кеше катнаша ала. Бөтен кешегә үзен күрсәтергә мөмкинлек бирелә. Монысы – бер. Икенчедән, газетада батырларның рәсемнәрен бастырып чыгару традициясе бар. Бу газетаның да, көрәшчеләрнең дә абруен күтәрә. Чемпионнар – авылда да, шәһәрдә дә хөрмәткә лаек кешеләр. Алар тормышта да югалмыйлар.

Азат НУРМӨХӘММӘТОВ, көрәшче,
Лаеш районы советының аппарат җитәкчесе:

– Муса Җәлил һәм татарча көрәш – минем өчен гаять әһәмиятле төшенчәләр. Инде менә 60 ел дәвамында Муса Җәлил истәлегенә уздырылучы көрәш турниры чын батырларны ачыклый. Шушы еллар дәвамында ул татарның йөзек кашына, көрәшчеләрнең, тамашачыларның, үсеп килүче буынның яраткан ярышына әйләнде. Оештырылу дәрәҗәсе белән дә, призлары һәм командаларның күп булуы белән дә ул – һичшиксез, иң мәртәбәле турнирларның берсе. Ел саен ул көрәш сезонын ачып җибәрә. Алай гына да түгел, турнир кысасында узган елгы сезонга нәтиҗәләр ясала, «иң-иң»нәре ачыклана. Менә шуның белән дә әһәмиятле ул. Моннан тыш, әлеге турнир татар халкының асыл егетләрен ачыклавы белән дә кадерле. 12 тапкыр җиңгән Айрат Гыйлаевны гына алыйк. Кайбер спортчыларның карьерасы да бу кадәр озын булмаска мөмкин. Ә бит безнең рекорд куйган көчле көрәшчеләребез тагын бар! Алар бүгенге көрәшчеләргә тынгы бирми. Яшьләр олпатларыбызны куып тотып, узып китәргә тырыша. Моның өчен рәхмәт бу турнирга! Аны гамәлгә куйган «Ватаным Татарстан» газетасына, Көрәш федерациясенә һәм башка оештыручыларга уңышлар телибез. Без исә, үз чиратыбызда, команданы әзерлибез һәм матур көрәш алымнары күрсәтергә ниятлибез.

Муса ГАЛЛӘМОВ, көрәшче,
турнирның 5 мәртәбә җиңүчесе (Лаеш):

– Чыгышым белән Мари Иленнән мин. Көрәш белән 15 яшемнән шөгыльләнә башладым. Ул чакта ук бер зур хыялым бар иде: Муса Җәлил турнирында һич югы призлы урын аласым килде. Тренерымның да: «Муса Җәлил исемен йөртүче зур турнир бар. Насыйп булса, син дә анда келәм тотарсың әле», – дигән сүзләре хәтеремдә. Шөкер, призер гына түгел, бу турнирда 5 мәртәбә батыр калырга насыйп булды. Иң зур җиңүләрем ул минем! Бүген дә минем бу ярышларга карата фикерем үзгәрмәде. Бер бәхәссез: Муса Җәлил истәлегенә уздырылучы көрәш ярышлары – иң көчле һәм мәртәбәле турнир. Ул татар халкының каһарман-шагыйре Муса Җәлил исемен йөртүе белән үк дәрәҗәле. Һәм аның дәрәҗәсен саклау, киләчәк буын көрәшчеләргә тапшыру – безнең бурыч.

2009

2011

2011

2012

2013

60 ЕЛНЫҢ 60 МИЗГЕЛЕ

2013

2014

2015

2016

2017

БУЫННАН-БУЫНГА

МУСА ҖӘЛИЛ ТУРНИРЫНЫҢ ӘТИЛЕ-УЛЛЫ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ

Бабай сөлгесе

Муса Җәлил турнирында дүрт тапкыр батыр калган Наил Хәмидуллинны «нык билле көтүче» дип йөртәләр. Гомере буе авылда яшәгән һәм тренерның ни икәнен дә белмәгән көрәшче зур ярышларда көндәшенең осталыгына да, авырлыгына да игътибар итми. Башта авылдагы, үз якларындагы картларны гаҗәпләндерсә, аннары бөтен республикага танылa.

Көрәш тамашачысы Саба районындагы Олы Мишә авылы егетен тәүге мәртәбә 1965 елда узган бәйгедә күрә. Кышын – фермада, җәен көтүче булып эшләүче Наил Хәмидуллин ул ярышта 60 килолылар арасында өченче урынны ала. Тагын бер елдан икенче була, 1967дә исә җиңүче булып танылa. Бу уңышын ул 1968, 1971 һәм 1975 елларда кабатлый. Татарстан һәм Россия чемпионы исемен яулый. Шул арада авыл егетләрен дә көрәшергә өйрәтә. Ярышларга резин галошлы киез итек киеп килүче батыр РСФСРның милли төрләр буенча спорт остасы дәрәҗәсенә ирешә.



Хатыны Фатыйма апа белән өч бала тәрбияләп үстерә алар. Уллары Камил Сабан туйларында бил алыша. Кызларының берсен исә Наил абый шәкерте – Сәгыйть исемле көрәшче егеткә кияүгә бирә. Муса Җәлил бәйгесендә, Татарстан чемпионатларында икенче, өченче урыннарны алган Сәгыйть Гыйниятуллинны күпләр чабышкылар тотучы танылган фермер буларак белә.

Сәгыйть Гыйниятуллинның уллары, ә Наил Хәмидуллинның оныклары көрәшкә кереп китмәсә, сәер булыр иде. Алар исә табигый юлны сайлый. Ленар – яшьләр арасында Россия чемпионы булып танылa. Кечкенәләре Фирзәр Татарстан, Россия, хәтта дөнья чемпионатларын ота. Иң олылары Илдар исә тагын да зуррак уңышларга ирешә. Ул берничә мәртәбә Татарстан һәм Россия чемпионатларында беренче урыннар алды, дөнья чемпионы исемен яулады. Тарихка 2013 елгы Казан Универсиадасы чемпионы буларак кереп калды. Муса Җәлил бәйгесендә Илдар 2009, 2013, 2015 елларда батыр калуы белән горурлана.

Хәтерлим мин әле бүгенгедәй

Батыр, тренер, хөкемдар. Фәрит Шәйхетдинов өчесендә дә ат казана. Муса Җәлил бәйгесендә ул 1977 елда җиңү яулый. 36 елдан әтисенең уңышын улы Фәнил кабатлый.

Яшел Үзән районындагы Олы Карагуҗа авылында туып-үскән Фәрит Шәйхетдинов кулына сөлгене кечкенәдән үк тота. Үсә төшкәч, Муса Җәлил бәйгесендә җиңү турында хыяллана башлый.

– Безнең күңелләргә кереп калган ярыш ул. Узган гасырның 70–80 нче елларында без аны дөнья чемпионаты дип йөртә идек. Чөнки бик күп кеше бил алыша, батыр калу бик авыр һәм мәртәбәле иде, – дип искә ала Фәрит Шәйхетдинов.

Андый шатлык аңа 1977 елда узган турнирда елмая. Үзе әйтүенчә, тормышындагы зур вакыйганы бүгенгедәй хәтерли.

– Без көрәшкәндә нибары 5 авырлык категориясе бар иде. Әйтик, мин 80 килолылар арасында бил алыштым. Иң атаклы көрәшчеләр шунда җыела. Җиңеп чыгу бик авыр. Уйлап карагыз: ярышны өч көндә тәмамлый алмадылар. Җиңүчеләр дүртенчесендә – дүшәмбе көнне генә ачыкланды, – дип сөйли Фәрит Шәйхетдинов моннан ярты гасыр чамасы элек булган ярыш турында. – Финалда Түбән Камадан Михаил Минеев белән бил алыштык. Ул 1972, 1976, 1978 елларда җиңү яулады. 1977дә исә миңа насыйп булды. Аны җиңәрмен дип уйламаган идем. Биеп кенә тора, җитез, көчле көрәшче иде. Хәтта көндәш белән сөйләшеп карарга да тәкъдим иттеләр, шул

рәвешле миннән спорт остасы ясыйлар, янәсе. Юк, мин әйтәм, көрәшәбез. Финалда 4:0 белән отып барганда, чистага салдым. Ярыш вакытында өч төн йокламадым.

Әле тагын берничә мәртәбә икенче һәм өченче урыннарны ала ул. Төрле хәлләр була. Сөенечләләре янында үкенечләләре дә очрый.

– Бервакыт бөтен көндәшләремне чистага салып барсам да, финалга чыга алмадым. Икенчесендә дүрт кеше калгач, бер көндәшем: «Чемпион калганым юк, әйдә инде җиңү миңа булсын», – дип аптырата башлады. Бирмәдем, әмма җиңеп барган килеш, имгәндем дигән булып, алыш ахырында ачудан сөлгене ташлап чыгып киттем, – ди танылган көрәшче. – Үзем бил алышып йөргән елларда көрәшче генә түгел, тренер да, команда вәкиле дә булдым. Бер елны шулай Татарстан беренчелеге бара. Бер келәмдә олылар, икенчесендә яшьләр ярыша. Финалга барып җиттем. Келәмгә чыгарга кирәк, инде ике мәртәбә чакырганнар, хәтта кисәтү биргәннәр, ә мин ул хакта уйламыйм да, укучым Илгиз Гайнуллинның ничек бил алышканын күзәтәм. Укучыларым өчен күбрәк куана идем. Тренерлыкны якынрак күрдем.

Сүз уңаеннан, Илгиз Гайнуллин Муса Җәлил турнирында батыр исемен 4 тапкыр яулый. Универсиада чемпионы булып танылган Илнур Мортазин, дөнья чемпионатын откан Фирдүс Зәйнуллин да – Фәрит Шәйхетдинов шәкертләре. Тагын бер горурлыгы – улы Фәнил. Ул «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган бәйгедә 2013 һәм 2014 елларда җиңү яулады. «Аның уңышлары үземнекенә караганда да зуррак күренә. Шөкер, мине уздыра алды», – дип горурлана әтисе.

Фәрит Шәйхетдинов Муса Җәлил бәйгесен зур ярыш кына түгел, олы бәйрәм дип атый.

– Җитмәсә, быел юбилей ярышы да бит әле. Бәйге ул – бергә бил алышып йөргән егетләр белән очрашу урыны да, – ди. – Кайбер көрәшчеләр гадел бил алышмый, бер-берсенә җиңүне бирәләр дигән сүзләр дә йөри. Муса Җәлил бәйгесендә андыйлар булмас дип уйлыйм. Герой исемен йөрткән турнирда бөтен халык карап торганда була да алмый. Егетләр нык әзерләнә, алар – профессионал. Шуңа күрә мавыктыргыч, яхшы ярыш көтәм.

Илфат салган эздән

Әнвәровлар гаиләсеннән берьюлы 3 егет Муса Җәлил бәйгесенең җиңүчеләре булып танылa. Әтиләре Илфат салган эздән соңрак уллары Илфир белән Айнур атлый. Өчесенә – 6 җиңү. Аларның да дәвамчылары бар.

Илфат Әнвәров гомерен авыл хуҗалыгына багышлый. Күп еллар механизатор булып эшли. Комбайнчылар арасында Татарстанда беренчелекне яулап, мотоцикл белән бүләкләнә, районда күп тапкырлар кыр батыры исеменә лаек була. Ярышларга әзерләнгәндә ике потлы герне капка аркылы атып уйнаган көрәшче келәмдә дә бил бирми. Сабан туйларында бил алышып, 12 мәртәбә Актанышның баш батыры булып танылa. 1982 һәм 1983 елларда исә Муса Җәлил бәйгесенең җиңүчесе.

– Аның өчен бу турнир иң зуры, иң дәрәҗәлесе иде. Бу сүзне еш кабатлады. Кызганыч, әтинең зур бәйгеләрдә бил алышканын күрү насыйп булмады. Әмма Казаннан самолетка төялеп ярыштан кайткач, ничек сөенгәннәрен һәм бәйрәм иткәннәрен хәтерлим, – дип сөйли улы Илфир Әнвәров. – Бервакыт кайтты да авылдагы бөтен «Социалистик Татарстан» газетасын җыеп чыкты. Истәлек өчен түгел. «Минем рәсемем төшкән газета теләсә кайда аунап йөрергә тиеш түгел», – диде.

Әнвәровлар гаиләсендә 1 кыз һәм 4 малай үсә. Аңлашыла инде, көрәшче әтинең уллары да кулына сөлге ала. «Безнең җиңүләргә, аның эшен дәвам иттерүебезгә бик сөенде», – ди Муса Җәлил бәйгесендә 1999 һәм 2005 елларда батыр калган, соңрак тренерлык эшенә алынган Илфир Әнвәров. Энесе Айнур исә 2003 һәм 2006 елларда җиңүче булып танылды. Республика ярышларында җиңүләре булмаса да, Тәүфикъ белән Шәфкать тә сөлге тотуның җаен белә.



Аларның да дәвамчылары бар. Әнвәровларда тагын 6 егет үсеп килә. Көрәшкә тартылалар. «Икесе кечкенә әле. Зурраклары исә сөлге тота белә инде», – ди Илфир. Аның улы, герой-шагыйрьнең адашы Муса узган ел Татарстан һәм Россия беренчелекләрен отты. Кечкенәсе Мөслимдә узган бәйгедә өченче булган.

Актанышта ел саен Илфат Әнвәров истәлегенә көрәш бәйгесе уза. Танылган батырның туган көненә туры китереп, ноябрь аенда балалар арасында турнир оештыралар.

ҺӘЙКӘЛЛЕ БАТЫР

Узган ел ахырында татар көрәшчесенә тагын бер һәйкәл барлыкка килде. Муса Җәлил бәйгесенең өч мәртәбә җиңүчесе Раббани Шәриповның бюсты Тукай районындагы Иске Абдул авылында ачылды. Шөкер, легендар батыр әле дә көрәш белән кызыксынып яши.

Минзәлә районында туып, алты яшендә әтисез, тагын ике елдан әнисез калган Раббанига тормышның ачысын кечкенәдән үк татырга туры килә. Абыйсы Габделнур гаиләсендә үсә булачак батыр. Сугыштан соңгы авыр еллар: уку кайгысы түгел. Яшьтән үк эшли башлый, 12–13 яшендә колхозда атлар көтә малай. Көч-куәте шуңа да бәйле. «Минем бер генә остазым да булмады. Шофер чагымда авыр капчыкларны төяп-бушаттым – тренерым шул булгандыр. Эшем дә, күнегүләрем дә бер булды», – дип искә ала ул. Авыл Сабан туйларында җиңү артыннан җиңү яулана. Тирә-якка «батыр» дигән исеме тарала. Бәйрәмнәргә аның бил алышканын күрү өчен генә килүчеләр була. Үзе дә төрле якларда көчен күрсәтә. Казанда көрәше, бүләккә алган 26 килолы чуен аю күп еллар дәвамында Иске Абдулдагы йортлары капкасы өстендә кадакланган килеш тора. Көрәш дөньясында танылган шәхес Николай Морящичев аны үзе янына чакыра. «Мин синнән грек-рим көрәше буенча дөнья чемпионы ясыйм», – ди. Әмма батыр туган ягын ташлап чыгып китәргә теләми.

40 яшенә җиткәндә икешәр мәртәбә Татарстан һәм Россия чемпионатларын ота, Муса Җәлил бәйгесендә өч мәртәбә җиңү яулый. Раббани Шәрипов белән Минзәләнең тагын бер батыры Фрил Әхмәтов арасындагы очрашу исә берара көрәш дөньясында халык авыз иҗаты үрнәгенә әверелә. Зур көрәштән ул 50 яшендә Тукай районы Сабан туе батыры булып танылгач китә.

Ярышлардан кайтуга, икенче көнне үк, колхозның йөк машинасы руле артына утырып, ерак юлларга чыгып китә Раббани батыр. Озак еллар хәвефсез йөреп, шәп шофер булып танылa һәм, лаеклы ялга чыкканда, аңа үзе йөрткән «ГАЗ» йөк машинасын бүләк итәләр. 60 яшен бәйрәм иткәндә аны улы Ришат белән бил алыштыралар.

Ришат Шәрипов берничә тапкыр район һәм шәһәр Сабан туйларында батыр булып танылa. Муса Җәлил турнирында ул 1996 һәм 1999 елларда җиңүче була. «Беренче уңышымны Кукмарада узган бәйгедә яуладым. Хәлиткеч алышта Зәйдән Раиф Сәхәбетдиновны оттым. Бу җиңүне әти дә күреп торды. Аннары Чистайда икенче урынны алдым. Хөкемдарлар көндәшне яклап, үкенечкә калган вакытлар да булды», – дип искә ала Ришат Шәрипов.

Шөкер, Шәриповларның көрәштәге юлы дәвам итә. Хәзерге вакытта келәмдә Раббани батырның онытгы Руслан Шәңгәрәев бил алыша.

Әтисенең шәкерте

Рим Синәкәевкә парлы җиңү килешә. Муса Җәлил бәйгесендә дә, Татарстан һәм Россия чемпионатларында да икешәр тапкыр батыр кала ул. Улы Рамил исә әтисен дә уздыра.

Мөслимдә туып-үскән, 70 кило авырлык белән район Сабан туенда җилкәсенә тәкә салган көрәшче Муса Җәлил турнирындагы беренче уңышына 1985 елда ирешә.

– Ул вакытта укытучы булып эшли идем. 1984 елда Татарстан чемпионатын, аннары Уфада РСФСРныкын отып, спорт остасы исемен алдым. Барысы да бер уку елында булды, – дип искә ала батыр. – Казанда узган Җәлил бәйгесендә финалда Сарманнан Фәрит Габдрахмановны оттым дип хәтерлим. Нык сөендем. Минем өчен бу бәйгедән дә дәрәҗәлерәк ярыш булмады.

Икенче җиңүне исә 10 ел көтәргә туры килә. Монысында ул 75 кило авырлыкта, үзе яшәгән Әлмәттә узган ярышта җиңүче исемен яулый. Бу вакытта әле әтисен дә уздырачак Рамил дөньяга да килмәгән.

Әтисенең шәкерте дә булган Рамил Синәкәев Җәлил турнирында 2015, 2016 һәм 2022 елларда батыр калды. Узган ел бәйгедә чемпион исеме белән бергә Әлмәтнең танылган пәһлеваны Ильяс Галимов исемендәге премиягә дә ия булды. Татарстанның Көрәш федерациясе һәм «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган әлеге бүләк финалда иң яхшы көрәш күрсәткән егетләргә тапшырыла.

– Улым көрәшкәндә ничек дулкынланганны һәм борчылганны үзем генә беләм. Һәрвакыт янында утырам, киңәшләремне бирәм. Шөкер, ул мине дә уздырды, Муса Җәлилдә өч мәртәбә батыр калудан тыш, әле бит Татарстан чемпионатын – биш, Россиянекен – өч һәм дөньяныкын ике мәртәбә отты. Димәк, аны җитәкләп көрәшкә алып килүем, биргән киңәшләрем бушка китмәгән.

2018

2018

2018

2019

2020

2020

2020

2020

2021

2021

БАТЫР ӘНИСЕ

Зур үрләр яулап, танылу алгач та, кеше булып калу мөһим. Бу сыйфат исә кечкенәдән – әти-әни биргән тәрбиядән килә. «Булатның тыйнаклыгы, бернинди гаугасыз, матур алымнар белән көрәшүе – минем өчен горурлык», – ди Муса Җәлил бәйгесенең дүрт мәртәбә җиңүчесе Булат Мусинның әнисе Рәмзия ханым. Батыр, шул ук вакытта кешелекле ул тәрбияләүнең дә үз серләре бардыр.

– Балаларны «тыйнаклык ул – матурлык» дип тәрбияләдек. Без – патриотик рух югары булган чорда үскән балалар. Безнең өчен ата-ана, әби-бабай, туган авыл, туган ил кыйммәтләре беренче урында тора. Җаваплылык тоеп эшләү, ихтыяр көче, тормышка үз карашың булу бездән балаларга да күчкән. Шул сыйфатларны мин Булатта да күрәм. Ул беркайчан да үзенең көрәше белән мактанмый. Мәйданга чыкканда да гади итеп чыга, матур итеп көрәшә, елмаеп кереп китә. Тамашачылар да аны тыйнаклыгы өчен ярата. Кемне генә очратсам да, алар Булатның гаугасыз көрәшүен мактап телгә алалар, – дип горурлана батыр әнисе.

Булат балалар бакчасына йөргән чакта ук көрәшә башлый. Әтиләре Марат абый бертуган Инсаф белән Булатны өйдә дә үзара көрәштереп үстерә. Марат абый – үзе дә көрәшче булган кеше. Үсә төшкәч, Сабан туе мәйданнарында призлы урыннарга күтәрелә Булат.

– Булат кечкенәдән тыңлаучан булып үсте. Беркайчан да киреләнмәде. Кечкенәдән үк бөтен кешегә дә ярдәм итәсе килү теләге бар иде аның. Ул сыйфаты балалар бакчасына йөргәндә үк чагыла иде. Кечкенәдән йорт эшләренә өйрәнеп үсте. Абыйсы белән бергә уйнап, эшләп үстеләр, – дип искә ала Рәмзия ханым.

2012 елдан Булат Мусин Татарстан дәрәҗәсендәге турнирларда чыгыш ясый башлый. «Ун елдан артык Булат өчен җан атып, аның белән бергә атлыйбыз», – ди әнисе. Шушы ун ел эчендә ул нинди генә ярышта катнашмаган да нинди генә турнирларда отмаган. Рәмзия ханым улының бүләкләреннән Булатның бүлмәсендә күргәзмә ясап куйган. Дивар тулы диплом, медаль, кубок, фото, газета битләре. Иң кадерлесе – күрше Шахмай авылында батыр калгач алган сөлгесе. «Кайвакыт эшләрне бетергәч, шул бүлмәгә керәм дә, медальләргә карап, барысын да искә төшереп утырам», – ди Рәмзия ханым.

Йөзләгән медаль белән диплом арасында иң кадерлеләрнең берсе – 2014 елда Муса Җәлил турнирында җиңүче булып алган медале дә саклана Булатның. 19 яшендә ул беренче тапкыр дәрәҗәле турнир чемпионы була.

– Муса Җәлил турниры – шулкадәр затлы турнир. Балачактан шушы шагыйрьнең шигырьләрен укып үскән буын өчен ул аерым бер символик мәгънәгә ия. Без аны һәрвакыт көтеп алабыз һәм анда җиңүне зур җиңүгә саныйбыз. Булат үзе дә Муса Җәлил турнирын дулкынланып көтә. Дүрт тапкыр җиңү яулаганы бар. Быел да без аңа уңышлар теләп торабыз. Исән-сау булсын, яхшы итеп көрәшсен, – ди җиңүче әнисе.

Ул – баласының уңышлары өчен иң нык сөенүче, авыр чакларында көенүче кеше. Булатның көрәштә үсүен, аны тамашачылар яратуын да Рәмзия ханым сөенеп әйтә.

– Элегрәк бер ярышны да калдырмый идем. Соңгы ике елда барган булмады. Соңгы тапкыр «Манзара» премиясен карарга килдек. Залда утырган халыкның «Булат! Булат!» дип кычкыруын күреп, шундый сөендем. Элек Булатка ул кадәр көчле итеп җан атмыйлар иде. Хәзер тамашачылар арасында Булатның дәрәҗәсе артуын аңладым. Димәк, улымның көрәше юкка булмаган, аның көрәшен яраталар, көтәләр, аны санлыйлар. Бу ярату артында эшеңә бирелгәнлек, аны профессиональ дәрәҗәдә башкару, нык ихтыяр көче һәм җаваплылык ята. Һәркөнне шул эш белән шөгыльләнү, үзеңне әзерләү бик җиңелләрдән түгел, – ди ул. – Булат бер командадан икенче командага күчеп йөри торган кеше дә түгел. Ул тугры булып, 10 ел дәвамында «Ак барс» көрәш сараена хезмәт итте. Аның тренерларына, Вакыйф абыйга һәм Булат Хәбибрахмановка рәхмәт.

Бу сыйфатлар һәммәсе дә Булатка әти-әнисеннән күчкәндер. Тәрәзә төбе саен гөлләр, ишегалдында чәчәкләр үстерергә яратучы Рәмзия апа белән нык рухлы Марат абый балаларын «батырлык – рухи матурлык» дип тәрбияләгәннәр.

– Яшәешнең асылы – туган илгә лаеклы алмашчылар үстерү. Батырлык – рухи матурлык бит ул. Хәзерге вакытта дөньяда матди байлык – беренче урында. Әлбәттә, ул бик кирәк. Шул ук вакытта кешенең рухи сыйфатлары да булырга тиеш. Ул сыйфатлар матди байлык белән югалырга тиеш түгел. Нинди генә үрләр яуласа да, шундый тыйнак кеше булып кала белгән улыма мин һәрвакыт хәер-догада. Безнең милли көрәшебез яшәсен иде. Көрәшче әниләренә сабырлык телим, киләчәктә улларыбыз белән горурланып кына яшәргә язсын, – ди Рәмзия Мусина.

Энҗе ГАБДУЛЛИНА

Бу кызык!

Бәйгедә ике тапкыр җиңүгә ирешкән Балтач егете Сәйдәш Мәгъсүмов 1983 елда батыр исемен яулаганда әле 18 яшен тутырмаган була. Аның якташы Фидаил Шакиров бу ярышта 6 тапкыр батыр булып танылa. Тәүге мәртәбә җиңгәндә аның әле яңа гына 19 яшен тутырган чагы була. 4 мәртәбә батыр булып танылган Яшел Үзән егете Илгиз Гайнуллин да 19ын тутырып, нәкъ бер ай узгач, беренче җиңүен яулый. Актаныштан Руслан Нургалиев (4 мәртәбә батыр) 19ын тутырып, 7 көн узгач, Чаллыда Муса Җәлил бәйгесе җиңүчесе булып таныла. Әлмәттән Тимур Милютин (1 тапкыр батыр), Алабугадан Ислам Фәлахов (1), Арчадан Рамил Хәкимҗанов (1), Актаныштан Морат Әмирханов (2), Сабадан Рафил Сабиров (4 мәртәбә), Яңа Чишмәдән Булат Мусин (4), Сарманнан Ришат Гайнетдинов (4), Башкортстаннан Артур Зөлкарнәев (5), Балык Бистәсеннән Илнар Әхмәтҗанов (9), Балтачтан Айдар Хәйретдинов (10) тәүге җиңүләрен 20 яшь тулганчы яулый. 1964 һәм 1968 елларда батыр калган Сарман егете Зөфәр Ханов исә икенче җиңүенә 45 яше тулып килгәндә ирешә.

Җәлил турниры кайларда узган?

* мәртәбә

«...Муса Җәлил призына барган бәйгенең үз традициясе, үз чемпионнары, үз рекордчылары бар. 11 февральдә турнирны 6 тапкыр откан 3 көрәшче бар иде. Балтачтан Фидаил Шакиров, Айдар Хәйретдинов һәм Питрәчтән Рафаил Сафиуллин. Айрат Гыйлаев исә җиде тапкыр җиңү яулаган иде. Айдар һәм Айрат 12 февральдә үз җиңүләренә тагын берне өстәделәр. Чаллыдагы турнирны тамаша кылган көрәш сөючеләр шуны күрде: ике егетнең дә беләкләре нык әле. Аларның уңышларын кабатларга теләүчеләргә бик нык тырышырга туры киләчәк. Дөрес, аларның икесе дә мәйданда яшьләрнең бик күп булуын искәртәләр...»

«Ватаным Татарстан», 15 февраль, 2005

Көрәш тә сәнгать

ДАНИР САБИРОВ: «Бил сиздерсә дә, көрәшкәнемә үкенмим»

Татарстанның атказанган артисты Данир Сабировның көрәшче булганын белмәүчеләр бардыр әле. Чандыр гәүдәле Азнакай егетенең балачагы урамда түгел, келәмдә узган икән. Көрәшеп алган титулларын да, «ВТ» гамәлгә куйган Муса Җәлил турнирында микродулкынлы мич отуын да бик яхшы хәтерли ул.

Данир – беренче рәттә, сулдан беренче

1999 ел. Иртәгә район үзәгендә көрәш ярышы дигән көнне кинәт кенә 12 яшьлек Данирның әбисе вафат була.

– Бик яшьли – 53 яшендә китте ул арабыздан. Аңа кадәр көрәштә гел җиңелеп килә идем. Ул көнне йоклар алдыннан, әби, бу юлы синең хакка җиңәм мин, дип уйлап яттым. Һәм җиңдем. 3 нче урында калсам да, минем өчен бик зур җиңү булды ул. Әле дә исемдә: бүләккә ике видеокассета биргәннәр иде, – дип искә ала Данир.

Шуннан әкрен-әкрен келәмне яуларга карешә егет. Иң зур терәге әтисе була. Көрәш белән дә ул әтисе теләгәнгә шөгыльләнә башлый.

– Үзем теләмәсәм, көрәшмәс идем, билгеле. Теләп йөрдем. Ә әти гел янымда булды. Ярышларга барырга автобус бирмәсәләр, бөтен команданы машинасына төяп булса да алып бара иде, – ди артист.

Үсмерләр арасында көрәшеп, байтак кына титуллар да җыярга өлгерә. Иң зурларыннан үсмерләр арасында Татарстан беренчелеген һәм Татарстанның Беренче Президенты кубогын отуын, спорт остасына кандидат булуын искә алды ул. Чиләбедә узган Федераль Сабан туеннан да батыр исеме яулап һәм ул чакта яңа гына чыга башлаган ЖК-телевизор отып кайта Данир.

2005 елда Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш турнирында катнашып, 3 нче урынны алуын да яхшы хәтерли. Бу аның ирләр арасында тәүге тапкыр бил алышуы була.

– Ул чакта беренче курста укый идем. Әллә ике спорт остасын җиңдем мин анда. Миңа – 18, көндәшләремә – 23–25 яшь... Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш ярышы – электән бик зур турнир инде ул. Финалда җиңелсәм дә, үземнән күпкә олырак көрәшчеләрне җиңеп, шундый зур турнирда өченче урында калуыма бик сөендем. Өстәвенә бүләккә микродулкынлы мич тә бирделәр, – ди Данир.

Өйләнгәнче бил алышып, ахыр чиктә сәнгать юлын сайласа да, көрәшкә рәхмәтле ул бүген. Дисциплина тәрбияләгәне, җиңүен дә, җиңелүләрен дә кабул итәргә өйрәткәне өчен рәхмәтле.

– Бил сиздерсә дә, көрәшкәнемә үкенмим. Без бит балачактан Балтач батырлары Айдар абый Хәйретдинов, Ранил Габдрахманов, Чаллыдан Айрат абый Гыйлаев көрәшкәнгә сокланып, алар кебек булырга тырышып үстек. Инде күптәннән утырып бер көрәш карыйсы килеп йөри. Вакыт кына табып булмый. Әле, ялгышмасам, өченче ел көрәшеп караган идем. Гел өметсез түгел, гәүдә хәтерли икән, – ди юморист.

Данирдан батырлык турында да сорадык. Бу төшенчәне ул менә ничек аңлый икән:

– Батырлык ул – бер сугып аудара алган чакта да үзеңне кулда тоту, сүз белән аңлата алган чакта көчеңне тыеп тора алу.

ВИЛ УСМАНОВ: «Көрәш мине Казанда калдырды»

Татарстанның халык артисты Вил Усманов – Муса Җәлил турнирының 1993, 1994, 1998 еллардагы батыры. Кечкенәдән үк келәмгә чыккан егет җырлый башлагач та әле шактый гына көрәштән аерыла алмаган. Азартны җиңү авыр иде, ди җырчы.

Баулы районының Хансөяр авылы егете беренче тапкыр Сабан туенда бил алышып карый. Җиңүче сөлгесен иңенә салып, авыл урамыннан, үзе әйтмешли, Берлинны алган кебек кайтканы әле дә исендә икән.

– 8 сыйныфны тәмамлап, Әлмәт физкультура техникумына укырга кердем. Нәкъ менә шул елдан профессиональ көрәш белән шөгыльләнә башладым. Илгизәр абый Димиев мәктәбен узган егет мин. Спорт залыннан чыкмадым да диярлек. Ярышлар җиткәндә бигрәк тә. Җиңүләре дә озак көттермәде, – ди җырчы.

Муса Җәлил исемендәге турнирда да өч мәртәбә бәхет елмая аңа. Кукмара, Балтач, Арча егетләре белән көндәшлек аеруча кискен булган.

– Ул турнирны оту безнең өчен зур дәрәҗә иде. Кайбер елларны башка ярышларга караганда да күбрәк һәм көчлерәк көрәшчеләр катнашты анда. Әмма без дә калышмаска тырыштык, – дип искә ала Вил Усманов.

Баулы егете берничә ел Теләче командасы өчен көрәшә. Сәнгать юлы нәкъ менә шул районга алып килә аны.

– Казанга укырга килгәч, Теләчедә эш тәкъдим иттеләр. Көрәшүемне белгәч, командаларына да дәштеләр. Көрәшчеләргә яхшы гына түлиләр иде алар. Яшәргә кирәк бит – ризалаштым. Әле данлыклы Теләче Сабан туена кайтып, батыр калганым да хәтердә.

Вил Усмановны Теләче генә түгел, төрле районнарга чакырып-чакырып карыйлар. Ләкин Казаннан китәсе килми.

– Казанда калырга көрәш ярдәм итте. Камил Исхаков мэр булганда, көрәш буенча шәһәр беренчелегенә килми калмый иде. Минем көрәшүемне ошаткан булып чыкты. Аның зур ярдәме белән, Казанда фатирлы булып, монда төпләнеп калдым. Кем белә бит, җырлап кына йөрсәм, язмышым бөтенләй башка борылыш алыр иде, – ди җырчы.

Көрәштән вакытында китә белергә кирәк дигән фикердә ул. Азарт һәм җиңү теләге көчле булганда, келәмне калдыру кыенрак икән шул.

– Көрәш чир кебек бит ул. Вокал буенча укытучым күпме тыеп карады – барыбер туктамадым. Көрәшнең җырчы буларак җитлегүемне шактый тоткарлаганын соң аңладым шул. Әмма бу әле үкенәм дигән сүз түгел. Табигатем буенча үҗәт мин. Көрәш менә шушы үҗәтлекне арттырды гына. Сәнгатьтә дә бик кирәк сыйфат ул. Аннан соң, сәнгать тә һәрдаим үз өстеңдә эшләүне таләп итә. Ул яктан бик охшаш алар, – ди Вил Усманов.

2022

2022

2022

2022

2022

Турнирның 1964–2022 еллардагы җиңүчеләре

12 ТАПКЫР ҖИҢҮЧЕ

Айрат Гыйлаев (Чаллы, 1995, 1999, 2000, 2001, 2002, 2003, 2004, 2005, 2006, 2008, 2009, 2010)

10 ТАПКЫР ҖИҢҮЧЕ

Айдар Хәйретдинов (Балтач, 1998, 1999, 2000, 2001, 2003, 2004, 2005, 2006, 2007, 2008)

9 ТАПКЫР ҖИҢҮЧЕЛӘР

Илнар Әхмәтҗанов (Балык Бистәсе, 2002, 2003, 2004, 2005, 2006, 2007, 2008, 2009, 2010), **Ильяс Галимов** (Әлмәт, 2001, 2003, 2005, 2008, 2009, 2011, 2012, 2013, 2014), **Раил Нургалиев** (Теләче, 2008, 2009, 2010, 2011, 2012, 2013, 2014, 2018, 2020)

7 ТАПКЫР ҖИҢҮЧЕЛӘР

Сергей Павлик (Ульян, 2011, 2014, 2016, 2017, 2018, 2020, 2021), **Ренас Кәлимуллин** (Теләче, 2016, 2017, 2018, 2019, 2020, 2021, 2022)

6 ТАПКЫР ҖИҢҮЧЕЛӘР

Фидаил Шакиров (Балтач, 1973, 1974, 1975, 1977, 1978, 1979), **Рафаэль Сафиуллин** (Питрәч, 1985, 1989, 1990, 1993, 1994, 1997)

5 ТАПКЫР ҖИҢҮЧЕЛӘР

Данил Галиев (Түбән Кама, 1971, 1973, 1974, 1975, 1976), **Гакыйф Борһанов** (Түбән Кама, 1973, 1980, 1981, 1983, 1994), **Ранил Габдрахманов** (Балтач, 2000, 2002, 2004, 2006, 2008), **Илдар Аббасов** (Биектау, 2006, 2009, 2012, 2013, 2015), **Айдар Нәҗметдинов** (Чаллы, 1992, 1993, 1998, 1999, 2004), **Муса Галләмов** (Лаеш, 2016, 2018, 2019, 2020, 2021), **Артур Зөлкәрнәев** (Теләче, 2015, 2016, 2017, 2019, 2020)

4 ТАПКЫР ҖИҢҮЧЕЛӘР

Рәшит Сәмигуллин (Казан, 1980, 1981, 1990, 1991), **Фазыл Әхмәтҗанов** (Түбән Кама, 1976, 1981, 1982, 1985), **Михаил Чернов** (Питрәч, 1975, 1980, 1981, 1985), **Марсель Таһиров** (Әтнә, 1988, 1989, 1991, 1995), **Рафак Хәлиуллин** (Теләче, 1992, 1995, 1996, 1998), **Рифкать Хөсәенов** (Балтач, 1990, 1991, 1999, 2000), **Фарил Фатыйхов** (Мамадыш, 1980, 1982, 1983, 1984), **Рөстәм Гыйниятов** (Питрәч, 1988, 1989, 1995, 1998), **Хәмит Вәлиев** (Чаллы, 1989, 1992, 1995, 1997), **Наил Хәмидуллин** (Саба, 1967, 1968, 1971, 1975), **Рафил Сабиров** (Саба, 1985, 1988, 1989, 1990), **Илшат Сибгатуллин** (Чаллы, 2005, 2006, 2007, 2011), **Ришат Гайнетдинов** (Сарман, 2007, 2010, 2011, 2012), **Руслан Нургалиев** (Әлмәт, 2007, 2010, 2011, 2012), **Ринат Хәйретдинов** (Балтач, 2008, 2009, 2015, 2016), **Лениз Абдуллин** (Казан, 2009, 2011, 2015, 2016), **Булат Мусин** (Казан, Яңа Савин, 2014, 2017, 2018, 2022), **Илгиз Гайнуллин** (Яшел Үзән, 1978, 1979, 1983, 1985)

3 ТАПКЫР ҖИҢҮЧЕЛӘР

Рөстәм Мухамов (Казан, 2000, 2002, 2010), **Раббани Гайфуллин** (Тукай, 1969, 1971, 1973), **Максим Васильев** (Зәй, 1983, 1985, 1991), **Әсхәт Гайфуллин** (Саба, 1967, 1970, 1974), **Илмир Тәхфәтуллин** (Казан, 2017, 2018, 2020), **Нәфис Миңнебаев** (Биектау, 2013, 2015, 2018), **Айвар Билалов** (Әлмәт, 2012, 2014, 2015), **Илдар Гыйниятуллин** (Теләче, 2009, 2013, 2015), **Рузил Ганиев** (Әлмәт, 2005, 2010, 2014), **Искандәр Мортазин** (Әлмәт, 2018, 2019, 2021), **Рамил Синәкаев** (Әлмәт, 2015, 2016, 2022), **Радик Салахов** (Лаеш, 2015, 2016, 2022), **Вил Усманов** (Казан, 1993, 1994, 1998), **Ранис Галимуллин** (Лаеш, 2014, 2018, 2020), **Рамил Хисмәтуллин** (Чаллы, 2009, 2011, 2012), **Наил Зәйнуллин** (Түбән Кама, 1972, 1975, 1976), **Рәшит Исхаков** (Буа, 1984, 1985, 1986), **Рафис Насыйбуллин** (Балтач, 1980, 1982, 1988), **Рәүф Хөснетдинов** (Түбән Кама, 1992, 1995, 1997), **Фәнис Кадыйров** (Кукмара, 1995, 1997, 1998), **Раил Сәләхетдинов** (Кукмара, 2019, 2021, 2022), **Михаил Минеев** (Түбән Кама, 1972, 1976, 1978), **Тәбрис Маннапов** (Балтач, 1986, 1987, 1988), **Дәхизулла Зиннәтов** (Чаллы, 1984, 1987, 1992), **Раиф Сәхәбетдинов** (Зәй, 1993, 1994, 1997)

2 ТАПКЫР ҖИҢҮЧЕЛӘР

Габдулла Хафизов (Чаллы, 1964, 1966), **Габбас Әхмәдиев** (Түбән Кама, 1986, 1988), **Мөхәммәтнур Зәкиев** (Саба, 1985, 1988), **Илфир Әнвәров** (Актаныш, 1999, 2005), **Миңнерахман Ваккасов** (Кукмара, 1996, 1998), **Зәфәр Ханов** (Сарман, 1964, 1968), **Әгъзам Гобәйдуллин** (Яшел Үзән, 1977, 1978), **Рим Синәкаев** (Әлмәт, 1985, 1995), **Нәкметдин Җәлалиев** (Саба, 1969, 1970), **Вил Мәһдиев** (Бөгелмә, 1965, 1967), **Әүхәт Мөхәммәдиев** (Кама Тамагы, 1981, 1984), **Морат Әмирханов** (Актаныш, 2004, 2010), **Илшат Идиатов** (Арча, 2004, 2006), **Зәфәр Шакиров** (Казан, 1991, 1996), **Илсур Гыймадетдинов** (Кукмара, 2021, 2022), **Динар Кәримуллин** (Лаеш, 2020, 2022), **Наил Хәмидуллин** (Биектау, 1983, 1987), **Айнур Әнвәров** (Актаныш, 2003, 2006), **Рәмис Фәхретдинов** (Мамадыш, 1996, 1997), **Таһир Әхмәдов** (Кукмара, 1998, 2003), **Фәһим Ибәтуллин** (Кукмара, 2002, 2005), **Гомәр Гәрәев** (Арча, 1986, 1994), **Азат Галиев** (Саба, 2003, 2005), **Илнар Галимов** (Алабуга, (2019, 2021), **Якуб Дәминов** (Мамадыш, 1985, 1990), **Марат Саматов** (Мамадыш, 1988, 1989), **Марат Галиев** (Чаллы, 1987, 1992), **Рәшит Сафиуллин** (Питрәч, 1990, 1996), **Зөлфәт Вәлиев** (Әлмәт, 2001, 2003), **Илшат Шаймәрданов** (Кукмара, 2002, 2007), **Радис Сәйфуллин** (Арча, 1965, 1966), **Вазыйх Сөләйманов** (Аксубай, 1965, 1966), **Исмәгыйль Баязитов** (Зәй, 1972, 1977), **Максуд Солтанов** (Минзәлә, 1979, 1981), **Рафис Шәрифуллин** (Балтач, 1981, 1983), **Дамир Сафиуллин** (Балтач, 1982, 1984), **Илгизәр Гыйбадуллин** (Кукмара, 1993, 1994), **Миңнерасиф Гыйльманов** (Түбән Кама, 1994, 1997), **Рөстәм Вәлиуллин** (Кукмара, 1991, 1996), **Ришат Шәрипов** (Чаллы, 1996, 1999), **Радис Галләмов** (Балтач, 2000, 2001), **Рөстәм Хашимов** (Әтнә, 2000, 2002), **Илфат Әнвәров** (Актаныш, 1982, 1983), **Сәйдәш Мәгъсүмов** (Балтач, 1983, 1987), **Габделәхәт Миннәҗев** (Әлмәт, 1988, 1990), **Марсель Нургалиев** (Тукай, 1994, 2002), **Руслан Гәрәев** (Азнакай, 2001, 2003), **Фәнил Шәйхетдинов** (Казан, 2013, 2014), **Илмир Камалиев** (Казан, 2016, 2017), **Элдар Хәмитов** (Чаллы, 2017, 2021), **Илнар Закиров** (Алексеевск, 2020, 2021).

1 МӘРТӘБӘ ҖИҢҮЧЕЛӘР

Якуб Ибраһимов (Аксубай, 1970), **Раил Батыргәрәев** (Актаныш, 1965), **Рифкәт Мадьяров** (Актаныш, 1971), **Марс Гафаров** (Актаныш, 1988), **Нәфис Кәлимуллин** (Азнакай, 1988), **Айнур Вәлиуллин** (Алабуга, 1992), **Таһир Миннаҗев** (Арча, 1978), **Вәгыйз Миннаҗев** (Арча, 1979), **Әнәс Хәлилов** (Арча, 1987), **Габделбәр Хәлилов** (Арча, 1989), **Талип Яруллин** (Әлки, 1964), **Габдулла Ямалов** (Сарман 1964), **Рәшит Фәсахов** (Әлмәт, 1968), **Рим Ялалов** (Әлмәт, 2001), **Рамил Вәгыйзов** (Әлмәт, 2001), **Васыйл Гыйлаҗев** (Балтач, 1967), **Васыйл Гарифуллин** (Балтач, 1974), **Фәрит Әхмәдиев** (Балтач, 1977), **Марат Әхмәдиев** (Балтач, 1979), **Наиль Мөхәммәтгалиев** (Балтач, 1983), **Айдар Гәрәев** (Балтач, 1994), **Рашат Газизов** (Балтач, 2002), **Радис Сибгатуллин** (Биектау, 2001), **Евгений Колесников** (Бөгелмә, 1972), **Фоат Козырев** (Буа, 1971), **Әлфис Йосыпов** (Зәй, 1989), **Игорь Комаров** (Зәй, 1997), **Җәүдәт Хөсәенов** (Казан, 1986), **Марсель Дияров** (Казан, 1991), **Әнис Миндубаев** (Казан, 1992), **Рафил Әхмәтханов** (Казан, 1996), **Шамил Габдрахманов** (Казан, 1999), **Азат Шаһабиев** (Казан, 2002), **Нурсил Галиев** (Кукмара, 1972), **Илшат Гыйбадуллин** (Кукмара 1993), **Нуретдин Зыятдинов** (Кукмара, 1995), **Нияз Галимуллин** (Кукмара, 1996), **Ирек Тимербаев** (Кукмара, 2000), **Алмаз Галимуллин** (Кукмара, 2000), **Ягъфәр Зыятдинов** (Кукмара, 2001), **Рамил Кашапов** (Мамадыш, 1984), **Рафаэль Мөхәммәтшин** (Мамадыш, 1985), **Әлфәт Шәйдуллин** (Мамадыш, 1992), **Рәшит Бариев** (Минзәлә, 1966), **Фәрит Хәмитдинов** (Минзәлә, 1974), **Рөстәм Насыйбуллин** (Нурлат, 1984), **Иван Дмитриев** (Питрәч, 1984), **Александр Золин** (Питрәч, 1986), **Сабирҗан Шакиров** (Саба, 1968), **Минһади Касыймов** (Саба, 1986), **Хәлил Заһидуллин** (Саба, 1989), **Рафаэль Солтанов** (Сарман, 1973), **Фәрит Габдрахманов** (Сарман, 1984), **Хәлил Шәйхетдинов** (Теләче, 1991), **Хөсәен Исмәгыйлев** (Теләче, 1994), **Рамил Нургалиев** (Теләче, 1993), **Фидаил Мортазин** (Теләче, 1995), **Тәфкил Шәйхетдинов** (Теләче, 1996), **Илмир Зыябиев** (Теләче, 2002), **Нариман Әхмәтшин** (Түбән Кама, 1976), **Зөфәр Галимҗанов** (Түбән Кама, 1994), **Нәгыйм Мөҗәһитов** (Чаллы, 1969), **Василий Николаев** (Чаллы, 1970), **Фәрит Шәрипов** (Чаллы, 1986), **Габделнур Нигъмәтҗанов** (Чаллы, 1987), **Григорий Петров** (Чаллы, 1987), **Мөҗәһит Латыйпов** (Чаллы, 1987), **Марат Гәрәев** (Казан, 2004), **Сергей Байков** (Чаллы, 1990), **Рәшит Бәдретдинов** (Чаллы, 1990), **Геннадий Стрелков** (Чаллы, 1993), **Алмаз Исмәгыйлев** (Чаллы, 1997), **Тәнзил Хәмидиев** (Чаллы, 1999), **Ленар Закиев** (Чаллы, 1999), **Роберт Зәйнуллин** (Чистай, 1969), **Илһам Садыйков** (Чистай, 1991), **Марсель Хәйдәров** (Казан, 1991) **Фәрит Шәйхетдинов** (Яшел Үзән, 1977), **Ислам Фәлахов** (Алабуга, 2018), **Фәнил Миннаҗев** (Әлмәт, 2012), **Айнур Фазылов** (Чаллы, 2010), **Айнур Гәрәев** (Чаллы, 2003), **Азат Шәйхетдинов** (Теләче, 2000), **Марсель Гозәеров** (Әлмәт, 2014), **Ленар Садыйков** (Чаллы, 2021), **Ришат Исхаков** (Чаллы, 2020), **Айнур Сыртаев** (Чаллы, 2019), **Тимур Милютин** (Әлмәт, 2019), **Рөстәм Сәлахов** (Зәй, 2019), **Константин Морозов** (Мамадыш, 2017), **Сәйдәш Бәдриев** (Казан, 2017), **Рафаэль Хәсәнов** (Казан, 2015), **Рәмис Саматов** (Казан, 2014), **Илдар Гайнетдинов** (2013, Чаллы), **Илнар Галиев** (2013, Казан), **Хафиз Вәлиев** (Чаллы, 2012), **Руслан Әюпов** (Тукай, 2012), **Рашат Газизов** (Балтач, 2002), **Фаил Кәримов** (Мамадыш, 2008), **Дамир Борһанов** (Чаллы, 2007), **Рөстәм Заһидуллин** (2007, Балтач), **Артур Сафин** (Чаллы, 2009), **Айнур Гыйссаметдинов** (Казан, 2008), **Реваль Садыйков** (Түбән Кама, 2006), **Артур Билалов** (Әлмәт, 2005), **Айдар Галиев** (Саба, 2004), **Радик Хаҗиахмәтов** (Казан, 2004), **Алмаз Галимуллин** (Кукмара, 2000), **Зиннур Әхмәтҗанов** (Питрәч, 1994), **Юрий Сабанов** (Башкортстан, 2007), **Марат Мөхәммәтҗанов** (2019, Түбән Кама), **Ринат Шәйхетдинов** (Зәй, 2016), **Рамил Хәкимҗанов** (Арча, 2017), **Рамил Шафыйков** (Чаллы, 2008), **Ринат Әхмәтшин** (Чаллы, 2008), **Руслан Касыймов** (Кукмара, 2011), **Сергей Гусев** (Мамадыш, 2010), **Айдар Нәҗмиев** (Чаллы, 2013), **Ленар Иванов** (Түбән Кама, 2013), **Зөлфәт Хәсәнов** (2011, Биектау), **Илназ Миңмуллин** (Балтач, 2021), **Айназ Тимеров** (Чаллы, 2022), **Ранис Гыйлаҗетдинов** (Чаллы, 2022).

Кушымтаны әзерләделәр:
текст – Илнар ХӨСНУЛЛИН,
Лилия ГЫЙМАЗОВА;
дизайн – Марат ХӘБИБУЛЛИН

АЙРАТ ГЫЙЛАЕВ:

«МИҢА БУ ЯРЫШТА ҺӘРВАКЫТ УҢЫШ ЕЛМАЙДЫ»

«...Тормышны башлап җибәрергә зур терәк булды миңа көрәш. Спортта чыныккан характер авыр вакытларда дөрес юл сайларга ярдәм итә. Яшермим, финанс ягыннан да файдасын күрдем. Сәламәтлеккә, бер караганда, зыян салса, икенче яктан, яшәргә көч-куәт бирә. Монысын бала чактан ук аңладым, авылда үскән малайлар бит без. Бер аягыма өч мәртәбә операция ясатсам да, шөкер, әлегә йөрибез бит. Көрәшне ник сайладым икән дип үкенгәнем булмады. Тормышны яңадан башлау мөмкинлеге булса, барыбер бил алышуа башлар идем.

Иң яраткан ярышым, иң зур турнир ул минем өчен. Гәрчә хәзер дөнья чемпионатлары узса да. Миңа бу ярышта һәрвакыт уңыш елмайды. Балки, әзерлек яхшырак булгандыр. Көзге ярышларга килгәндә, җәйге ялдан соң әзерлек җитмәгән, курсәң. Ә Җәлил турнирында исә бар көчемне күрсәтергә тырыша идем. Кайсы җиңү истә калды дигәндә, әлбәттә, беренчесен онытып булмый. Тагын берсен яхшы хәтерлим әле. Анысы ахырга таба булды. Бер атна кала Азнакайда билбаулы көрәш буенча Татарстан чемпионаты узды. Йә әйтегез, кем инде Җәлил турнирына бер атна кала зур ярыш оештыра? Кыскасы, Азнакайдан грипп эләктереп кайттым. Гомергә ятып авырган юк иде. Моннысында ике көн юрган астыннан чыга алмадым. Ә көрәшергә кирәк. Тегеләй итеп, болай итеп, ничек тә аякка басарга, келәмгә чыгарга туры килде. Ничек отып чыкканмындыр – әле дә аңлый алмыйм.

Үз көрәшебезне югалтмасак иде. Егетләр киеп чыккан формага да, кагыйдәләргә дә кагыла бу. Бик еш бутыйлар ул кагыйдәләрне. Күтәреп атучылар булды, бөтерәләр дә куялар, аннары шуны санап утыралар. Татар көрәше бит инде ул гомергә күтәреп китеп, атып бәрә торган спорт төре. Һәрхәлдә, безнең вакытта шулай иде. Көрәшчеләрне дә аңлыйм, әгәр кагыйдә мөмкинлек бирә икән, ник артыгын тырышсын ул...»

«Ватаным Татарстан». 2021 ел

АЙДАР ХӘЙРЕТДИНОВ:

«КӨЧЛЕ ВАКЫТТА КӨРӘШЕРГӘ КИРӘК»

Үземне бүгенге көрәшчеләр белән чагыштырмыйм. Ник дисәгез, һәр кеше үзенең әзерлегенә, сәләтенә, хәтта тәрбиясенә карап көрәшә. Мин болай яки тегеләй итәр идем дигән сүз эш түгел ул. Мин көрәшкәндә дә килеп җитмәгән яклар булгандыр. Бил алышуым бөтен кешегә дә ошап беткәндер, дип әйтә алмыйм. Әйе, Муса Җәлил турнирын 10 тапкыр оттым, әмма җиңелгән вакытлар да булды. Әмма кемгәдер үпкә белдерел, кул бирмичә чыгып киткән вакыт булмады. Димәк, үзем эшләп бетермәгәнмендер, дип фикер йөртә идем.

Иң истә калган җиңү дигәндә, күңелемдә алай тасвирлап сөйләрлек вакыйгалар нишләптер күп түгел. Әлбәттә, Муса Җәлил турнирында беренче мәртәбә батыр калганымны хәтерлим. Берсендә ни өчендер абсолют батыр исеме өчен көрәшмичә кайтып киттем. Озак үкендем. Көчле вакытта көрәшергә кирәк.

Айрат Гыйлаев белән бил алышулармы? Аны җиңү республика ярышын отуга тәңгәл иде. Келәмдә көндәш булдык, хәзер аралашып яшибез. Бер-беребезгә хөрмәтебез зур. Икебез арасындагы очрашуларның исәбен аерым санап бара идем. Бер-беребезгә лаеклы көндәшләр булдык, шөкер, бүген дә бар андый егетләр.

Һәр чорның үз батыры, үз көрәше бар. Көрәшчеләр һәрвакытта да ярышка әзерләнеп килгән, келәмгә «җиңәм» дип чыккан. Әйе, бүген үз тормышын профессиональ дәрәҗәдә көрәшкә көйләгән, язмышын шуның белән бәйләгән егетләр бар. Тормышның кыйммәтләре үзгәрә. Кеше, акча табылса, барысы да була, уңышка ирештем, дип уйлый. Үзебездәге тренерларга кабатлап торабыз: балаларның акыл ягын да үстерергә тырышыгыз, дибез. Аларга тәрбия дә кирәк. Бер-береңә хөрмәт булырга тиеш. Батыр ул җиңүче генә түгел. Башкаларга үрнәк кеше дә. Үзен келәмдә генә түгел, аннан читтә дә бу исемгә лаек итеп күрсәтә белергә тиеш.

«Ватаным Татарстан». 2022 ел

ИЛЬЯС ГАЛИМОВ:

«ҖИҢҮГӘ НИЧЕК ИРЕШКӘННЕ ҮЗЕМ ГЕНӘ БЕЛӘМ»

«...Зур ярышлардан беренче уңыш китергәне 1996 елда булды. Өлкән үсмерләр бәйгесендә икенче урынны алдым. Олылар ярышында исә беренче медальне Зәйдә яуладым. «Ватаным Татарстан» газетасының кыһарман-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә уза торган бәйгесе иде ул. 85 килолы егетләр ярышында Кукмарадан Рәмис Фәхретдиновка оттырып, өченче урынны алдым. Шуңа күрә, Зәй һәм әлеге турнир аеруча истә калган. Гомумән, бу бәйгене иң көчле көрәшчеләр чыгыш ясаганы, дәрәҗәле булганы өчен аеруча үз итәм. Халык та ярата аны.

Җиңүләр күп булды. Әмма аларга ничек ирешкәнне үзем генә беләм. Җиңәр өчен иң элек теләк кирәк. Отам дип йөрисең икән, була. Әле хәзер дә атнасына өч тапкыр күнегүләргә йөрим. Ашау-эчүгә, режимга игътибар кирәк. Әчеп-тартып йөргән кеше чемпион була алмый. Ярышка әзерләнгәндә, үземне күкрәгемә медаль таккан итеп күз алдына китерә идем. Кеше хыялланып яшәргә тиеш. Бүгенге яшьләргә нәрсә киңәш итәмме? Халык яратырлык итеп көрәшергә кирәк. Айдар, Айрат, Ранилләр әнә шулай бил алышты. Келәмгә бүләк дип чыгарга ярамый, анысы соңрак үзе килә. Болар, әлбәттә, кешенең тәрбиясенә дә, тренерларга да бәйле.

Һәрбер җиңелүдән сабак алырга тырыштым. Үкенгәнем файда юк. Димәк, нәрсәнедер эшләп бетермәгәнсең, кабат тырышырга кирәк. Минем дә җиңелгән булды. Әмма якшәмбе көнне оттырып кайтсам, душәмбе тагын да ныграк үҗәтләнеп шөгыльләнә башлый идем. «Безнең урамда да бәйрәм булыр әле», – дип өметләндем...»

«Ватаным Татарстан». 2016 ел

РАИЛ НУРГАЛИЕВ:

«ИҢ ОЛЫ ҖИҢҮЕМ – АВЫЛДА БАТЫР КАЛУ»

«...Без үскәндә, авылда көрәш түгәрәгеннән башка берни юк иде. Йә шуңда барасың, йә урамда йөрисең. Башлангычта укыганда карыйм: авыл малайлары күрше авылга мәктәпкә төшеп бара. «Көрәш түгәрәгенә барабыз», – диләр. Нәрсә соң ул, дип кызыксынып бардым. Әле ул чактан бер вакыйганы искә төшереп торалар: мин, беренче көнне үк баскетбол тубына тибеп, мәктәп тәрәзәсен ватканмын икән. Кызыксынып киттем. Марсель Хатыйпович бер авылдан бик күп чемпионнар әзерләде. Районнарда гел беренче булсам да, республикада төшеп кала идем. «Активность» аркасында җиңеләм, аз гына җитми иде. Күңелем төша башлады. Безнең авылдан Марат Гәрәевнең ул чакта физкультура университетында укып йөргән чагы, шактый уңышлар күрсәтте: Чаллыда Муса Җәлил турнирында җиңде, «спорт остасы» исемен алды. Шулчак мин дә уземә: «Казанга укырга керәм, спорт остасы булам», – дип сүз бирдем. Марат мине Вакыйф абый Дәүләтшин белән таныштырды. Шуннан китте инде.

Беренче тренерым Марсель Хатыйпович: «Раил, авыл Сабан туенда батыр калырсың, сиңа бөтен авыл карап торыр, кызлар карап калыр», – ди иде. Чыннан да, минем көрәш карьерамда бик күп җиңүләрем булды. Иң олысы – авылымда беренче тапкыр батыр калып, тәкә алуым. Ул җиңү төмен беркайчан да онытмаячакмын! Бер атна буе авылда очып кына йөрдем. Бөтен көрәшчегә дә халыктан игътибар тою рәхәт. Синең эшеңне, үзеңне ошаталар икән, кемгә рәхәт түгел инде ул?..»

«Ватаным Татарстан». 2020 ел

«ЭШ» 1918–1920 | «ТАТАРСТАН ХӘБӘРЛӘРЕ» 1920–1922 | «ТАТАРСТАН» 1922–1924 | «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» 1924–1951

«ВТ» – 105 12 март 2023

1951–1960 «СОВЕТ ТАТАРСТАНЫ» | 1960–1992 «СОЦИАЛИСТИК ТАТАРСТАН» | 1992– «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

ЯБЫЛУ ИХТИМАЛЫ БАР ИДЕ

Төрле елларда төрле исемнәр белән нәшер ителгән бүгенге «Ватаным Татарстан» газетасы, әлбәттә, ил, Татарстаныбыз язмышына бәйле. Газета вакыйгаларны тарихка язып калдырды, бүген дә әлеге вазыйфаны бик үтемле итеп башкара.

Вакыйгаларның газета редакциясе коллективына җил-давыл булып кагылган чоры да булды. Бу нисбәттән минем 1991 елны күздә тотуым. Бөек Ватан сугышы чорында да нәшер ителгән газета чак кына ябылмый калды. Шул заманда илдә үзгәртеп кору бара иде. 1990 елның 12 мартында СССР халыкларының III съезды СССР Конституциясенең 1 нче бүлегеннән «КПСС Совет җәмгыятенең җитәкче һәм юнәлеш бирүче көче политик системасының ядросы» дигән маддәне гамәлдән алып ташлады. Шулай итеп, партия, совет органнарында да үзгәрешләр башланды. КПССның шәһәр, район комитетлары беренче секретарьлары шәһәр, район Советлары рәисләре кәнәфиенә күчеп утырдылар.

Әлеге аерылышу, бүленешүләрнең җиле җитмеш ел буена КПСС өлкә комитеты, ТАССР Министрлар Советы, ТАССР Югары Советы президиумы органы буларак нәшер ителгән «Социалистик Татарстан», «Советская Татария» газеталарына да кагылды. Татарстан Югары Советы, Министрлар Кабинеты белән берлектә үз газеталарын булдыру, ягъни «Татарстан хәбәрләре», «Известия Татарстана» газеталарын нәшер итү турында карар кабул иттеләр, «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталарын КПССның Татарстан рескомы газеталары итеп

калдыру күздә тотылды. Нәкъ шулай булды да, редакцияләрнең яңа уставлары кабул ителде, газета тарихында беренче тапкыр редакция коллективы оештыручы итеп теркәлде. Соңыннан, 1991 елның августында КПСС өлкә комитеты эшчәнлеген туктаткач, ГКЧП белән мөнәсәбәтле, бу гамәл «Социалистик Татарстан»ны саклап калуда мөһим роль уйнады. Чөнки редакция уставында оештыручыларның берсе гамәлдән чыкса, редакция хокукларының икенче оештыручыга күчүе каралган иде. 1991 елның 27 августыннан «Социалистик Татарстан»ның бердәнбер оештыручысы булып, уставта каралганча, хезмәт коллективы калды һәм финанслау туктатылды. Бүген-иртәгә газетаның ябылу ихтималы, билгесезлек редакция хезмәткәрләрен нык борчуга салды, хезмәткәрләрнең байтагы «Татарстан хәбәрләре»нә эшкә күчте. Шулай да 165900 данә газета график буенча чыга торды, банкта редакциянең үз исәп-хисап счетын ачтык. Рәхмәт, ул вакыттагы газета-журналлар нәшрияты директоры Владимир Гаврилов, хәлне аңлап, газетаны нәшрият хисабына бастырды.

Әлбәттә, «Социалистик Татарстан» газетасының баш мөхәррире буларак, мин үзем дә, «Советская Татария»нең баш мөхәррире Е.А. Лисин да җитәкчеләргә юлны суытмадык, теләк-фикерләрне җиткерә тордык, хөкүмәт финансламаса да, барлык законнарны, рәсми хәбәрләрне халыкка җиткереп бардык. Һәрнәрсәне төптән уйлап, сабырлык белән хәл итә торган Татарстан Дәүләт Советы рәисе Минтимер Шәймиев, газеталар редакцияләренә бәйле мәсьәләне уртага салып сөйләшкән һәм газеталарны саклап калуга мөнәсәбәтле җитди карарга да килингән. Тора-бара «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татарстан» газеталарын оештыручылар итеп Татарстан Югары Советы Президиумы һәм Татарстан Министрлар Кабинеты тәгаенләнде.

Бүген «Ватаным Татарстан» исеме белән нәшер ителүче газета 105 яшьлегенә җиткән икән, болганчык елларда газетабызны саклап калган Беренче Президентыбыз Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә рәхмәтле без. Мин исә «Ватаным Татарстан»да эшләвем белән бәхетле.

Мөнир ӘҺЛИУЛЛИН,
1990–1996 елларда газетаның
баш мөхәррире, XII чакырылыш
Татарстан Югары Советы депутаты

Үткән гомер җәл түгел

Егерме ел буе әвәрә килеп яшәгән «Татарстан яшьләре» газетасыннан китүне бик авыр кичердем. Әйе, «яшәгән» диюдә ялгышлык юк, без яшьләр газетасында эшләп кенә калмыйча, яши идек. Харис абый Әшрәфҗанов белән дә, Хәлим абый Гайнуллин белән дә редакциябез башкалардан нык аерылып тора иде. Ә инде баш мөхәррир итеп Исмәгыйль Шәрәфиевне сайлагач, без тулысынча диярлек бер гаиләгә әверелдек. Туктаусыз командировкалар, берсеннән-берсе кызыклырак темага язмалар, атлаган саен диярлек уйлап чыгарылган бәйгеләр, фестивальләр һәм котчыкмалы тиражлар. Безне исемләп беләләр, таныйлар, санлашалар.

Шулай яшәп ятканда, мине Хөкүмәт йортына чакырдылар. Андый җирләргә йөреп гадәтләнмәгәнлектән, шөбһәләнеп кенә Премьер-министр урынбасары ишеген шакыдым. Ипле-җайлы Зилә ханым Вәлиева, үзе дә оста журналист буларак танылган кеше, мине «Ватаным Татарстан» газетасына баш мөхәррир итеп билгеләргә теләүләрен хәбәр итте. Шундый ышаныч белдерүләренә эчтән генә сөенеп куйсам да, мин ул көнне: «Бу зур эшкә әзер түгел, андый коллективны үз өстемә ала алмыйм», – дип баш тарттым. Бу минем ихлас әйтелгән сүзләрем иде. Күпчелеген ап-ак чәчле олпат, безнең ише яшь-җилкенчәк белән исәнләшеп тә тормаган каләм ияләре тәшкил иткән коллективны җитәкләүне мин күз алдына китерергә дә курка идем. Аннары, безнең «Татарстан яшьләре»нең гөрләп эшләп торган, бушлай фатирлы гына итеп калмыйча, заманына күрә иң зур хезмәт хакы түләгән вакытында ничек итеп капыл гына китеп барасың ди. Кайткач, Исмәгыйльгә дә сөйләп күрсәттем. «Сине җибәрү миңа да җиңел түгел, ну синең кулыңнан килерлек эш инде ул», – дип, минем кирелегем белән килеште.

Инде онытылды дигәндә, тугыз айдан тагын Зилә ханымга чакырдылар. Бу юлы китәр алдыннан Исмәгыйль миңа кабат киреләнеп маташмыйча гына ризалашырга киңәш итте: «Зилә башта мине кодалаган иде, минем көч-дәрман җитми анда, синнән буласын мин әйттем. Яшьлегең бар, көчең җитә – килеш».

Ике-өч елга чыдый алсам, дип тәвәккәлләгән идем, 16 ел узганын сизми дә калганмын. Теләмичә, яратмыйча эшләсәң, моның кадәр түзеп булмас иде. Төрлесе булды: чарасызлыкның чигенә җиткәндә, күкләргә ялварып, сабырлык сораган авыр чакларым да, редакциябезнең игътибардан читтәрәк калып килгән ике язучыбызны Тукай премиясенә тәкъдим итеп, комиссиядәгеләрне шуңа инандыра алган сөенечле көннәребез дә, анализлап, йөрәккә якын алып язылган тәнкыйть язмаларыбызның гадәти күренешкә әверелүе дә. Болар барысы да – аерым-аерым бер тормыш этабы. Сыйфатлы журналистиканың нинди булырга тиешлеген без үз мисалыбызда раслап күрсәтә алдык. Иң авыр чакларда да планканы төшермичә, саргаю юлына кермичә, ихласлыгыбыз һәм яхшы мәгънәсендәге үҗәтлегебез белән укучыларыбызны да, Татарстан җитәкчелеген дә үз принципларыбызга инандыра алуыбызны татар журналистикасының тарихи традицияләрен лаеклы дәвам иттерү дип карарга кирәктер. Без беркайчан да җил искән уңайга бармыйча, фәкать фактларга гына таянып, тормыштагы вакыйгаларны үз бәябезне көчләп такмыйча җиткерү ягын карадык. Бу бик тә тынгысыз, борчу-мәшәкать китерә торган тормыш иде. Ул еш кына үткен пычак өстеннән йөрүне хәтерләтә иде. Әмма шул чактагы үз-үзебезгә ышану, фидакарьлек, һөнәребезнең җәмгыятьтәге ролен тирәнтен аңлау безгә башкача эшләргә урын калдырмады.

Болай эшләүнең рәхәт яшәү чигенә сыймаганын без бик яхшы аңлый идек. Ләкин үз рәхәтлеге өчен түгел, ә җәмгыятьне бер мыскалга гына булса да үзгәртә алуга иннануы, шул инануның башкаларга йогуын күрү өчен җан атуы каләм иясенә аңлатып булмаслык көч өсти, иманын ныгыта.

Тормыш сынауларын һәркайсыбыз үзенчә үтә. Әмма аларга бәяне вакыт үзе билгели. Бүген, газетаның миннән башка гына чыккан чорында да шул рухның исән-имин булуын күрүне, үзем эшләгән чорда басылган бер генә язма өчен дә уңайсызланмыйча, кешеләр күзенә туры карый алуны иң зур бәхет, безгә – журналистларга куелган иң зур бәя дип саныйм. Азаккача шулай булса иде, дим.

Миңназыйм СӘФӘРОВ,
«Татарстан» дәүләт
телерадиокомпаниясенең милли
тапшырулар хезмәте җитәкчесе,
«Ватаным Татарстан» газетасының
2003–2019 еллардагы баш
мөхәррире

ФИДАКАРЬЛӘР ШӨГЫЛЕ

Үзенең бөтен гомерен татар журналистикасына багышлаган, утыз ел буе «Ватаным Татарстан»ның элгәре булган «Кызыл Татарстан», «Совет Татарстаны», «Социалистик Татарстан» газеталары редакцияләрендә хезмәт куйган танылган журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мәрьям Мозаффар кызы Дибаева үзенең истәлекләрендә болай дип язган иде: «Ватаным Татарстан» – минем университетым, мәхәббәтем, бөтен тормышым. Гомер юлымдагы бөтен шатлыкларым һәм кайгыларым, табышларым һәм югалтуларым шушы газета редакциясендә булды. Мин аңа чиксез рәхмәтлемен һәм бурычлымын».

Минемчә, төрле елларда, төрле чорларда «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясендә эшләп киткән журналистларның һәм хезмәткәрләрнең күбесе шулай дип әйтә алыр иде. Чөнки «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе татар журналистлары өчен чын мәгънәсендә һөнәри чарлану үзәге, тормыш мәктәбе иде. Анда эшләү һәр журналист өчен зур дәрәҗә булып саналды. Мин шәхсән әле бүген дә гомерләренең күп өлешен әлеге газета редакциясендә хезмәт итүгә багышланган олпат журналистларыбыз – Шәмси Хамматовны, Рафак Тимергалинны, Миншәех Зәбировны, Равил Сәгъдиевне, Мөдәррис Мостафинны, Заһидулла Шәфигуллинны, Марат Әмирхановны зур хөрмәт белән искә алам.

Тарих чоңгылларына бик тирән кермичә, егерменче гасырның икенче яртысында, егерме беренче гасыр башында редакциядә хезмәт куйган күп хезмәттәшләремне олы ихтирам белән хәтердә саклыйм. Рәис Сабиров, Мөнир Әһлиуллин, Мөнир Абдуллин, Миргалим Харисов, Нургали Булатов, Ислам Әхмәтҗанов, Габделбәр Ризванов, Илдус Илдарханов һәм башка күп журналистлар – бөтен республикага танылган шәхесләр. Алар газетаны кызыклы һәм укылышлы итеп чыгару өчен күп көч куйдылар.

Редакциядә талантлы журналистлар күп иде. Алар бүген дә тырышып хезмәт итәләр. Әмма минем исемнәре киң даирә газета укучыларга мәгълүм булмаган кайбер хезмәткәрләрне дә искә алып үтәсем килә. Аерым алганда, озак еллар редакциядә тәрҗемәче булып эшләгән Мәгъсүмә Гарипова, машинистка Флера Шәмсетдинова, рәссам Әнәс Әмирханов, фотохәбәрче Мидхәт Шакирҗанов һәм башкалар газета вакытында чыксын, укылышлы булсын өчен зур тырышлык куйдылар.

«Ватаным Татарстан» газетасы турында сүз чыккач: «Газета күп тапкыр исемен алыштырса да, үз мәсләгенә тугрылыклы булып калды», – дигән сүзләрне ишетәбез. Анысы шулай, бу бик сөендерә. Газета оешканнан бирле аның игътибар үзәгендә татар халкының язмышы, аның тарихы, теле, әдәбияты, мәдәнияте булды. Һәм шулай булып кала да. Әмма һәр чорның үз кыйммәтләре, үз проблемалары була. Шуңа күрә газетага да үзгәрергә, заман куйган таләпләр яссылыгында эш итәргә туры килә.

Үткән гасыр азагында, яңа – егерме беренче гасыр башында без шундый халәткә килеп кердек тә. СССР таркалгач, Коммунистлар партиясе таратылгач, күп нәрсә үзгәрде. Коммунистик идеалларны, социалистик яшәү рәвешен пропагандалауны кискен туктатып, халыкны яңа шартларда яшәргә өйрәтергә кирәк иде. Бу хәл матбугат чараларын бик кыен хәлдә калдырды. «Ватаным Татарстан» газетасын оештыручылар составыннан КПССның Татарстан өлкә комитеты алып ташланды. Ә бит ул төп оештыручы булып санала иде. Бу хәл югары даирәләрдә дә шактый ыгы-зыгы тудырды. Берәүләр: партия үзе сәяси аренадан киткәч, аның газетасы да бетәргә тиеш, дип фикер йөртте; икенчеләре, газетаның матди базасын файдаланып, бөтенләй башка юнәлештәге газета оештыру идеясен алга сөрде. Газетаны хосусый басма итү турында уйланучылар да бар иде. Матбугат һәм мәгълүмат министрлыгы вәкаләтләрен «Татмедиа» агентлыгына тапшыргач, хәлләр тагын да катлауланды. Яңа структура хезмәткәрләре арасында матбугат чаралары үзләрен үзләре тәэмин итәргә тиеш, дигән караштан чыгып эш итүчеләр дә бар иде. Тиражларның нык кимүе; күпсанлы яңа газета-журналлар барлыкка килү сәбәпле, журналист кадрларга зур кытлык булган шартларда байтак редакцияләр бик кыен хәлдә калды. Татар телендә чыга торган матбугат чараларының хәле аеруча авыр иде. Менә шундый шартларда Татарстан Президенты, Дәүләт Советы, Министрлар Кабинеты «Ватаным Татарстан» газетасын оештыручылар итеп Татарстан Дәүләт Советын, Министрлар Кабинетын, редакция хезмәт коллективын билгеләү турында карар кабул иттеләр. Бу бик урынлы һәм вакытлы чара булды. Нәтиҗәдә бай традицияле, халкыбыз тарихында мөһим роль уйнаган матбугат чарасы сакланып калды, аның нәтиҗәле эшчәнлеге өчен тиешле шартлар тудырылды.

Редакция коллективына алга таба да иҗат уңышлары, яңа табышлар һәм казанышлар телим.

Габделхак ШӘМСЕТДИНОВ,
газетаның 1996–2003 еллардагы
баш мөхәррире, тарих фәннәре кандидаты

РӘХМӘТ СҮЗЕ

Кадерле әтиебез, ир, абый, бабаебыз Әфраим Хәлиулла улын соңгы юлга озатуга ярдәм итүләре, бу авыр көннәрдә олы кайгыбызны уртаклашулары өчен Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановка, Рәис Администрациясе, республика Министрлар Кабинеты, районнар хакимиятләре башлыклары, Аксубай районы администрациясе, Аксубай районы мөхтәсибе, республика Урман хуҗалыгы министрлыгы, Нурлат районында яшәүчеләр һәм коллегаларыбызга, Нурлат шәһәре «Яшьлек» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Аксубай шәһәр тибындагы бистәсе универсаль технологияләр техникумы, Аксубай районы үзәк хастаханәсе, «Сельская новь» газетасы редакциясе коллективларына, якыннарыбыз һәм туганнарыбыз, бик күп дусларыбыз һәм күршеләребезгә, Яңа Дума авылы халкы һәм мәктәп коллективына эчкерсез рәхмәтебезне белдерәбез.

Кузюровлар гаиләсе

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың агросәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык намуслы хезмәтләре өчен «Авангард» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Абрамов** Виктор Ильич, «Майский» теплица комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 5 номерлы цехы теплица эшчесе (Татарстан Республикасының Зеленодольск районы) **Александрова** Алевтина Васильевна, «Вафин Радик Кадыйр улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Лаеш районы) **Вафин** Радик Кадыйр улы, «Красная Заря» җитештерү авыл хуҗалыгы кооперативы тракторчысы (Татарстан Республикасының Биектау районы) **Сабиров** Нәҗип Лотфулла улы, «Игенче» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте бозау караучысы (Татарстан Республикасының Теләче районы) **Шәймәрдәнова** Гөлсинә Рәхимулла кызы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Балык Бистәсе үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Иванаево фельдшерлык-акушерлык пункты фельдшеры **Афанасьева** Альбина Петровнага, Казан шәһәренең «7 номерлы балалар шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибының оештыру-методика эше буенча урынбасары **Гатауллина** Гүзәл Сирень кызына, Казан шәһәре «Сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең кабул итү бүлекчәсе өлкән шәфкать туташы **Ларина** Нина Евгеньевнага **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Балык Бистәсе Агрохимсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе **Лаврентьев** Сергей Владимировичка **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Борчылу

«Салават күпере»... исләре

Исе сасы! «Салават Күпере» торак комплексында яшәүчеләрдән мондый мөрәҗәгатьләр еш ишетелә. Үземнең дә бик күп танышларым шул якта ипотекага торак алды. Шәһәрдән читтәрәк булуына да иялэштеләр инде, «бөке»ләргә дә исләре китми. Ә менә сасы ис үзәккә үтә. Кемдер аны янәшәдәге заводларга сылтаса, тавык үстерүчеләргә дә ым кагучылар булды. Татарстан экологлары да әлеге проблеманы күптәннән өйрәнә. Чираттагы рейдка алар иртәнге алтыда ук чыкты. Бу юлы зарлар Авиатөзелеш районында яшәүчеләрдән дә килгән.

Һава пробаларын алу ике урында башкарылды. Аны Татарстанның Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының күчмә экологик лабораториясендә һәм Роспотребнадзор лабораториясе белгечләре тарафыннан куелган махсус җиһазлар ярдәмендә автоматик режимда алдылар. Һава пробасын «Салават Күпере» торак комплексында Наил Йосыпов урамы, 5 һәм Камышинская урамы, 84 адресы буенча Төньяк торак массивында тикшерделәр.

Экология һәм табигать ресурслары министрының беренче урынбасары Айрат Шиһапов хәбәр иткәнчә, 2022 елда Казанның Киров һәм Мәскәү районнарында, шулай ук «Салават Күпере» торак комплексында атмосфера һавасы сыйфатына бәйле мөрәҗәгатьләр арткан. Бер ел эчендә 261 зар килгән.

– Экология министрлыгы, Росприроднадзорның Идел-Кама төбәкара идарәсе хезмәткәрләре белән берлектә, атмосфера һавасын тикшерергә «Салават Күпере» торак комплексында яшәүчеләр белән бергә чыктык. Иснең каян килгәнен ачыклар өчен, бик күп тикшеренүләр уздырылды. Сасы иснең сәбәпчесе өч оешма булырга мөмкин дигән нәтиҗәгә килдек. Әмма соңыннан табигатькә зыян салучыны ачыкладык. Ул «ПЖКХ» идарәче компаниясенең Химия урамындагы каты көнкүреш калдыклары полигоны булып чыкты, – ди Айрат Шиһапов.

Әлеге оешма административ җаваплылыкка да тартылган. Аларга шулай ук нормативларсыз эшчәнлек алып барган өчен 18,9 млн сум өстәмә түләтү турында таләп җибәрелгән. Хәзерге вакытта идарәнең дәгъваларын Татарстанның Арбитраж суды карый.

Халыкның үтенеченә колак салып, министрлык Киров районының 188 нче күппрофильле лицее, Илһам Шакиров проспекты, 3 нче йорт территориясенә атмосфера һавасының пычрануына автоматик контроль станциясе урнаштырды. Станция тәүлек буе автомат режимда һава үрнәкләрен сайлап алачак.

Еллык эшләренә нәтиҗә ясаганда, Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең (Росприроднадзор) Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе Фаяз Шакиров та бу яклардан зар еш килүен әйткән иде. Ул да «Салават Күпере»ндә һавада формальдегидның – 1,5 тапкыр, күкерт газының 2,3 мәртәбә артык булуын ачыклауларын сөйләде. Димәк, һаваны чистартырга кирәк. Тик менә ничек итеп? Бар ышаныч – пычратучыларның эшенә җаваплы карый башлавында. Каты көнкүреш калдыкларын тиешенчә урнаштырсалар, бәлки, бу ис чыкмас та иде. Халыкта мең сорау. Алар инде әлеге полигонны үзләре күмеп куярлык булган.

Биредә яшәүчеләрнең бөтен үтенечен истә тотып, Татарстанның экология һәм табигать ресурслары министры Александр Шадриков табигатьне саклау оешмаларын «ПЖКХ» идарәче компаниясе белән очраштырды.

– Һаваны пычратуны туктатырга кирәк! Тикшерүләр шуны күрсәтә: биредә һавада күкерт газы нормадан артып китә. Без бу эшне бергәләп башкарырга тиеш. Сулаган һаваның сыйфаты монда яшәүчеләрнең сәламәтлегенә зыян салырга тиеш түгел, – ди Александр Шадриков.

Очрашуда катнашкан зыян салучы «ПЖКХ» идарәче компаниясе җитәкчесе Дмитрий Петров һава сыйфатын ничек яхшырту буенча үз тәкъдимен дә җиткерде. Алар сасы исне бетерергә сүз бирә. Бу юнәлештә эшләячәкбез, ди. Тикшерүчеләр аларга бер ай вакыт бирде. Полигон эшчәнлеге дә контрольгә алыначак. Моннан соң «Салават Күпере»ндә яшәүчеләр соравына Дмитрий Петров җавап бирәчәк. Аңа халык белән очрашып сөйләшергә дә куштылар.

Гөлгенә ШИҺАПОВА



ҺАВАДАГЫ КҮКЕРТ ГАЗЫНЫҢ ЗЫЯНЫ:
- ✓ баш әйләнә, баш авырта;
- ✓ күңел болгана;
- ✓ күп булса, үпкәләрнең шешүенә һәм үлемгә китерә.

ИСЕ:
- ✓ сасыган йомырканы хәтерләтә.

ФОРМАЛЬДЕГИДНЫҢ ЗЫЯНЫ:
- ✓ күзләр әчетә, борыннан су ага;
- ✓ күп булса, бөер һәм бавырны зарарлый.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Гашыйклар көне белән!

Бер мәлне февральнең уртасы алдыннан социаль челтәрләрнең берсендә шундыйрак котлау куйган идем, укучыларымның бер ише бик өнәп бетермәде: «Бу ят дин белән бәйле нәрсә, безнең халыкка хас түгел», – дип, минем наданлыкны фашладылар.

Бәлки алар хаклыдыр инде. 14 февральне руслар «Святой Валентин» көне дип атыйлар бит. Татарларның бере ише, үзенчәләштереп, «Изге Вәли» дип җиппәрә. «Изге» сүзе белән билгеләнгән затлар, нигездә, чит-ят мәдәниятләрдән кергән булып чыга, чөнки татарда да, мөселманда да кешеләрне андый сыйфатлар белән атау гадәте юк. Һәм читтән кергән шул «изге»ләрне тарихи чыганаклардан эзләп, әкиятләрдән арындырып карасаң, аларның я дөньяда бөтенләй яшәмәгәнлеге, я бик үк изге булмаганлыгы ачыклана. Шулай булгач, Валентин белән бәйле бу бәйрәм безгә хас түгел, диючеләр хаклы булып чыга.

Ләкин мин бит Валентин көне белән дә, Изге Вәли көне белән дә түгел, ә Гашыйклар көне белән котладым. Күптән котлыйсы килеп йөри иде. Яраткан кешеләрем артык күп булган өчен генә түгел. Гыйшык тойгыларын, ярату хисен аяк астына салып, заман яшьләрен «мәхәббәт белән шөгыльләнү» дәрәҗәсенә төшергән чорда «Гашыйклар көне» дигән төшенчә бик матур яңгырый. Ул булырга тиештер.

Ә «Изге Вәли көне» турындагы мәгълүматларның берсен дә төгәл дип булмый. Берәүләр аны борынгы Римдагы көтүчеләр бәйрәме Луперкалии (Луперк алла хөрмәтенә уздырылган тазарыну һәм уңыш-үрчем теләү көне) белән бәйли, икенчеләр аны кире кагып, үзләренчә гөманлый, өченчеләр… Кайбер урыннарда дөреслек эзләүдән бигрәк, тарихчыларның һәм дин әһелләренең әлеге бәйрәмне үз ихтыяҗларына яраклаштырырга тырышуы да чалынып кала. Хәтта моның нигезен гадәти булмаган җенси бәйләнешләргә илтеп терәргә маташучылар да табыла. Барысы да гадәттәгечә инде… Бүгенгедә намус һәм гаделлек юк икән, тарихта дөреслек була алмый. Ләкин аның бер риваяте кызык.

Урта гасырда Римда император булып торган Клавдий II шундыйрак карар чыгарган, имеш: батырларча сугышсыннар өчен, ир-егетләргә – өйләнү, ә хатын-кызларга кияүгә чыгу тыела. Гади бер табиб булып эшләүче Валентин исемле кешегә императорның шундый сантый карары ошамый. Ул гашыйк парларны, егетләрне һәм кызларны, очраштырып, күрештереп тора. Бер заман Валентинның бу кырын эшен Клавдий императорга җиткерәләр. Ул Валентинны үлемгә хөкем итә. «Таш капчык»та үлемен көтеп, газиз башы белән бәхилләшеп яткан яшь егет төрмәне саклаучы абзыйның Юлия исемле кызын дәвалый, яшьләрнең бер-берсенә күзе төшә, гашыйк булалар. Валентин сөйгәненә мәхәббәтен аңлатып, йөрәк рәвешендәге кәгазь битенә хат язып калдыра. Ахырдан «Синең Валентиның» дип култамга сала. Юлиягә бу язманы Валентинның башын кискәннән соң гына укырга насыйп була. Үлем җәзасы, имеш, нәкъ 14 февраль көнне була. 286 нчы елның 14 февралендә.

Бу риваять кенә инде. Асылда, «Изге Валентин» дип йөртелүчеләр өчәү булса да, «изге» дигән титул аларга башка гамәлләре өчен бирелгән. Ләкин шушы риваятьне Валентин бер җенестән булган затларның кавышуына булышлык иткән, дип үз якларына борып җибәрүчеләр бар. Кемнәр икәнлеге аңлашыладыр инде…

Шуңа күрә, бу бәйрәмне бернинди «Изге Вәли»ләр белән дә бәйләп карарга кирәкмидер. Төгәл генә билгеле тарихы да юк бит. Римдагы Валентинның, христиан диненә дә, татар Вәлиенә дә катнашы юк. Менә шул катнашы булмаган нәрсәләрдән арындырып, «Гашыйклар көне» итеп калдырылса, начар түгелдер кебек. «Безгә хас түгел, читтән кергән», – дип йөз чөерү дөресме икән? Хәзерге бәйрәмнәрнең барысы да диярлек татарга читтән кергән инде – 8 Март та, 1 Май да… Боларның берсе дә татарның ат тоягы астыннан яки бәрәңге бакчасында шытып чыккан нәрсәләр түгел. Мәхәббәте исән, гашыйклары бар икән, димәк, «Гашыйклар көне» булу да табигый.

Ә чынында мин һәрбер көннең гашыйклар көне булуын теләр идем. Мәхәббәтнең чалымнары чиксез бит аның. Без һәрвакыт кемгәдер, нәрсәгәдер гашыйк. Сөйгән кешебезгә, сайлаган һөнәребезгә, эшләгән эшебезгә, туган җиребезгә, торган җиребезгә… Санап бетергесез. Бер карасаң, без мәхәббәт эчендә яшибез. Хәтта эт булып арып, төн уртасында кайтып егылсак та, таңда уянабыз да яңа туган көнгә гашыйк булабыз. Ул безне яшәтә, без аны матурларга омтылабыз. Һәрбер таңда үзеңне дә, якыннарыңны да шул бер сүз белән котларга мөмкин бугай:

– Гашыйклар көне белән!

ЯШЬ ГАЛИМ ИРЕК МӨХӘММӘТДИНОВ:

«БЕРКАЯ ДА КИТӘРГӘ ҖЫЕНМЫЙМ»

Горурлык

КФУ доценты Ирек Мөхәммәтдинов нефть чыгаруның яңа ысулын тәкъдим итә. Махсус катализатор уйлап тапкан өчен ул Россия Президенты премиясенә ия булды. Яшь галим узган атнада Мәскәүдә Владимир Путин белән очрашып кайтты. Ирек Мөхәммәтдинов белән аның ачышлары, киләчәккә планнары турында сөйләштек.

– Президент премиясе лауреаты булыр өчен дүрт ел дәвамында авыр нефтьне җиңеләйтүче катализаторлар булдырып, аның нефтькә йогынтысын тикшереп, промысел сынаулары үткәрдек. Моның өчен безгә «Татнефть», РИТЭК, «Зарубежнефть» оешмалары ярдәм күрсәтте. Казанышларыма шундый зур бәя бирелү минем өчен көтелмәгән хәл булды. Башта ышанып та бетмәдем. Кремльдә ил башлыгы котлап, минем белән сөйләшеп утырыр дип хәтта күз алдыма да китермәгән идем. Мин – Чаллыда туып-үскән гап-гади татар егете. Дөресен генә әйткәндә, миндә дулкынлану да, сөенү дә, бәхет һәм курку хисләре берьюлы булды. Безнең эшебезне шулай зурлаган өчен бик рәхмәтлемен, – ди 33 яшьлек Ирек Мөхәммәтдинов.

Алдагы ачышлары да нефтькә кагылышлы булыр дип уйлый ул. Аның әйтүенчә, катализаторларга бәйле фәнни казанышларын дәвам итәчәк.

– Без ачышлар ясау белән әле шөгыльләнә генә башладык, тәүге адымнарны ясыйбыз. Катализаторлар нефтьле җир катламына акватермолиз технологиясе ярдәмендә тәэсир итә, зур сумала һәм асфальт молекулаларын җимереп, авыр нефтьне җиңеләйтеп, сыегайтып җибәрә, нефтьнең химик составын яхшы якка үзгәртә. Бу үзгәрешләр авыр һәм үзлелеге югары булган нефтьне чыгаруны бик күпкә җиңеләйтә, – дип сөйләде ул хезмәте турында. – Бу ачыш, чыннан да, бик кирәкле һәм актуаль, чөнки җиңел нефть күләме кими бара, ә республикабызда һәм, гомумән, Россиядә авыр нефть күп. Безнең ачышыбыз илебезгә нефть чыгару буенча алдынгылыкны югалтмаска ярдәм итәчәк.

Гадәттә, техник галимнәрнең татарча белүе чамалы. Ирек туган телен бик яхшы белүе белән дә сокландыра. Әнисе Рәйханә – Яңа Чишмә районының Шахмай, әтисе Изаил – Оренбург өлкәсенең Абдуллин районындагы Иске Шалты авылыннан. Гаиләдә татар һәм рус телендә аралашалар.

Ирек Мөхәммәтдинов Чаллы шәһәренең Пушкин исемендәге 78 нче лицейны тәмамлаган. Мәктәптә яхшы билгеләргә укыган. «Укытучылар бик көчле иде. Барыбызның да яхшы укып, югары уку йортларына керәсе килде», – ди ул мәктәп еллары турында.

Химия фәненә мәхәббәтне анда укытучысы Наталья Нәбиуллина уяткан. Укучысының кызыксынуын күреп, олимпиадаларга әзерләгән. Ирек 9 нчы сыйныфтан төрле олимпиадаларда катнашып, беренче урыннар яулаган. Алдагы һөнәри юлын сайлаганда, кая барырга, дип аптырап калмаган. Казан дәүләт химия-технология университетының нефть һәм нефть химиясе факультетына укырга кергән.

– Университетта укыганда нефть химиясе, нефть чыгару, эшкәртү турында кызыксына башладым. Белемемне арттыру, фәнни эшләр белән шөгыльләнү өчен, укуымны аспирантурада дәвам иттердем. Казан федераль университетының Геология институтына аспирантурага кердем. Шул ук вакытта «Казаноргсинтез» оешмасына 5 нче разрядлы аппаратчы булып эшкә урнаштым, – ди Ирек.

Аспирантурада укыганда фәнни җитәкчесе Алим Кемалов белән юл түшәмәсен ныгыту өчен махсус кушылма (присадка) уйлап тапканнар. Аннан шушы тема буенча диссертация яклый. «Чаллыда

Ирек Мөхәммәтдиновның шәхси архивыннан

хәтта безнең матдә кушып җәелгән юл участогы да бар. Бу юлның асфальт катламы вакыт үткәч тә ватылмаган, киресенчә, ныгыган», – дип горурлана егет.

Аспирантураны тәмамлагач, аны КФУның «Внутрипластовое горение» лабораториясенә эшкә чакыралар һәм бүген ул шунда эшләвен дәвам иттерә. Галим әйтүенчә, лабораториядә алар авыр нефтьне чыгару ысуллары белән шөгыльләнә, авыр һәм ябышкак нефтьне тикшерәләр. Монда яшь галим нефтьне тулысынча тикшереп, тәҗрибәләр ясап, физик һәм химик үзлекләрен ачыклый. Студентларга лекцияләр укый, практика һәм лаборатория дәресләрен алып бара.

Аспирантурада укыганда конференцияләрдә катнашып, беренче урыннар яуласа, 2021 елда «Иң яхшы яшь галим» бәйгесендә 2 нче урын алган. «Вверх», «Иң яхшы 50 инновацион идея» бәйгеләрендә җиңгән, Арбузов премиясе призеры. «Бүгенге шартларда фәнебезгә игътибар кирәк», – ди ул.

Мондый акыллы егетне читкә чакыручылар да бардыр, әлбәттә. «Беркая да китәргә җыенмыйм, – диде ул, өздереп. – Китүчеләрнең, бәлки, башка төбәкләрдә яшисе килгәндер. Минем Татарстанга хезмәт итәсем килә».

Сәрия МИФТАХОВА

«Гомерлеккә булган икән»

Йөзьяшәр

Балтачның иң өлкән кешесе Әминә Зариповага шушы көннәрдә 100 яшь тулды. Бер гасырлык юбилее белән котларга килүчеләрне ул яшьләргә биргесез зиһене, хәтере, эзлекле, матур итеп сөйләве белән таң калдырды.

Документта Нина Ивановна булса да, үзе гомер иткән Түнтәр авылында аны барысы да Әминә апа дип белә. Ул чактагы Чынлы (Чүпрәле) районының Әлши авылында туган чуаш кызы, Буадагы фельдшерлар мәктәбен тәмамлаганнан соң, Чепья районына эшкә җибәрелә. Арбор, Борнак авыллары балалар бакчаларында берничә ел эшли. Түнтәргә – декрет ялына киткән шәфкать туташы урынына (шулай ук балалар бакчасына) күчкәндә инде ул татарчаны тәмам өйрәнеп беткән була. Баксаң, ул елларда авыллардагы балалар бакчалары ясле-садлар дип йөртелгән, салам матрацлы, салам мендәрле бу бакчалар хастаханәләр карамагында булган.

– Вакытлыча гына дип килгән идем, шушында гомерлеккә калдым. Мин – Түнтәрне, түнтәрлеләр мине яратты. Берничә елдан сугыштан кайткан Закир белән өйләнештек. Бик матур яшәдек, биш бала үстердек… – дип сөйли Әминә апа.

Эшен бик яратып башкарса да, бала ялыннан соң үз урынына вакытлыча килгәннәр белән даулашып йөрми ул, эш талымлап та тормый, колхозга эшкә чыга. Ә Әминә апа, чордашлары кебек, барлык авыр эшләрдә карусыз була. Кая кушсалар, шунда бара, зарланмый, авырсынмый эшли.

– Әминә апа безнең авылга килгәндә мин яшүсмер малай идем, аны әнә шуның кадәр ел белеп, беркемгә авыр сүз әйткәнен, каты бәрелгәнен хәтерләмим, – ди авылның хөрмәтле кешесе Рәфхәт абый Зарипов. – Кешеләргә бик игелекле, мәрхәмәтле булды. Беркем белән ачуланыша белмәде. Озак яшәвенең, әйбәт саклануының сере дә сабырлыкта, ипле булуындадыр. Ире Закир абый да, аның әти-әнисе дә шундый ипле кешеләр иде. Шөкер, балалары да үзләре кебек акыллы, тәртипле булды. Камилләре югары белемле бик көчле архитектор иде, үз тырышлыгы белән баш архитектор дәрәҗәсенә күтәрелде. Ижаудагы зоопарк, курчак театры кебек бик күп дәрәҗәле биналарның проектлар җитәкчесе булды. Кызганычка, бик яшьли, авырып, вафат булды… Аннан кечерәк балаларын мәктәптә укытырга туры килде. Бик тырышлар иде, әти-әниләре йөзенә кызыллык китермәделәр. Гомер буе хөрмәтләп, ярдәм итеп яшәделәр. Әлегәчә шулай…

Улын, тормыш иптәшен югалту хәсрәтләрен дә балалары ярдәме белән, сабыр холкы белән генә кичерә ала Әминә апа. Яшәр өчен көчне дә шулардан ала. Ун оныгы, аларның балалары өчен генә түгел, хәзер инде бөтен Балтач кешеләре өчен дә иң кадерле, дәрәҗәле акъәби ул…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Һөнәрчелек

Җеп өзелсә, эш харап

Балтач районының Чутай авылында туку эше белән шөгыльләнүче Гөлзифа Нәҗипова социаль челтәрдә бер ай эчендә йолдызга әйләнгән. Үзем тәгәрәп үскән паласларны сагынам, дип көн дә дистәләгән хатлар язалар аңа. Иң мөһиме, ул балачак хыялын тормышка ашырган.

– 7–8 яшь чагымда әбинең, кечкенә өебезгә зур стан кертеп, палас сугуын күзәтә идем. Аның хезмәтләре төп йортта һаман да саклана әле. Үземнең сугып карыйсы килсә дә, дөнья мәшәкатьләре белән әлеге эшкә вакыт җитмәде. Дөресрәге, стан да юк иде. Узган ел кызым белән киявем Киров өлкәсенең Малмыж шәһәрендә узган ярминкәдән туку станогы алып кайтты. Алагаем зур түгел, өстәлгә сыя торган. Ниһаять, декабрь аенда эшкә җиктем мин моны. Башта әллә ни барып чыкмады. Остазым да – интернет кына бит. Шуңа карап өйрәнә торгач, әһә, булдырам бит, дип күңелдә өмет чаткысы уянды. Хәзер менә көннән-көн остара барам. Тырышсаң, була икән, – дип сөйли Гөлзифа ханым.

Баштарак иске футболка, свитерларның да кирәге чыккан. Хәзер Казанга барып, кибеттән трикотаж материал алып кайта икән. Аны юа, киптерә. Калынракларын – 1,5, юкаракларын 2 сантиметр итеп телә. Шулай итеп, чимал әзер була. Гөлзифа апа әйтүенчә, иң авыры – җепләрне дөрес итеп сузу. Буталган чаклары да булгалый. Җеп өзелсә, аны төйнәп кенә станок аша үткәрәм димә. Бер җеп бөтен эшне харап итәргә мөмкин. Берсендә, аптырагач, келәй белән ябыштырган. Палас сугарга 3–4 көн вакыты китә икән. Барлыгы унлапны тукыган инде.

– Утын ярасы, су ташыйсы юк, вакыт уздырыр өчен туку бик әйбәт. Мин тик утырырга яратмыйм, эшләп карамаган эшем калмады бугай. Атнага берәр тапкыр китапханәгә, мәчеткә гарәпчә укырга йөрим, – ди заманасында зоотехник булып эшләгән әңгәмәдәшем.

Кичке сәгать унга кадәр тукыса, аннан соң интернеттан килгән хатларга җавап бирә, үз эшләре белән таныштыра. «Тагын бер палас станнан төште. Монысын балалар өчен тукыдым. Аларга да ошар дип уйлыйм. Монда минем күңел җылысы», – дип куйган соңгы постын. Күпләр станокны каян

алуы, бәясе хакында сораша. «Мондый келәмнәр хәзер модада бит», «Мине дә кызыктырдың әле», «Матур чыккан», – дип, мактау сүзләрен яудырып торалар.

Паласны һәр хуҗабикәнең зәвыгына, бүлмәнең җиһазына туры китереп тукырга була. Тузанын да селкергә уңайлы, кер машинасына салып юарга да мөмкин. Аллергиядән интегүчеләр өчен яхшы, чөнки трикотаж киҗе-мамыктан тукылган. Иң мөһиме, әлеге паласлар берсен берсе кабатламый. Аны баскыч төбенә, ванна, мунча идәннәренә җәяргә була.

– Беренче паласымны саттым инде. Чаллыда яшәүче ханым, мин теләгән палас бу, дип рәхмәт әйтеп алды. Кул эшләремне ошаткач, күңел күтәрелеп китә. Кешенең сөенгәнен күрү рәхәт миңа, – ди ул.

Элекке һөнәрләр турында кызыксынучылар булганга да сөенә Гөлзифа ханым. Тагын бер теләге бар әле: өйләрендәге борынгы әйберләрне туплап, музей ачу.

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15277 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 223

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+